Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

12
декабрь 2019
ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

СЕРГЕЙ НЕУСТРОЕВ «САМАВЫР БЕЛӘН НАТЮРМОРТ»

Татарстан Президенты – Дубайда

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Дубайда (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре) II Бөтендөнья толерантлык саммитында катнашты. Татарстан делегациясе составында Татарстан Президенты ярдәмчесе Радик Гыйматдинов, ТРның мәдәният министры Ирада Әюпова, ТРның Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина, ТРның Дубайдагы сәүдә-сәнәгать вәкиле Тимур Хәйретдинов һәм ТР Мөселманнарының диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин да бар иде.

Фотолар president.tatarstan.ru сайтыннан алынды

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +
12 (312)
декабрь 2019

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

80



31 **ЗАТЛЫ ГАИЛӘ ЯЗМЫШЫ.**
Эльмира Сәлахова

96 **БОРЫНГЫ ТАТАР МИЛЛИ МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ.**
Ринат Гыйләҗев

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Мөхәммәт Мәһдиев**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Этрусклар – Рим остазлары.** *С.Шәмси*
12 **Тарихи карталарда – Бәрәңге җирләре.** *Ф.Мусин*
17 **Мәрҗаниләр эшен дәвам итеп...** *Р.Шәйдуллин*
22 **Гаяз Исхакый – татар Прометее.** *Л.Галиева*
26 **«Корылтай» газетасы.** *Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин*
31 **Затлы гаилә язмышы.** *Э.Сәлахова*

ТАТАР ГАМЕ

38 **Рухи хәзинәбезне барлаганда.** *Х.Миңнегулов*
44 **Гыйлем үзәге... бар иде.** *Т.Галиуллин*
49 **Татар галимнәрен таныткан хезмәт.** *Г.Хаҗиева*
51 **Аның рухы, фәһеме бар...** *Х.Хәлилов*

ДИНИ МИРАС

53 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*
58 **Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?** *Г.Буби*

ӘДӘБИ МИРАС

62 **Хөсәен Мирза.** *Ф.Бурнаш*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

70 **«Тылсымлы тартма»ның... беренче адымнары.** *Ә.Фәйзрахманов*
76 **Иске Мәңгәрнең борынгы зиратындагы ташъязма истәлекләр.** *И.Һадиев, Р.Мәрданов*
80 **Татарның гаярь ирләре.** *И.Сәлахов*
82 **Истә, һаман да истә!**
84 **Моңлы ядкарь.** *Р.Сәгъди*
89 **Мәктәпләр һәм сабакташлар.** *Л.Лерон*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов
Лотфулла Шәфигуллин

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Сайт мөхәррире
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

СӘНГАТИ МИРАС

96 **Борынгы татар милли музыка уен кораллары.** *Р.Гыйләҗев*
100 **Әдип-галим-артист Габдулла абыйга мәдхия.** *Ә.Зарипов*
106 **Гасырлар-чорлар аша – яңа үрләргә!** *Р.Шаһиева*

112 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
114 **Мирасворд**
115 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Декабрь*
116 **«Безнең мирас» журналының 2019 елга библиографиясе**

Заказ №О-3263. Тираж – 2200 данә. Формат 70х108 1/16.
Басарга кул куелды: 22.11.2019.
Чыгу көне: 29.11.2019.
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, Кукмара туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды. Тышлыктагы С.Неустроев рәсемнәре ТР Дәүләт сәнгать музее тупланмасыннан алынып бирелде.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – **«Самавыр белән натюрморт». 1976.**
Сергей Неустроев рәсеме

Безнең мирас №12 декабрь 2019

Мөхәммәт Мәһдиевнең тууына 90 ел

Мөхәммәт Мәһдиев

(1.12.1929 – 14.06.1995)

***

Бер борчу килердәй булса – көт, ул килә.

***

Агач көрәк белән карандаш очлап булмый.

***

Хатын-кыз никадәр ямьсез булса, шулкадәр киенә белми.

***

Кадерең барда – кадерлән, кадерең беткәч, кабереңә әзерлән.

***

Кешенең тормыш коруы – космоска чыгу. Старт дөрес алынса, программа үтәлә; старт начар алынса, бернинди центр корректировка ясый алмый.

***

Әгәр кеше надан булса, аннан котыла алмый: надан профессор, надан академикка хәтле күтәрелеп була, әмма наданлык кала.

***

Дөньяда иң акыллы китапларның берсе – сүзлек. Әлбәттә, аңа сәясәт катнашмаган булса. Сәясәт катнашкан әйбер исән калмый. Сәясәт катнашса, музыка, рәсем сәнгате, әдәбият, архитектура үлә. Опера, балет үлә.

***

Кеше дөрес яшәсә генә озын гомерле була. Кеше генә түгел, җәмгыять тә шулай.

***

Зыялылык-интеллигентлык ул – бик тирән төшенчә. Ул – татар баеның, татар морзасының, татар мулласының нәселе, улы, оныгы булу дигән сүз түгел. Зыялылык ул ярым-йорты була алмый. Ул сыйфат кешедә йә бар, йә юк. Уйлавымча, мондый кеше – үз мәнфәгатьләрен кайгыртмыйча, милләте өчен, аның киләчәге өчен көрәшүче, белемле, юридик әзерлекле, тормышында әхлаклы, динле, милли тарихыбызны белгән ачык күзле, хөсетсез бер татар баласы.

***

Булачак татар язучылары бит, югары уку йортын тәмамлауга, Казанда кала, ә Казан – татар шәһәре түгел. Безнең шәһәрдә милли рух юк. Казан татарлары ул – синтетик татар. Бу атмосферада милләтнең зур язучысы туа алмый.

Текстны Ләбиб Лерон әзерләде. ■

ЭТРУСКЛАР – РИМ ОСТАЗЛАРЫ*

Солтан Шәмси

ҖӘМГЫЯТЬ ҺӘМ СЫЙНФЫЙ КАТЛАУЛАР

Этрусклар җәмгыяте һәм сыйнфый катлаулар турында җәелеп язу әлегә мөмкин түгел, чөнки бу мәсьәләләр тулысынча ачыкланып бетмәгән. Этрусклар җәмгыятен өйрәнүчеләр әлеге мәсьәләне төрле текстларда очраган терминнар, титулларга таянып ачыкларга тырышалар. Әйтик, гаилә төрбәләре – тумулилардагы саркофагларга, кабер өстенә утыртылган таш стелаларга язылган кыска текстларда мәрхүмнең кем икәнлеге, нинди вазыйфа үтәве, ничә яшьтә вафат булуы һәм башка мәгълүматлар күрсәтелгән. Шуларны туплый һәм акрынлап ачыклый барып, галимнәр этрусклар җәмгыятенең төзелешен, анда нинди вазыйфа үтәүчеләр булуын күпмедер дәрәҗәдә ачыклауга ирешкәннәр.

Әлеге мәсьәләне өйрәнүдәге бер үзенчәлеккә игътибар итмичә мөмкин түгел. Эш шунда ки, этрусклар ярдәмендә үсеш алган, аякка баскан һәм, тора-бара көчәеп китеп, этрускларны кысрыклый башлаган һәм ахыр чиктә аларны яулап алуга, буйсындыруга ирешкән Рим дәүләте, соңрак империясе тарихы бик җентекләп өйрәнелгән, төрле яктан тикшерелгән һәм бу дәүләттәге барлык идарә органнары, анда вазыйфа үтәүче затларның титуллары тулысынча ачыкланып беткән, дияргә мөмкин. Этрускларның дәүләт структурасын, җәмгыятен, андагы сыйнфый катлауларны өйрәнүчеләр еш кына этруск телендәге вазыйфаи титулларны ачыклаганда римлылар үрнәгенә мөрәҗәгать итәләр, этрусклардагы титулларны Рим дәүләтендәге терминнар, титуллар белән чагыштырып, аларга ачыклык кертергә тырышалар. Әйтергә кирәк, бу ысул еш кына этрусклардагы титулатураны, статусларны ачыклауда уңышка китерә.

Мәсәлән, галимнәр этрусклардагы идарә органнарын, гадәттә, латин сүзе «магистрат» аша аңлаталар. Магистратлар Борынгы Римда дәүләт хезмәтендә вазыйфа башкаручы затларны (консул, претор, трибун һ.б.) аңлаткан. Этрускларның үзләрендә дәүләт хезмәтендәге төрле затлар нинди титуллар йөрткән соң? Этрурия шәһәр-дәүләтләрендә идарә иткән патшаларның нинди титул йөртүе ачыкланган, дип

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2019) санында.
*Фәнни-популяр тарихи бәян.

әйтергә мөмкин. Галимнәр Римның беренче этруск патшасы Тарквини Приск (Таркна ыруыннан) үз ватаны Этруриядә Лукумон дәрәҗәсендә булган. Шуңа нигезләнеп, этруск патшалары «лукумон» титулын йөрткән, дигән фикер урнашкан. Тик бу фикер белән килешмәүчеләр дә бар. Этрускларда патша вәкаләтләре бирелгән затны икенче бер сүзтезмә – «Этрурия дәүләте патшасы» дип атау очраклары да булган. Әлеге титул Этрурия шәһәр-дәүләтләре берлегендә иң югары вәкаләткә ия затка бирелгән. Этруриянең унике шәһәр-дәүләте тарихында андый затны сайлап кую ихтыяҗы туган хәтәр вакытлар ара-тирә булгалап торган.

Этрусклар җәмгыятендә аксөякләр катлавы аерым урын биләгән. Аңа зур җир хуҗалары, казылма байлыклар чыгарылган шахталарга ия шәхесләр, металл эретү остаханәләре хуҗалары, гаскәр башлыклары, югары статуска ия дин әһелләре кергән. Алар сәясәт, икътисад, хәрби һәм дини өлкәләргә җитәкчелек иткәннәр. Кайбер галимнәр шәһәрләрдәге идарәчеләр «зилк» статусына ия булган, диләр. Бу вазыйфаны башкарган шәхес безнең көннәрдәге «шәһәр мэры» статусына якын торган, ахры. Зилкның төрле вазыйфалар башкаручы ярдәмчеләре дә булган.

Кызганычка, этрусклар җәмгыятенең төзелешен тулысынча ачыклап бетерү әлегә мөмкин түгел.

Этруриядә шулай ук дин әһелләре (жрецлар, гаруспик-күрәзәчеләр) дә зур роль уйнаган. Этруск телендә дин әһелләре «cepen» (кепен) дип аталган һәм, этрусклар гаять дини халык булу сәбәпле, анда дәүләт күләмендә дә, аерым кешеләр дә дини йолаларны еш үтәгәннәр, үз Аллаларына корбан китергәннәр. Әлеге җәмгыятьтә гаруспик-күрәзәчеләр дә мәртәбәле урын алып торган. Бу мәсьәләгә без әлегә озак тукталып тормабыз, ул турыда алдагы бер бүлектә иркенләбрәк сүз алып барылыр.

Әйткәнебезчә, Этрурия тарихында барлык унике шәһәр-дәүләт конфедерациясе катнашында хәл ителергә тиешле гадәттән тыш берәр вакыйга килеп чыкканда, әлеге мәсьәлә белән шөгыльләнү өчен «пурт» вазыйфасы тапшырылган шәхес сайлап куела торган булган. Этрускча «пурт» сүзе латин телендәге «диктатор» мәгънәсенә ия икән. Димәк, андый очракларда бу шәхескә диктатор вәкаләтләре бирелгән. Этрускларның бер үзәктән идарә ителә торган дәүләтләре булмау сәбәпле, килеп туган кыен мәсьәләне шундый ысул белән хәл итәргә туры килгән.

Этрусклар җәмгыятендә шулай ук ирекле кешеләр катлавы да билгеле. Әлеге катлау гадәттә тормышларын берәр төрле һөнәрчелек белән алып барган (әйтик, балта осталары, тимерчеләр, сынчылар, рәссамнар һ.б.). Алар барысы да гражданлык хокукына ия булган.

Хатын-кызларның җәмгыятьтәге урынын **А.И.Немировский** болай билгели: *«Гаиләдә хатын-кызның ирекле булуы этрускларның, римлылар белән чагыштырганда, иҗтимагый-икътисади яктан югарырак баскычта торуын күрсәтә. Бу хәл җәмгыятьнең зур үсешкә ирешүе һәм сизелерлек тарихи тәҗрибә туплавы турында сөйли»* (Нем., 101).

Моннан тыш, әлеге җәмгыятьтә әүвәл кол хәлендә яшәгән һәм соңрак хуҗасы тарафыннан ирек бирелгән кешеләр дә булган. Алар хуҗаның гаилә әгъзасына әверелгән һәм «лаутни»лар катлавына кергән. Этрускча «лаутн» гаилә дигәнне аңлаткан. Иреккә чыкканнан соң бу кешеләр, аксөякнең ышанычлы хезмәтчесе буларак, аның турылыклы ярдәмчесенә әверелгәннәр. Мәсәлән, тимер, бакыр шахталарында эш алып баручы, хуҗаның сәүдә эшләрендә ярдәмчесе, әгәр хуҗа зур җирле булса, кырларда эшләүчеләргә күз-колак булып торучы яки урманда агач материаллары әзерләүгә күзәтчелек итүче һәм башка вазыйфа башкаручыга әйләнгәннәр.

Бу җәмгыятьтә тагын «этера» дип аталган катлау булуы да билгеле. Кемнәр соң ул «этера» дип аталучылар? Әлеге катлауга гражданлык хокукына ия кешеләр кергән. Алар берәр аксөяккә ялланып хезмәт иткәннәр. Шул хезмәтләре бәрабәренә бу кешеләргә күпмедер җир дә бүлеп бирелгән. Этералар җәмгыятьтә крепостной хәлендә яшәгәннәр, хуҗа ирекккә чыгарган лаутнилар алардан өстен торганнар.

Җәмгыятьтәге иң түбән катлау – ул хокуксыз коллар катлавы. Колларның бер өлеше хуҗа йортында хезмәт иткән. Этрускларда, империягә әверелгән Римдагы кебек, рәхимсез, адәми затны хайван дәрәҗәсенә төшергән коллык күренеше булмаган. Дөрес, колларның барысы да хуҗа йортында уңай шартларда яшәмәгән, кайберләре хуҗаның җирләрен эшкәрткән, көтү көткән, шахталарда мәгъдән чыгарган, сәүдә һәм хәрби корабларда ишкәкчеләр булып хезмәт иткән, гыйбадәтханәләр төзелешендә

Биюче этрусклар

эшләгән, канаулар казып, сазлыкларны киптергән. Ә берәр сәләткә ия коллар актёрлар, биючеләр, акробатлар, флейтада уйнаучылар булып киткәннәр. Шунысы игътибарны җәлеп итә, этрускларның киң итеп төзелгән гаилә төрбәләре диварларында сакланып калган фрескаларда мәҗлес корып утыручы этруск аксөякләренә ялангач тәнле үсмер коллар хезмәт күрсәтә. Әмма кол-актёрлар, кол-биючеләр, кол-флейтачылар бик матур киемнәрдә сурәтләнгән. Күрәсең, хуҗа йортында эш башкаручы коллар ялангач килеш йөрергә тиеш булгандыр. Аларның гәүдәләре зифа һәм матур. Бәлки, хуҗалар аларга карап ләззәтләнгәндер. Этрусклар җәмгыятендә, грекләрдагы кебек үк, үсмер егетләр белән җенси мөнәсәбәткә керү гадәти эш саналган.

Этруриядә колларны сатып та ала торган булганнар. Мәсәлән, этрусклардан төньяктарак яшәгән кельтларның кабилә башлыклары бер амфора шәрабка үзенең берәр колын алыштырган. Этруриядә грек, италик, галл (кельт), хәтта Мисырдан китерелгән коллар булуы да билгеле. Карфаген дәүләте диңгезчеләре дә этрускларга коллар китереп саткан. Этрускларның үз пиратлары да б.э.к. IV-III гасырларда, башка

Ике көпшәле флейтада уйнаучы егет

ил корабларына һөҗүм итеп, әсирлеккә төшкән кешеләрне кол иткәннәр. *«Шул ук вакытта күп кенә коллар этруск исемнәрен йөрткән: Тана, Рамта, Вел, Велия, Велфур һ.б.»* (Нем., 129).

Шулай да этрусклар, римлылар кебек, коллар кулга төшерү максатында сугышлар алып бармаганнар. Ә римлылар исә бурычын түли алмаган үз ватандашларын да Этруриягә китереп коллыкка сатканнар. Гомумән Этруриядә, Римдагы кебек, вәхши коллык системасы булмаган.

Этрусклар җәмгыяте гасырлар дәвамында бер килеш кенә калмаган. Ул тора-бара шактый үзгәрешләр кичергән. Әгәр дә борынгы заманда (әйтик, б.э.к. VII, хәтта VI гасыр башында) җәмгыять ике сыйныфтан – хуҗалар һәм хезмәтчеләрдән генә торган булса, вакытлар үтү белән, күргәнебезчә, анда яңа сыйнфый катлаулар барлыкка килгән. Нәтиҗәдә, ул шактый чуарланган, катлауланган. Шәһәрләр барлыкка килгәннән соң авыл халкы анда килеп урнаша башлаган. Шәһәрләр икътисади, зур үсеш ала барган сәүдә мөнәсәбәтләре тормышка үзгәрешләр керткән. Әгәр дә элек җирбиләүче аксөякләр авыллардагы зур утарларында тормыштан канәгать булып яшәсәләр, шәһәрләр барлыкка килү һәм икътисадның, сәүдәнең үсә баруы сәбәпле, җир хуҗалары да бу процесска тартылырга мәҗбүр булганнар. Аларның күбесе, җирләрен үзләренең ышанычлы клиентларына тапшырып, шәһәрләргә күчеп килгәннәр. Шулай яңа аксөякләр катлавы барлыкка килгән. Әлеге катлау шактый киңәйгән, яңа тормыш шартларына яраклашырга тырышкан. Француз этрускологы **Жан-Ноэль Робер** шушы дәвердәге бер кызыклы хәлгә игътибар итә: *«Бу күренештә ономастиканың эволюци-*

Этрускларның югары катлавы вәкиле

ясе үзгәрүгә игътибар итик әле, – дип яза ул. – Әүвәл этруск язмаларында бары тик фамилияләр генә очрый. Б.э.к. VII гасыр урталарыннан исем янына атасының исеме дә (отчество) куела башлый. (Аны галимнәр «gentilice» (гентилице) дип атыйлар. Бу сүзнең нигезен латинча «gens» – «ыру» сүзе тәшкил итә, әмма «gens» сүзенең нигезендә төркичә «җенес» сүзе ята. Латиннарга ул төркиләрдән кергән. – ***С.Ш.***). *Кешенең атасы исеме ул яшәгән төбәк атамасыннан (кайвакытта теге яки бу алла исеменнән дә) ясалган. Соңрак ата исеме кешенең нәселен белдерә башлый. Шулай кеше үзенең нинди нәсел-ырудан булуын, балаларының кайсы атадан тууын күрсәтергә омтылган <...> Римда кабул ителгән системада кешегә исем, фамилия һәм кушамат тагыла торган булган. Этрускларда элек кушаматлар гомумән булмаган, соңрак ул Этруриянең төньяк өлешендә күренә һәм тарала башлаган. Этрускларда ономастика барлыкка килү аксөякләр белән гади халык арасында әллә ни аерма юклыгын күрсәтергә омтылу галәмәте булган»* (Ж.-Н.Робер., 104-105).

Икенче төрле итеп әйткәндә, гади нәселдән чыккан кешеләр исемнәренә затлылык төсмере бирергә тырышканнар. Шул сәбәпле, яшәгән төбәк исемен фамилия итеп алу

очраклары да булган. Бу сыйныфларның үзара якыная, алар арасында атлап чыгып булмаслык киртәләрнең юкка чыга баруын күрсәтүче процесс булган.

ДИҢГЕЗЛӘРДӘ ХУҖА БУЛЫП...

Этрускларның, диңгезләрдә зур юл үтеп, Италиягә корабларда килүен әйтеп узган идек. Геродот язганча, Лидия патшасы Атис халыкны икегә бүлергә карар кылганнан соң үзе илдә кала, ә җирәбә салгач, Тиррен атлы улына ватанны ташлап читкә чыгып китәргә боера. Күрәсең, ул вакытта ук бер чиге Эгей диңгезенә чыгып торган Лидия патшалыгында (Төркия территориясе) диңгездә йөзү гадәти хәл булгандыр. Атис патша үз карамагындагы барлык корабларны да улы Тирренга биреп җибәрә алмагандыр. Тирренга илнең ярты халкын алып диңгезгә чыгып китәр өчен өстәмә кораблар да төзергә туры килгәндер. Моның өчен ул тыныч диңгез култыгында урнашкан Смирна шәһәренә китә һәм анда кораблар төзетә. Шуннан соң гына, әзер корабларга тормыш кирәк-яракларын төяп, халыкның яртысы патша улы Тиррен җитәкчелегендә билгесез һәм хәтәр юлга чыгып китә.

Кече Азиядәге (хәзерге Төркия территориясе) Лидия патшалыгы белән Италия бер-берсеннән ерак урнашкан. Бу ике ил халыклары ул заманда бер-берсе турында аз-маз ишетсәләр дә, әлеге хәбәрләр имеш-мимеш рәвешендә генә булгандыр. Лидиялеләр күбрәк греклар белән аралашкан. Греклар да, лидиялеләр дә диңгезчеләр булганнар, бәлки, үзара диңгез сәүдәсе дә алып барганнардыр.

Ана-ватаннарын ташлап, читкә чыгып киткән лидиялеләр (моннан соң аларны патшалары Тиррен исеме белән тирреннар дип атарбыз), диңгезләр кичеп, турыдан-туры Италиянең урта өлешендә яшәгән умбрлар җиренә килеп урнашканмы? Бу шактый катлаулы мәсьәлә, әмма аңа җавап бирүе кыен түгел. Юктыр, аларның турыдан-туры билгесез җиргә килеп урнашуы шик уята. Фәндә дә әлеге хакта төрле фикерләр бар. Аларның иң ышандырганы – тирреннар әүвәл Италиядән әллә ни ерак булмаган ике зур утрауда – Сардиния белән Корсикада тукталганнар, анда тормыш корып, күпмедер вакыт шунда яшәгәннәр, диелә. Аларга Италиягә үтеп керү өчен бу ил турында башта мәгълүмат тупларга, анда нинди халыклар, кабиләләр яшәвен ачыкларга, табигать шартларын белергә кирәк булгандыр. Италиядә яшәүче бер халык та килмешәк тирреннарны колач җәеп каршыларга җыенмагандыр. Монысы ап-ачык. Үзләренә торыр җир яулап алу өчен, шик юк, тирреннарга көч кулланырга да туры килгәндер. Тирреннар умбрлар җиренә килеп урнашалар, шунда шәһәрләр төзиләр һәм шушы көнгә хәтле анда яшиләр, дип яза Геродот.

Күрәсең, умбрлар үз җирләренә басып кергән халыкка каршы тора алмаганнар, яр буйларыннан ил эченә, Апеннин тауларына якынрак җирләргә таба чигенергә мәҗбүр булганнардыр. Этрурия шәһәрләр иленә әверелгәннән соң да умбрлар тирреннарның күршесендә яшәүләрен дәвам итәләр. Әмма әлеге чорда этрускларга әверелгән халык белән алар арасында нindидер бәрелешләр булуы хакында мәгълүматлар юк. Бу хәл этрускларның алардан өстенрәк һәм көчлерәк булуы турында сөйли кебек.

Француз этрускологы Ж.-Н.Робер этрускларның диңгез флоты б.э.к. VIII гасырдан да соңрак барлыкка килмәгән, дип яза. Димәк, шушы чордан без этруск диңгезчеләренең Урта диңгезнең көнбатышында тулысынча хуҗа булып яшәүләре турында сөйли алабыз. Этрусклар тиз йөрешле сугыш кораблары – питеконтерлар төзиләр. Андый корабның озынлыгы 25 метрга җиткән, корабның һәр ягында егерме бишәр ишкәкче утырган. Илле ишкәкче алып барган кораб, чыннан да, тиз йөрешле булган. Ул инде җилкәнгә уңай яктан җил исүен көтеп тормаган, төрле манёврлар

да ясый алган. Аннан соң сугыш корабларының алгы ягына, су астынарак бронзадан коелган мөгезләр-тараннар урнаштыра торган булганнар. Зур тизлек белән килгән питеконтерлар дошман корабын килә-килешкә төртеп тишкән, җимереп ташлаган.

«Рим империясе барлыкка килгәнче, – дип яза Тит Ливий, – *этрусклар империясе җирдә дә, диңгездә дә зур биләмәләр яулап алалар. Италияне утрау дип күз алдына китерсәк, Өске һәм Аскы диңгезләрнең атамалары этрускларның икесендә дә хуҗа булуы турында сөйли. Аларның берсен Италия халыклары* (этрускларны кайбер халыклар тусклар дип атаган. – ***С. Ш.***) *тускларныкы дип атый, икенчесен, этрускларның колониясе булган Адрия шәһәре исеме белән, Адриатик (Әдрән) диңгез дип йөртә, ә греклар исә Тиррен һәм Адриатик диңгезләр дип атыйлар. Һәм шушы ике диңгезгә хуҗа булып, алар җирләрне дә үзләренең унике шәһәре белән тутырдылар».*

Шулай итеп, этрускларның диңгез флоты греклар һәм Африканың төньягындагы карфагенлыларның көндәшенә әверелә. Һәркайсы Урта диңгезнең көнбатышында төп көчкә әверелергә омтыла. Әлеге хәл киләчәктә алар арасында каршылыклар китереп чыгармасмы, сугыш-бәрелешләргә китермәсме? Бу хакта без алдарак сөйләрбез. Әмма ул мәсьәләләргә күчкәнче, укучыга этруск корабларының нинди диңгез киңлекләрендә хәрәкәт итүен бераз тасвирлап бирү дөрес булыр. Италия, итек сыман, Урта диңгезгә кереп тора. Аның көньягында зур Сицилия утравы бар. Ике арада – бик тар Мессиния бугазы. Бу – стратегик яктан бик мөһим бугаз. Аны бикләп куйсаң, этруск корабларына, Сицилия утравын әйләнеп узып, зур юл үтәргә туры киләчәк. Төньяк Африка ярында урнашкан Финикия диңгез сәүдәгәрләре колониясе Карфаген шәһәренә (хәзерге Тунис) этруск кораблары фәкать шушы юлдан гына бара алачак.

Бераз төньяккарак күтәрелгән очракта, без Тиррен диңгезенә килеп керәбез. Бу диңгезгә күп гасырлар этрусклар хуҗа булганга, ул бүгенге көндә дә үзенең борынгы атамасын саклый. Тиррен диңгезендә ике зур утрау – Сардиния һәм Корсика утраулары урнашкан. Моннан тыш, Этруриянең диңгез ярындагы Популония шәһәре каршында кечерәк Ильба утравы бар. Ул Популониягә якын булганга, яр кырыеннан күренеп үк торган. Ә Ильба утравына аяк баскан кеше калын урманнар белән капланган Корсика утравын күрә алган. Корсикадан исә диңгез уртасында ук урнашкан Сардиния утравына бару кыен булмаган.

Әлеге өч утрау этруск диңгезчеләренә хәрәкәт итү өчен зур уңайлыклар тудырган, чөнки бу, бер утраудан икенчесенә күчә-күчә, диңгездә адашмыйча, аларга юлны дәвам итәргә ярдәм иткән. Борынгы заманда әлеге юлдан этрусклар бик оста файдаланганнар һәм Сардиния утравын үткәннән соң, Ливия дип аталган Төньяк Африка ярларына килеп чыкканнар. Шулай диңгез сәүдәсе белән шөгыльләнгәннәр.

Моннан тыш, Этрурия диңгезчеләре көнбатышка таба да юл салганнар. Ә көнбатышта аларны Иберия (хәзерге Испания) дәүләте кызыксындырган. Иберияде төрки халык – иберләр яшәгән. Бу ил төрле металларга бик бай булган. Ибер металлурглары кургаш, аккургаш, көмеш, тимер белән сәүдә иткәннәр. Алар сугыш кораллары ясау осталары булганнар. Шахталардан чыгарылган мәгъдән эретелгән һәм чит илләргә сатылган. Илнең көньягында урнашкан Тартесс (Тартесия) шәһәре аеруча дан тоткан, ул металлургия һәм мәдәният үзәге булган. Кайбер галимнәр фикеренчә, Тартесс шәһәренә тирреннар нигез салган икән (Нем., 32). Этруск диңгезчеләренең Иберия белән актив сәүдә итүенә, алар белән аралашып яшәвенә хәзерге Испания янындагы Болеар утрауларының борынгы заманда Тиррен утраулары дип аталуы да дәлил булып тора. Этрусклар Тартесстан аккургаш, кургаш, көмеш алып кайтканнар. Этруриянең үзендә бакыр һәм тимер шахталары җитәрлек булган. Әмма кораллар һәм тормыш кирәк-ярагы җитештерү өчен бронза кирәк, ә аны бакыр белән аккургашны

кушып эретеп кенә җитештерергә мөмкин. Шул сәбәпле, этрусклар Тартесстан аккургаш алып кайтканнар. Сугыш һәм авыл хуҗалыгы коралларын тимердән дә ясаганнар.

Этрусклар шулай ук Гибралтар бугазы (борынгы исеме – Геракл баганалары) аша Атлантик океанга да чыкканнар һәм андагы бер утрауда колония оештырмакчы булганнар. Тик гаҗәеп матур табигатьле, яшәү шартлары гаять уңайлы бу утрауда урнашырга аларга карфагенлылар комачаулаган. Этрусклар анда үз колонияләрен булдырса, җәннәт мисалындагы әлеге утрауга Карфаген халкы да күпләп килеп урнаша башлар, Карфаген дәүләте көчен югалтыр, зыян күрер, дип шикләнгәннәр. Әгәр дә Карфаген дәүләтенә юкка чыгу куркынычы яный калса, үзләре шунда күчеп килмәкче булганнар (Нем., 147). Бәлки, көчле җил-давыллар Атлантик океан эченә алып кереп киткән Финикия диңгезчеләре (Карфагенны алар төзи) әүвәл ачкан бу утраулар хәзерге Канар утрауларының берсе булгандыр.

Этруск диңгезчеләре шулай ук Адриатик диңгезне (Әдрән диңгез) дә үз диңгезләре санаганнар. Төньяк Италиядәге Падан тигезлегендә (По елгасы үзәне) аларның Адрия, Спина, Мантуя, Плаценция кебек бай шәһәрләре үсеп чыга. Адриатик диңгез Адрия шәһәре исемен йөртә башлый. Бу шәһәрләр Төньяк Этруриянең колонияләрен тәшкил итә, анда икътисад, мәдәният чәчәк ата. Без алдагы бүлекләрнең берсендә мәшһүр Рим шагыйре, «Энеида» эпосын иҗат иткән Вергилий (б.э.к. 70-19 елларда яшәгән) Мантуя шәһәрендә туган, дип әйтеп үткән идек. Аның туган шәһәре Мантуяда яшәүче кавемнәрне, шул исәптән этрускларны да зурлап язган шигыре дә алдарак китерелде. Бу әсәр язылган чорда этрусклар инде мөстәкыйль дәүләтләрен югалткан булсалар да, аларның абруе әле сакланган. Вергилийның шигыре шул хакта сөйли. Этрускларны шулай күтәреп язгач, аның анасы этрусклардан булмадымы икән, дигән фикер дә туа. Мантуяда катнаш халык яшәгән бит.

Этрурия урманнарында кораблар төзергә яраклы агачлар җитәрлек булган, бигрәк тә Корсика утравындагы калын урманнарда биек ак чыршылар, наратлар күп үскән. Моннан тыш, этрусклар төзелеш өчен римлылар һәм латиннар яшәгән Лаций урманнарыннан да файдаланганнар. Тора-бара, Этрурия урманнарында кораблар төзерлек агачлар кими һәм алар илнең төньяк читендә аккан Арно елгасы буендагы урманнардан файдалана башлыйлар. Умбрлар яшәгән бу җирләргә килеп урнашканда, этрусклар табигатьнең гаять бай булуына да игътибар иткәннәрдер. Гомумән, Этруриядә кораблар төзергә яраклы башка материаллар да җитәрлек булган. Әлбәттә, беренче чиратта агач материаллары, ә икенче чиратта – корабларны җиһазландыру, коралландыру өчен металл җайланмалар җитештерү дә мөһим роль уйнаган. Язып үткәнебезчә, этрусклар металл кою осталары булганнар. Шулай ук билгеләп үткәнчә, алар хәрби корабларның борынына бронзадан коелган очлы мөгез-таран урнаштырганнар. Аны римлылар «ростр» дип атаган.

Рим язучысы Өлкән Плиний (б.э. 23-79 елларында яши) бер әсәрендә әлеге «ростр»ны, ягъни су астынарак урнаштырылган таранны һәм якорьны Писей атлы этруск уйлап тапкан, дип язган (Нем., 144). Камилләштерелгән якорьны римлылар этрусклардан күреп куллана башлаганнар. Гомумән, тарихта ике япьле якорь уйлап табучы ул гына түгел икән. Башка халыкларда да Писей кебек берничә затның исеме телгә алына. ■

ТАРИХИ КАРТАЛАРДА – БӘРӘҢГЕ ҖИРЛӘРЕ

Фәнил Мусин

Тарихи әһәмияткә ия карталарның берсе – «Нократ губернасының Уржум өязен генераль ызанлау планы». XIX гасыр башына нисбәтле бу чыганак белән теләгән һәр кеше интернеттан таныша ала. Шунда ук җир биләмәләренең кемгә һәм кайчан бирелүен аңлата торган икътисади искәрмәләр дә бар.

Генераль ызанлау планы – координатлар челтәрен күрсәтмичә генә кулдан ясалган карта. Аларда җирлекнең тулы картинасы – барлык торак пункт, аерым хуҗалык, пүчинкә, авыл, елга, урман, ул елларда булган юллар, вак чокыр һәм инешләр күрсәтелә.

1765 елның 19 сентябрендә дәүләт җирләрен Генераль ызанлау турында манифест һәм яңа инструкция чыга. Генераль ызанлау 1766 елда башлана һәм XIX гасыр уртасына кадәр дәвам итә. Аның максаты – аерым зат, алпавыт, крестьян һәм

Бәрәңге авылының планы. XIX гасыр башы

Фәнил Мусин – Мари Иле Республикасының Бәрәңге районында чыга торган «Безнең тормыш» газетасының баш мөхәррире, Бәрәңге районының Тарихчы-архивчылар, төбәкне өйрәнүчеләр җәмгыяте рәисе.

Мәкаләне язганда Мазарбашы авылында яшәүче төбәкне өйрәнүче **Наил Габделхак улы Бариев** һәм техник фәннәр кандидаты, Купай авылында туып үскән **Рафаиз Нурмөхәммәт улы Гайнанов** тәкъдим иткән архив материаллары файдаланылды.

башка милекчеләрнең, шәһәр-авылларның җир чикләрен тәгаенләү. Җир (дача) кишәрлекләрен ызанлау белән ике җир үлчәүче – өлкән һәм кече геодезист, 10 кешелек хәрби команда, 12 пунәтәй, өч канцелярия хезмәткәреннән торган төркем шөгыльләнергә тиеш була.

Эш башлар алдыннан белгечләр хуҗадан җир турында кирәкле мәгълүматны, чиктәш торак пункт, табигый объект атамасын һәм алар ия булган кешеләрнең исемнәрен сораган. Шуның нигезендә, чиктәш җир хуҗаларына ызанлау урынына килү турында чакыру җибәрелгән. Ызанлау процессында өлкән җир үлчәүче кишәрлекнең чик буйларын әйләнеп чыга, ә икенче геодезист эчке мәйданны өйрәнә. Алар эшне күзгә күренеп торган ориентирлардан – елга, инеш, чокыр, сазлыкларны тасвирлаудан башлый. Җир үлчәүче бөтен мәгълүматны да кыр журналына теркәп барган, шуның нигезендә, дача һәм ызан кенәгәләре төзелгән. Бәхәсләр һәм планнарга дәгъвалар булган очракта, бу язмалар беренчел төп ызанлау документлары буларак тәкъдим ителгән. 1766 елгы Сенат фәрманында җир үлчәүчеләргә торак пунктларда яшәүче халык саны, кәсебе, җир сыйфаты һәм аны эшкәртү ысулы, хуҗалык итү системасы, округта суднолар йөрү, терлек куу юллары, почта һәм сәүдә трактлары, тегермән, фабрика, заводлар һәм башкалар күрсәтелгән махсус икътисади журналлар да тутырырга кушыла.

Безнең төбәккә килгәндә, Уржум өязен Генераль ызанлау 1796-1820 нче елларда үткәрелә. Шуны да искәртик, хәзерге Бәрәңге районының күпчелек мәйданында бу вакытта урман шаулаган. Мәсәлән, ызанлау мәгълүматларына караганда, 1816 елның 6 сентябренә Илләт авылы җирлеге тулысынча куе урман белән капланган һәм монда бернинди торак пункт күрмибез. Илләт елгасының хәзерге вакытта торф чыгарыла торган яр буйларында Россия империясе хәрби эшләр министры, генерал-лейтенант Петр Петрович Коновницын биләмәләре ызанланган. Урман исә Нократ казна палатасы карамагында булган.

Планнан аңлашылганча, 1807 елда Бәрәңге авылында бер урам – хәзерге вакыттагы Совет урамы гына булган. Авылның чикләре 35 нче йорттан башлана һәм Комсомол урамы чатында тәмамлана. Елганың сул як ярында, Колхоз һәм Коллектив урамнары чатында да берничә йорт барлыгын күрәбез. Авыл аша Иске Казан сәүдә юлы узуы XIX гасырда торак пунктның тиз үсеп китүенә сәбәп булуы ихтимал. Нәкъ менә шушы елларда Бәрәңге авылы волость үзәгенә әверелә дә инде. 1811 елгы алтынчы халык санын алу вакытында биредә 310 ир-ат ясаклы татар яши. Алар арасында керәшеннәр дә бар. Кызганыч, хатын-кызларның санын ачыклый алмадык. Хәзерге Беренче Май урамындагы 11, 13, 15 нче йортлар урнашкан калкулыкта да кечкенә генә пучинкә күренә.

Лажы (Ляжбердино) авылы инеш буеннан башлана һәм урман буендагы зираткача сузыла. Бу вакытта биредәге 18 йортта 48 ясаклы һәм 12 йомышлы татар яши. Картадан Бәрәңге елгасының урман эчендәге агымында, хәзерге авылны урап уза торган юлдагы күпер тирәсендә буа булганын күрәбез. Лажы ягыннан Яңавылга (Ирнур) таба – Ировка елгасына чаклы мәйдан калын урман белән капланган. Ирнур (Иръ) пучинкәсендәге һәм Портянур авылындагы урамнарның, андагы йортларның урнашу тәртибе гасырлар узу белән шактый үзгәргән – хәзер бөтенләй башкача. Бу заманда йортлар, башка чыккан кардәшләр бер-берсенә якын яшәсен дигән принцип буенча төзелеп, төп, ягъни ата-баба нигезе тирәсендәрәк салынган. Шул сәбәпле, урамнар хәзерге кебек туры түгел, ә гаять таркау. Авыллар арасында ага торган Купшерка елгасында XIX гасыр башында буа, димәк, тегермән була. 1811 елда Яңавылда 28 хуҗалык, 112 ясаклы татар, ә Портянурда 54 йорт, 172 ясаклы татар теркәлгән.

Картада Югары һәм Түбән Учиял (Осиялы) авыллары да бар. Алардан урман аша Куракинга, ә аннары кыр аша Морзанай авылларына бара торган юл уза. Бу авылдан

Мазарбашы (бу вакытта Кугунур) авылының планы. XIX гасыр башы

төньяктарак рус крестьяннарының ике пүчинкәсе – Пигильмаш һәм Полянур урнашкан. Куракиннан бераз төньяктарак яңа оешкан Панжинур авылын, ягъни хәзерге Данилово җирләрен күрәбез. Көнчыгыштарак – Овечкино (Иванча Сурт) пүчинкәсе. Ике авылның да халкы елга буенда, урман эчендә яшәгән.

Планда Ирмучаш белән Яндемирово авыллары һәм алар тирәсендә җирле крестьяннарның биләмә мәйданы да ясалган. Ике авыл янында да Ировка елгасының плотиналар белән буылганын күрәбез, бу исә су тегермәннәренең булуы хакында сөйли. Ирмучаштан бераз гына көнчыгыштарак Мари-Лебляк (Ивашкин) пүчинкәсе билгеләнгән, ә аннан соң Искеавылга (Тоштоял) кадәр җәелгән кара урман башлана. Бәрәңгедән төньяктарак, урман эчендә, Чекманур пүчинкәсе бар. Хәзерге Бәрәңге-Елеево юлыннан Искеавылга таба 1,5 чакрым юл узсаң, әлеге җирлек урынына килеп чыгасың. Кайчандыр биредә авыл булганлыгын ерганактагы агачлар һәм иске зират кына искәртә. 1811 елда пүчинкәдә хәзерге Әтнә районының Күшәр авылыннан күчеп килгән ике ясаклы татар һәм мари милләтеннән булган Шерга Изибаевның гаиләләре яши. Әлеге мари гаиләсенең 1762 елгы ревизиядә үк Чекманурда булуы күрсәтелгән.

XVIII гасыр уртасында Искеавылның атамасы Кукмара булган. Хәзер аның Искеавылдагы Заречная урамы урынында икәнлеген күрәбез. XIX гасыр башында биредәге 18 хуҗалыкта татарлар, 6 хуҗалыкта марилар яши. Кушпай (Мари-Кошпай) авылы исә Кошпаев дип теркәлә. Әлеге авыл артыннан башланып киткән урман Ильпанурга кадәр сузылган.

Бәрәңгедән Учулага бара торган юл хәзерге бистәнең көнчыгыш ягындагы плотина яныннан башланган куе урман аша үтә. Учуланың төньягында – Ирсерма елгасы буенда бер хуҗалыклы Тинер-Шинер, ә елганың икенче ягында Олыкыр пүчинкәсе урнашкан. Олыкырда ясаклы татарларның тугыз йорты бар. Аннан ерак түгел Иске Казан сәүдә

Мари Иле Республикасындагы Бәрәңге районының Мазарбашы авылы мәчете

тракты уза. Учуладан Уланурга (Олоры) чаклы урман массивы җәелә, әмма бу елларда анда Тошкемнур авылы булмый. Уланур кечкенә генә торак пункт булуга карамастан, аның биләмәләре Олорка елгасының ике ярына да урнашкан. Авылның көньягында ике пүчинкә – хәзерге Сидорово һәм Макарово авыллары бар. Ә куе урман эчендә яңа гына барлыкка килгән Сабанур пүчинкәсен күрәбез. Хәзерге Манкинер авылы урынында Киржевож пүчинкәсе күрсәтелгән. XIX гасыр башында биредә йомышлы татарлар һәм кавказлылар яши.

Куян авылы – «Илеть-Кукмара Коянково», хәзерге мәчет яныннан башланып, авылны ике өлешкә бүлүче буага кадәр сузылган. 1811 елда биредәге 41 йортта 113 ясаклы татар, Кормашевлардан өч ир туган – Бикчәнтәй, Морас, Абдышлар яшәве билгеле. Ә Ляж елгасының сул як ярында Кошпаев исемле татар пүчинкәсе (соңрак – Татар Кушпае авылы, бүген исә Куян авылының Терлекчеләр урамы) күрсәтелгән. Ноля елгасы тамагында Мәмәтовлар фабрикасы аерым пүчинкә (соңрак – Прикум-Фабрика, хәзер исә Куян авылының Зеленая урамы) итеп билгеләнгән. 1816 елда биредә урнашкан комач фабрикасы белән Мөхәммәдәмин Манасыйпов-Мәмәтовның идарә итүе мәгълүм.

Мазарбашы (Алашайка) авылына килгәндә, XIX гасыр башында ул Кугунур, дип күрсәтелә. Элегрәк, XVIII гасыр уртасында ике торак пункт: Югары Мазарбашы – Морзабаш, ә Түбән Мазарбашы – Кугунур, дип аталган. Вакытлар узу белән, Морзабашның исеме Мазарбашына әйләнә. 1816 елда бу торак пункттагы 78 йортта

татарлар гына – 222 ир-ат һәм 239 хатын-кыз яши. 1829 елда биредә таш җәмигъ мәчет төзелә. Төзелешнең иганәчесе – хәзерге Арча районындагы Түбән Оры авылының танылган сәүдәгәре һәм фабриканты Мөэмин Таһир улы Хуҗасәетов.

Атаклы сәүдәгәрнең биредә зур мәчет салдыруы һич кенә дә очраклы күренеш түгел. М.Хуҗасәетов җирле эшкуарлар Мәмәтовалар белән туганлык мөнәсәбәтендә булып, бизнеста да аларның уртак эшләре булган. Апасы Сәгадәтбану Туктамышева (1741 елгы) Мәмәтовлар нәселе кешесе Мәкъсут Бикмәтов-Мәмәтовка (1716-1802) кияүгә чыга. Мәкъсутнең уллары Муса, Мәхмүт, Мөхәммәтрәхим яхшы гына сәүдәгәр һәм сәнәгатьчеләр булып таныла. Өлкән улы Манасыйп Мәкъсутов (1744-1803) безнең якларда берничә комач, кәгазь фабрикалары һәм поташ заводы төзи. Аның вафатыннан соң, сәнәгать оешмалары Манасыйпның ир туганнары һәм балаларына кала. Бу нәсел гаиләләре Портянур-Мәмәт (хәзерге Купай) һәм Койли-Портянур (Путаш) пүчинкәләрендә дә яшәгән. Мәмәтовлардан булган Рахманкол Бикмәтовның (1707) балалары ат үрчетү һәм агач эшкәртү белән таныла.

«История сел и деревень Республики Марий Эл. Параньгинский район» исемле документаль җыентыкта Портчара авылында кәгазь фабрикасы хуҗасы Сөләйман Йосыповның яшәве искә алына. Бу шәхеснең дә Мәмәтовлар нәселеннән икәнен белдек. 1811 елгы алтынчы ревизия кенәгәсендә ул Мөхәммәдәмин Манасыйпов-Мәмәтовның туганы буларак күрсәтелә һәм аның гаиләсендә – Поташ пүчинкәсендә яши. Бу елларда Сөләйманга нибары 10 яшь. Ә инде 1850 һәм 1858 еллардагы халык исәбен алу документларында Сөләйманның үз гаиләсе белән Кугунурда (Алашайкада) яшәве теркәлә.

Картаны өйрәнүне дәвам итеп, Вочарма авылын, ә аннан бераз гына көнчыгыштарак Мари-Сеснурны табабыз. Алар арасында, урманда Оби-Памаш чишмәсен күрәбез, хәзерге вакытта бу урында әлеге исем белән аталган авыл бар. Биредә дә Россия империясе хәрби эшләр министры, генерал-лейтенант Петр Петрович Коновницын биләмәләре булган икән.

Вочармадан төньякта Елеево җирләре (әле авыл түгел) күрсәтелгән, тагын да төньяктарак – Помосъял. Ә менә Николашкино һәм Егорково авыллары картада юк, әмма Иштырадан күчеп килүчеләр нигез салган пүчинкәләр бар. 1812 елда Солянур Мамьянчара пүчинкәсендәге (хәзерге Хәсән авылы) дүрт йортта 13 кеше яши. Пүчинкәгә 1813 елда 61 яшендә вафат булган Габит Арсланов нигез салган. Бу вакытта авылда Мәмәтовлар да яши башлый. 1807 елда Муса Мәкъсутов-Мәмәтов ерганакның аргы ягындагы Токсубай пүчинкәсенә нигез сала.

XIX гасыр башында хәзерге Рус Ляжмары җирлеге территориясендә, Хәсән авылыннан кала, тагын берничә торак пункт булган. Болар – Мари-Ляжмары, Иштыра һәм Юлтышка. Биләмә тулысынча диярлек урман белән капланган. Ачыклыкта Вятка мещаны Авдотья Прозорова һәм дәүләт эшлеклесе Татьяна Окуневаның печәнлек җирләрен күрәбез. Моннан тыш, 1811 елгы ревизия кенәгәләрендә биредәге Капкаинер һәм Удеринер чишмәләре арасында тагын бер пүчинкә – хәзерге Ишим авылы җирләре дә бар. Монда ике татар гаиләсе яшәгән, 1816 елга кадәр алар башка торак пунктларга күчеп китәләр. ■

Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты оешуга – 25 ел

МӘРҖАНИЛӘР *эшен дәвам итеп...*

Институт хезмәткәрләре ТР Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов белән

Татарстанда татар халкы тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүче фәнни-тикшеренү оешмалары җитәрлек. Алар арасында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты аерым урын тота. Ул, фәнни оешма буларак, Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхреддин һәм башка татар зыялыларының энциклопедик традицияләрен дәвам итү, үстерү эшендә мәртәбәгә иреште. Быел аның оешуына 25 ел тулды.

Бүген Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты – төрле энциклопедияләрнең фәнни һәм методик нигезләрен эшләгән әйдәп баручы фәнни-тикшеренү учреждениесе. Биредә энциклопедияләргә профессиональ экспертиза уздырыла, шулай ук илебездәге энциклопедия эшенең теориясе һәм үсеше мәсьәләләре өйрәнелә. Институтның фәнни хезмәткәрләре төрле басмалар өчен фәнни концепцияләр эшли, материалны бәян итү принципларын, аны сайлап алу критерийларын, мәкаләне әзерләү һәм аны мәгълүматлар белән баетуның, иллюстратив һәм библиографик яктан тәэмин итүнең методик нигезләрен билгели.

Институт хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев һәм ТР Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов белән. 2005 ел

Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының тарихы Татарстан АССР Министрлар Советының 339 нчы «Татар совет энциклопедиясен әзерләү һәм нәшер итү турында»гы карары (6 сентябрь, 1989 ел) нигезендә Тел, әдәбият һәм тарих институты каршында оештырылган Татар совет энциклопедиясе бүлегеннән башлана.

Документ Татарстан АССР Министрлар Советы рәисе М.Ш.Шәймиев тарафыннан имзаланган. Карарның преамбуласы мондый: *«Киң җәмәгатьчелек теләкләрен исәпкә алып, КПСС өлкә комитеты бюросының 1989 елның 14 марты карары белән расланган республика максатчыл комплекслы «Мирас» программасын башкару һәм хезмәт ияләрен интернациональ һәм патриотик рухта тәрбияләү максатында, Татарстан АССР Министрлар Советы карар бирә: СССР ФАнең Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының, В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының, ТАССРның Нәшрият эшләре, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча дәүләт комитетының 1989-2000 елларда күптомлы Татар совет энциклопедиясен (татар һәм урыс телләрендә) әзерләү һәм бастыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә». Бер үк вакытта СССР Социаль-торак банкының Татарстан республика идарәсенә «СССР ФАнең Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы Татар совет энциклопедиясе фәнни үзәгенә ТАССРның <...> предприятиеләреннән, оешмаларыннан һәм учреждениеләреннән, министрлыкларыннан һәм ведомстволарыннан, шулай ук аерым совет һәм чит ил гражданнарыннан акча күчерү өчен Фәнни үзәкнең махсус хисабын ачарга»* йөкләмә бирелә.

Шулай итеп, кәгазьдә Татар совет энциклопедиясе фәнни үзәге оеша, аның шәхси хисабына 3,18 миллион сумлык спонсор акчасы күчерелү планлаштырыла.

Әмма күп кенә предприятие һәм оешмаларның җитәкчеләре үзләре өчен аңлаешлы

булмаган ниндидер фәнни-тикшеренү учреждениесенең эшчәнлеген финансларга атлыгып тормый. Моннан тыш, илдә һәм республикада социаль-икътисади вазгыять һаман катлаулана бара, инфляция арта, бәяләр күтәрелә. Әлбәттә, болар барысы да тулы куәтле Татар совет энциклопедиясе *фәнни үзәген* булдыру юлында киртәләр тудыра, аның урынына өлешчә иганәчеләр, өлешчә институт исәбенә финанслаучы кечкенә генә Татар совет энциклопедиясе *бүлеге* төзелә.

Үзәкне оештыруда туган кыенлыкларның тагын берсе – ике телдә иркен сөйләшә һәм яза белгән кадрлар кытлыгы була. Алай да, кирәкле хезмәткәрләр туплана, аларның күпчелеген фәнни-тикшеренү тәҗрибәсе булмаган яшь белгечләр тәшкил итә. 1992 елның мартында бүлек составында 14 штат берәмлеге исәпләнә. Бүлекнең мөдире итеп Ф.С.Хәкимҗанов билгеләнә. Коллективның тәүге составында 4 кеше генә гыйльми дәрәҗәгә ия була: филология фәннәре кандидаты Ф.С.Хәкимҗанов, өлкән фәнни хезмәткәр, тарих фәннәре кандидаты Г.К.Вайда, өлкән фәнни хезмәткәр, философия фәннәре кандидаты Р.М.Мөхәмматшин, фәнни хезмәткәр, тарих фәннәре кандидаты Р.В.Шәйдуллин. Бүген институтта беренче составтан өч кенә кеше эшли: тарих фәннәре докторы, профессор, энциклопедистика үзәге мөдире Р.В.Шәйдуллин, фәнни хезмәткәрләр Г.М.Габделхакова һәм Л.М.Сәхабова.

Оешкач та, Татар совет энциклопедиясе бүлеге хезмәткәрләре өчен Тел, әдәбият һәм тарих институты җитәкчелеге (директор М.З.Зәкиев) тарафыннан кечкенә бүлмә бирелде, анда компьютер, булачак энциклопедия лөгатьлегенә керәчәк шәхесләрнең фамилияләре, терминнар һәм төшенчәләр язылган карточкалардан тупланган каталог урнаштырылды. Бер үк вакытта әлеге бүлмә компьютерчы Резеда Габитова белән бүлек мөдире Фәрит Хәкимҗановның эш урыны да булды. Резеда компьютерда лөгатьлек материалларын һәм мәкаләләрне туплады. Еш кына бу эшкә бүлек мөдире үзе дә тартылды, ул кичләрен материалларны җыю һәм системалаштыру белән шөгыльләнде.

Кыенлыкларга карамастан, Татар совет энциклопедиясе бүлеге тарафыннан ике ел эчендә «Татар совет энциклопедиясе»нең фәнни концепциясе (беренче вариантта) эшләнде һәм аның нигезендә татар телендә 11 меңләп төшенчәне һәм шәхесләр исемлеген колачлаган беренче генераль лөгатьлек әзерләнде, энциклопедия сүзлеге өчен урыс телендә беркадәр мәкаләләр язылды.

1991 елның азагында СССР таркалганнан соң, «Татар совет энциклопедиясе» концепциясенең фәнни нигезе тамырдан үзгәрде. Нәтиҗәдә, хезмәт басылмыйча калды. Тупланган материаллар киләчәктә «Татар энциклопедия сүзлеге» һәм күптомлы «Татар энциклопедиясе» өчен нигез булды.

1992 елның 3 мартында Татар совет энциклопедиясе бүлеге, «совет» сүзен төшереп калдырып, яңа оештырылган Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе карамагына тапшырылды. Бүлекнең башлыгы итеп Казан мәдәният институтында эшләгән тарих фәннәре кандидаты Г.С.Сабирҗанов билгеләнде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1993-1994 елларда дөнья күргән махсус карарлары нигезендә, *«Татар энциклопедиясе»н эшләүне һәм бастыруны тизләтү өчен* мөстәкыйль Татар энциклопедиясе институты оештырылды. 1997 елга кергәндә, ул фәнни-тикшеренү һәм нәшрият учреждениесе буларак формалашып бетте.

Бу вакытка аның кадрлар мәсьәләсе хәл ителде, агымдагы һәм перспективадагы планнары расланды. 1998 елда, Татарстан җитәкчелеге карары белән, институтка Казанның Пушкин урамыннан аерым бина (элеккеге Крестовниковлар йорты) бирелде. 1999 елның февралендә, капиталь төзекләндерү эшләреннән соң, моңарчы төрле җирләрдә таралып эшләгән хезмәткәрләр бер түбә астына тупланды. Институт белән озак еллар дәвамында филология фәннәре докторы, академик Мансур Хәсән улы

Хәсәнов җитәкчелек итте. Бер үк вакытта ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты рәисенең беренче урынбасары (1992 елга кадәр) һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең президенты (2006 елга кадәр) вазыйфаларын да башкарды. Институтта ул 2010 елның 13 мартына кадәр хезмәт куйды. Эшләре бик тыгыз булуга карамастан, Мансур Хәсәнов, институтның оештыру-хуҗалык һәм фәнни-нәшер итү проблемаларын хәл итүдән тыш, «Татар энциклопедиясе»нең фәнни концепциясен төзүгә, аның эчтәлеген билгеләүгә дә вакыт тапты. 1994-2011 елларда директорның беренче урынбасары булып Г.С.Сабирҗанов эшләде.

Тырышлык һәм бирелеп эшләүнең күркәм нәтиҗәсе буларак, 1994-1997 елларда «Татар энциклопедиясе»нең урыс һәм татар телләрендә беренче лөгатьлекләре дөнья күрде. Лөгатьлек материаллары урыс телендә «Татарский энциклопедический словарь»ны эшләү һәм бастыру өчен нигез булды. Әлеге басма 1999 елда, 30000 данә тираж белән, Лондонда нәшер ителде. 2002 елда ул, 7000 тираж белән, татар телендә дә басылды. Урыс һәм татар телләрендәге генераль лөгатьлекләрне камилләштерү юнәлешендә күп еллар дәвамында башкарылган эш нәтиҗәсендә, институт коллективы «Татар энциклопедия сүзлеге»нең һәм күптомлы «Татар энциклопедиясе»нең үзенчәлекле модель структурасын эшләү һәм әлеге энциклопедик басмаларга фундаментальлек, фәннилек, системалылык һәм комплекслылык сыйфатларын бирү югарылыгына ирешә. Татар телендәге лөгатьлекне эшләгәндә фәнни терминнарны һәм төшенчәләрне алынмалардан арындыру, системалаштыру һәм транслитерация, географик объектларның (таулар, елгалар, күлләр), хайваннарның һәм үсемлекләрнең, шулай ук торак пунктларның атамаларын тәртипкә салу буенча зур лексикологик эш башкарылды.

«Татар энциклопедиясе»нең лөгатьлеге даими рәвештә актуальләштерелде, камилләштерелде, яңартылды һәм тулыландырылды. Нәтиҗәдә, урыс телендәге 6 томлык «Татар энциклопедиясе»ндә (2002-2014 еллар) «кара сүзләр» исәбе 20000гә җитте. Татар телендәге 7 томлык «Татар энциклопедиясе»ндә (2008-2019 еллар) лөгатьлек 21000 «кара сүз»гә тулды.

Бу басмалар татар мәдәнияте тарихында зур вакыйга булды. Аның фәнни-әдәби һәм энциклопедик нигезләмәләрен төзүгә Р.Н.Даутов, Ф.С.Фасиев, К.С.Миңлебаев, Г.С.Сабирҗанов, Ф.К.Зыятдинов, Л.Х.Хәмидуллин, А.Г.Яруллина, Р.В.Шәйдуллин зур өлеш кертте. Ф.Ә.Шәрифуллин, И.Х.Хәлиуллин, Р.И.Раскулова, С.С.Шәмси кебек татар мөхәррирләренең эшчәнлеге дә тирән ихтирамга лаек. Энциклопедик басмалар текстын тәрҗемә итү эшендә Ф.Р.Бәдретдинова, Р.С.Вафина, В.Г.Габдрахманова, Л.К.Галиева, Ф.С.Гыйниятуллина, Р.Г.Зәкиева, Ф.Г.Камалетдинова, Г.И.Каюмова, Р.И.Хәлиуллина һ.б. күп тырышлык куйды.

Урыс һәм татар телләрендәге «Татар энциклопедия сүзлеге»ннән һәм күптомлы «Татар энциклопедиясе»ннән гайре, институт тагын бик күп басмаларны дөньяга чыгарды. Алар арасында төбәк энциклопедияләре, фәнни белешмәлекләр, «Татарстан: иллюстрацияле энциклопедия» (2013 ел), «Татарстан: кыскача иллюстрацияле энциклопедия» (2015 ел), «Татарстан Республикасының табигате һәм табигый байлыклары: иллюстрацияле энциклопедия» (2017 ел), «Әдәби Чистай. Энциклопедия» (2017 ел), «Татарстан Республикасының торак пунктлары: иллюстрацияле энциклопедия» (беренче том, 2018 ел), «Татарстан Республикасының юкка чыккан торак пунктлары: белешмәлек» (2016 ел), «Татарстан Республикасы: гаммави мәгълүмат чаралары өчен энциклопедик белешмәлек» (2016 ел) кебек хезмәтләр аерым әһәмияткә ия.

Институт коллективы тарафыннан татарлар тупланып яшәгән урыннарны өйрәнү буенча да зур эш башкарыла. Соңгы биш елда, мәсәлән, «Казакъстан татарлары: энцик-

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты хезмәткәрләре. 2019 ел

лопедик белешмәлек» (2016 ел), «Казакъстан татарлары: кыскача иллюстрацияле энциклопедия» (2017 ел), «Россия Федерациясендә татарлар тупланып яшәгән төбәкләр: белешмәлек» (2016 ел), «Урта Идел буенда татарлар тупланып яшәгән җирләрдә татар авылы: тарих һәм хәзерге чор» (2017 ел) басмалары дөнья күрде.

Институт эшчәнлегендә Татарстанның җәмгыяви-мәдәни тарихын популярлаштыру да аерым урын тота. Бу җәһәттән, соңгы ун елда «Татарстан Республикасы: табигать, тарих, икътисад, мәдәният, фән» (2010, 2015 еллар), «Татарстанның үзәк дәүләт хакимияте һәм идарә органнары (1920-2010 еллар): фәнни белешмәлек» (2010, 2017 еллар), «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль символлары» (2017 ел) кебек җитди басмалар дөнья күрде. Татарстан АССР оешуның 100 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган дәүләт программасы кысаларында хәзерге көндә басмага махсус китаплар, җыентыклар, иллюстрацияле альбом әзерләнә...

Бер мәкалә эчендә генә институт кадәр институтның 25 ел дәвамында ирешкән уңыш-казанышларын санап чыгу мөмкин түгел, әлбәттә.

Институт коллективы яулаган үрләр – Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы халыклары өчен милли-төбәк энциклопедияләренең мөһим булуын тану – Татарстан Республикасы җитәкчелеге (хосусан, президентларыбыз М.Ш.Шәймиев һәм Р.Н.Миңнеханов) тарафыннан даими игътибар һәм яклау нәтиҗәсе дә. Чирек гасырга сыйган мәгънәле юл үтеп, биниһая эшләр башкарылуга карамастан, Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты алдында бүген дә бик зур бурычлар тора әле. Җиң сызганып эшләргә генә кирәк.

Рафаил Шәйдуллин,

тарих фәннәре докторы, профессор ■

Мөһаҗирләр мирасы

ГАЯЗ ИСХАКЫЙ – *татар Прометее**

Ләйсән Галиева

Бу исемне телгә алганда, беренче булып, Хәсән Туфанның «Могикан» поэмасындагы аяклары бәйле Прометей искә төшә. Борынгы грек мифологиясендәге Прометей XX гасыр татар әдәбиятының тагын бер күренекле язучысы иҗатында урын ала. Интернетта аны «татар Прометее» дип атау да очрый. Сүз – Гаяз Исхакый хакында.

Әдип әсәрләренең унбиш томлыгында Прометей сүзе клуб, оешма, җәбһә (фронт), сәяси блок, мәҗмуга, җәмгыять атамалары буларак очрый. Г.Исхакыйның 1930 елгы бер язмасыннан: *«Әле без, төрек-татар оешмалары һәр йирдә бергә, бер-беремезгә ярдәмләшеп, бер фикердә хәрәкәт итәмез. Дошманның көчлелеген аңлап, без бөтен рус кул астыннан котылыр өчен тартышкан халыклар белән якынлашырга телимез. Украина, Гөрҗестан, Кубань вә Дон казакларының истикъляль* (азатлык. – ***Л.Г.***) *көрәшчеләре белән берегеп, «Прометә» исемле сәяси клублар төзедек. Шул ук исемдә Парижда французча бер мәҗмуга чыгарамыз. «Прометә»нең лозунгасы – Русияне милләтләр нигезендә бүлүдер, бу изге эшемездә бер-беремезгә ярдәмләшүдер. Хәзерге көндә «Прометә» оешмасында Украина, Кавказия, Төркестан, Идел-Урал, Кырым, Кубань вә Дон истикъляль-*



«Прометей» хәрәкәтендәге кавказ һәм төрки халыкларның җитәкчеләре. Сулдан уңга утырганнар: Мамәд Гәрәй Сунш, Җәгъфәр Сәедәхмәд, Гаяз Исхакый, Мөхәммәдәмин Рәсүлзадә. Басып торалар: Мостафа Чокай, Мостафа Вәкилле, Таусолтан Шакман. Варшава, 1920-1930 нчы еллар

*Мәкалә Татарстан Республикасының яшьләр гранты кысаларында языльды. Проект номеры: 17-100-ч Г 2019.

чылары әгъзадыр. Себер халыкларының вә карелиялеләрнең дә безгә катнашулары вә аларның эшләрен дә үземезнеке итеп алу – әгъзаларымызның теләгедер», – дигән юлларны укыйбыз. Алга таба күренекле язучыбыз «Прометей»да төрки-татар төркеменең украиннардан кала икенче урын тотуы, татарларның тулы хокуклы әгъза дәрәҗәсенә ирешүләре, оешманың төрле чараларны уздыруда ярдәм күрсәтүе хакында хәбәр итә. Г.Исхакыйның аерым мәкаләләре нәкъ менә шушы төркем фронт эшчәнлеген җәелдерү максатыннан языла.

1938 елда «Яңа милли юл» журналында Г.Исхакыйның «Прометә» исемле мәкаләсе басылып чыга. Биредә оешманың төп максаты ассызыклана – Русиядән аерылган милләтләрнең бәйсезлекләренә ирешеп, мөстәкыйль дәүләтләр төзү. Оешма, аңа кергән төрле милләт вәкилләре, «Прометей» исемле журнал чыгуы турында сүз бара.

«Прометей» хәрәкәте эшчәнлеге әле бүген дә тулысынча бәяләнеп бетмәгән. Фикер каршылыклары да бар. Әлеге оешманың төрле ил эмигрантларын берләштерүе дә бу өлкәдәге эзләнүләрне катлауландыра. Шулай да аерым фактларны, бигрәк тә Г.Исхакый шәхесенә кагылышлы мәгълүматларны барлап карыйк.

2013 елда Бакуда азәрбайҗан, 2015 елда Мәскәүдә рус телендә Мөхәммәдәмин Рәсүлзадә энциклопедиясе дөнья күрә. Биредә «Прометей» оешмасының эшчәнлеге Семих Ваннер, Этьен Копон, Рамиз Абуталыбов һ.б. галимнәрнең хезмәтләренә таянып ачыклана. Эчтәлектән чыгып, кайбер нәтиҗәләрне ясап үтәбез.

Прометейчылык хәрәкәтенең төп максаты – рус булмаган халыкларның бәйсезлек өчен алып барган милли хәрәкәтләрен хуплау һәм шуның аркылы Россия империясен (соңрак Советлар Союзын) көчсезләндерү. Әлеге хәрәкәтнең җитәкчелеге Кызыл Армиягә оппозициядә торып һәм туган илдә җиңелүгә юлыгып, эмиграциядә большевизмга каршы бердәм фронт барлыкка китерергә тырыша. Дөрестән дә, хәрәкәт төрле илләрдә абруйлы шәхесләрне берләштерә. СССР тирәли «Прометей» исемендәге төркемнәр Варшава, Берлин, Париж, Истанбул, Шанхай, Мюнхен, Хельсинки, Токиода оештырыла. А.Ф.Керенский Парижда большевикларга каршы оешмага нигез сала һәм «Дни» исемле басма чыгара. Әмма чыгышлары белән рус булмаган эмигрантларның күбесе аны Россиянең колониаль сәясәтен яклауда, Кавказ һәм Төркестан илләренә бәйсезлек бирергә теләмәүдә гаепли.

«Прометей» хәрәкәтенең төрки-татар юнәлешен оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе – Башкортстанның беренче җитәкчесе Әхмәтзәки Вәлиди-Туган. Ул, 1923 елда Парижга килгәннән соң, Мостафа Чокай углы, Галимәрдән бәй Топчыбашев һәм Садри Максуди белән таныша.

1924 елда Польша хакимиятенең рәсми вәкиле Стемповски белән очрашу вакытында «Прометей» журналын чыгара башлау турында карар кабул ителә. Франциядә маршал Юзеф Пилсудский ярдәме белән француз телендә «Прометей» журналын чыгара башлыйлар. Идарә һәм даими авторлар арасына Кавказ, Төркестан һәм Украина вәкилләре кертелә: Ной Жордания, Александр Шульгин, Гаяз Исхакый, Мирьякуб Мехтиев һ.б. Үз журналын бастырудан тыш, «Прометей» оешмасы эмигрантларның башка басмаларын чыгаруда да ярдәм итә. Әлеге журналлар исемлегенә Идел-Урал төркиләренең «Яңа милли юл»ы да кертелгән. Рәсүлзадә энциклопедиясендә Г.Исхакый хакында кыскача белешмә, «Прометей» хәрәкәтенең кавказ һәм төрки халыклар җитәкчеләре белән төшкән фотосы урнаштырылган. Энциклопедиядә китерелгән фактларны конкретлаштыру сорала, чөнки аларның күбесе татар укучысында бары тик өстәмә сораулар гына уята.

Политология фәне галиме, тарихчы, Җәмгыять белеме фәннәрен тикшерү Югары

Sixième Année. — N° 52 St-Cloud Mars 1931

PROMÉTHÉE

Revue Mensuelle

Le Numéro { France : 3 fr. Étranger : 5 fr.

ABONNEMENT

Un an........ 30 francs.

Étranger .... 50 francs.

Organe de défense nationale des Peuples du

CAUCASE { Géorgie Azerbaïdjan Caucase du Nord

de l'UKRAINE et du TURKESTAN

Directeur : Georges GVAZAWA

«Прометей» журналының тышлыгы. 1931 ел, №52

мәктәбе (Париж, Франция) докторы Георгий Мамулиа да мәҗмуганың барлыкка килү сәбәпләренә игътибар итә. 1925 елда Истанбулда «Прометей»ның Кавказ бәйсезлеге комитеты оешу, 1926 елның маенда Польшада Юзеф Пилсудскийның хакимияткә килүе белән бәйле, дигән нәтиҗәгә килә. «Прометей» журналы 1927 елның язынннан

Кавказ, Украина һәм Төркестан халыкларын яклаучы милли орган буларак бастырыла башлый. Мең данә тираж белән чыккан журнал Франция һәм башка илләрнең сәяси эшлеклеләренә бушка таратыла. Басма бүленеш ягыннан өч өлештән тора. Беренче бүлек гомуми характердагы мәкаләләрне, СССРның үзендә һәм аннан читтәге сәяси мохитне тасвирлаган язмаларны эченә ала. Икенче бүлектә Кавказ, Украина һәм Төркестандагы аерым халыкларның милли бәйсезлек өчен алып барган көрәш тарихы һәм хәзерге хәлләре яктыртыла. Соңгы бүлектә редакциягә килгән хатларга күзәтү ясала. 1926-1938 елларда журналның баш мөхәррир вазыйфасын грузин милләтеннән булган милли демократ Георгий Гвазава (1869-1941) башкара. 1935-1940 елларда журнал үзгәреш кичерә. Бу кырым һәм казан татарлары, башкорт, бурят һәм Ерак Көнчыгыштагы аз санлы халыкларның активлашып китүе белән дә бәйле.

Редакция коллегиясенә, Георгий Гвазавадан кала, Мир Якуб Мехтиев, Ибраһим Чулик, Александр Шульгин, Мостафа Чокайлар да керә. 1938 елның май аенда «Прометей» журналы кабат үзгәрешкә дучар була. Мәҗмуга хәрәкәттә катнашкан барлык милли оешмаларның уртак басмасына әверелә һәм «La Revue de Prométhée» («Ревью де Прометей» – «Прометей күзәтүе») исеме белән чыга башлый. Мөхәррире итеп Украина Халык Республикасының элекке чит ил эшләре министры Александр Шульгин тәгаенләнә.

Г.Мамулиа «Прометей» журналының тарихына кагылышлы бер хисап документын да җәмәгатьчелеккә җиткерә. Ул баш мөхәррир Г.Гвазава тарафыннан язылган һәм басманың 1926-1934 еллардагы эшчәнлеген яктырта. Рәсми кәгазьдән аңлашылганча, журнал редакциясе нәшрият эшчәнлеге белән генә чикләнеп калмый. Ул, хәленнән килгәнчә, 1932 елга кадәр бары тик Варшавада булган һәм формаль рәвештә Франция башкаласында 1939 елның мартында барлыкка китерелгән «Прометей клубы»ның функцияләрен билгеле бер дәрәҗәдә үз өстенә алып, әлеге хәрәкәттә үзәк рольне уйный. Әмма бу документта татар әдибенең исеме очрамый.

Г.Исхакыйның Париждагы «Прометей» журналы редакциясенә юллаган бер хаты бар. Эчтәлектән аңлашылганча, язучы әлеге журналда бер мәкалә дә бастырмавын белдерә. Хат 1931 елның 30 мартында язылган. Шулай да, бу хәбәр Г.Исхакый мәҗмугада автор буларак бөтенләй катнашмаган дигән сүз түгел. Тарихчы С.М.Исхаков мәкаләсеннән күренгәнчә, «Прометей» журналында Г.Исхакыйның «Кызыл хаҗилар яки большевикларның икейөзлелеге» (1931, №52), соңрак «La Revue de Prométhée»да француз телендә «Loukman le Saga» («Локман Хәким») әсәре дөнья күрә (1938, №2). Соңгысы язучының «Шәхесләребез» сериясендә басылып чыккан тарихи-документаль җыентыкта да теркәлгән. «Прометей» журналының безнең кулда булган саннарында Г.Исхакый имзасы (Ishaki) куелган тагын бер хезмәт табылды. 1933 елгы 77 нче санда басылып чыккан бу мәкалә «Идел-Урал татарларының бәйсезлек өчен көрәшенә күзәтү» дип атала. Авторы билгесез бер язмада Г.Исхакыйның Европага әйләнеп кайтуы хәбәр ителә (1936). Г.Исхакый һәм татар халкының башка күренекле шәхесләре турындагы мәгълүматларны журнал саннарының хроника өлешеннән дә табарга мөмкин.

«Прометей» журналының барлыгы 137 саны дөнья күргән. Кызганыч, шулардан кырыгының эчтәлеге әлегә безгә билгеле түгел. Мәҗмуганың дәвамы булган «La Revue de Prométhée» басмасы да өйрәнелмәгән. Эзләнүләрнең табышлы буласына өметләник. ■

«Корылтай» газетасының 1917 елгы 14 июль саны

قورولتاى

«Корылтай» газетасы

Газета 1917 елның 2 июлендә (яңа стиль белән 16 июль) тарала башлый. Басманың үзендә: «Казанда пайтәхет гәзитәләре зурлыгында чыга торган «Корылтай» хәзергә атнасына өч мәртәбә (якшәмбе, сишәмбе вә пәнҗешәмбе көннәрдә) чыгып, тиз көннән көндәлек булачак», – дип хәбәр ителә. Газета – шул ук елның 7 мартында Казанда оешкан Мөселманнар комитетының басма органы.

Ф.Туктаров җитәкчелегендәге һәм 200ләп әгъзадан торган комитетның оештыру, финанс, агитация-пропаганда бүлекләре була. Алар урыннарда Мөселманнар комитетлары оештыру, Учредительләр җыенын чакыруны тизләтү, сугышны тәмамлау, крестьяннарны Төркестан һәм Себергә күчерүне туктату мәсьәләләрен күтәрә[1]. Мөселман комитеты, газетадан кала, «Учредительное собрание», «Безгә нинди җөмһүрият кирәк?», «Иске хөкүмәт ни өчен җимерелә?», «Швейцария

[1] Мөселманнар комитеты / Татар энциклопедиясе. 4 нче том. – Казан, 2014. – Б.264.

Нәҗип Хәлфин

Хәлил Әбелхан

төзелеше», «Җирне халык кулына алу» һәм башка шуның кебек сәяси эчтәлекле китаплар да бастырып тараткан. Әлеге комитетның «Сәяси вә икътисади мәсьәләләргә гаид кыйраәтханәсе» дә була. Уку залында, Русиядә чыга торган татар газеталарыннан башка, Петроград, Мәскәү һәм Казанда басылган һәммә рус газетларын, революция вакытында чыккан русча һәм татарча җыентык-китапларны укырга мөмкин булган. Комитет үзе Екатеринская урамындагы Татар укытучылар мәктәбе бинасында урнашса, аның басма органы булган «Корылтай» конторасы «Мәскәүски урамда, Апанаев подворьесының 6 нчы номерында» урнашып, иртәнге 9дан кичке 4кәчә эшләгән. «Йомышлы кешеләр»не баш мөхәррир төштән соң 4тән 5кәчә, ә сәркатип 1дән 2гәчә кабул иткән. Мөселманнар комитеты рәисе Фуат Туктаров газетаның баш мөхәррире вазыйфасын да башкарган. «Корылтай»ның шигаре – «Яшәсен кушма халык җөмһүрияте!» (Федеративная-демократическая республика) һәм «Яшәсен милли вә мәдәни мөхтәрият!» (Культурно-национальная автономия).

Матбугат белгече **Исмәгыйль Рәмиев** «Корылтай» хакында: *«Казанда революция дәверендә чыгарылган вак һәм эре буржа гәзит һәм журналларның атасы. 2 нче номерындагы баш мәкаләсендә: «Хөррият һәм иман – бездән, иршад – Алладан», – дип сүз бетерә. Башта гәзит ак кәгазьдә, зур кулда, бай мөндәриҗәле (эчтәлекле) булып чыкты. Һәр сәхифә 6 баганалы һәм 87шәр юлдан гыйбарәт була иде. Бездә күләме ягыннан иң зур чыгарылган шушы гәзит булды. Көндәлек, диелсә дә сирәгәйгәннән-сирәгәйде. Күләме кечерәйде, кәгазе дә сарыга әйләнде. Тәмам фәкыйрьләнеп калды. Язучылары да азайды. Гәзитнең техникасы шәп иде. Казанда «Өмид» типографиясендә басылып килде»*, – дип яза. Галим газетаның барлыгы 67 саны чыгуын һәм 1919 елның мартында Казан Мөселман комиссариаты тарафыннан ябылуын хәбәр итә. Ул «Татар вакытлы матбугаты» альбомында «Казан инкыйлаб штабы»ның приказын да китерә: «Казан мөселман комиссариаты тарафыннан төзелгән инкыйлаби штаб мөселманнар арасындагы фетнәне басу, гади тормышны юлга салу өчен бөтен чараларны кылды һәм халыкны курку вә тәшвишкә төшерә торган җәридә

(журнал) вә шәхесләргә каршы да мәрхәмәт вә галиҗәнаплык белән мөрәҗәгать кылды. Ләкин «Корылтай»ның 67 нче номерындагы баш мәкаләсе ачыктан-ачык провокация булганга халыкның тынычлыгы, революциянең ныгуы хөрмәтенә «Корылтай» гәзитәсе ябылырга һәм бөтен милке кулга алынырга һәм дә ширкәт әгъзалары вә күрсәтелгән «Корылтай» мөхәррирләре кулга алынырга карар бирелде. Рәис: Сәетгалиев, Харис Җомагыл. Сәркатип: Шәһид Әхмәдиев. Әгъзалары – Рәхмәтуллин[2]».

Мөселманнар комитеты рәисе һәм «Корылтай» газетасының баш мөхәррире Фуат Туктаров

«Корылтай»ның нәшире – «мөхәррирләр һәйәте». Актив язучылардан Җамал Вәлиди, Сәетгәрәй мирза Алкин, Газиз Гобәйдуллин, Хәлил Әбелхан, Габделбари Баттал, Нәҗип Хәлфин, Фәхри Әхмәд, Шәйхулла Алкин, Габдулла Шөнаси һәм башкалар була. Газета соңгы көннәрендә Гыйзәзетдин Сөйфелмөлеков мөхәррирлегендә чыга.

Галим Раиф Мәрданов «Корылтай» газетасының 1918 елның 23 августында (5 сентябрьдә), пәнҗешәмбе көн чыккан 90 нчы саны Татарстан Республикасының Тарихи-сәяси документлар үзәк дәүләт архивында табылуы хакында хәбәр итә[3]. «1918 елның 6 август-9 сентябрь көннәрендә Казан шәһәре ак чехлар кулында булганлыгы мәгълүм. Димәк, большевиклар тарафыннан ябылган «Корылтай» газетасы шул вакытта янә чыгып алган икән. Тик 1918 елның март аенда 67 нче санынннан туктатылган газетаның август саны 90 нчы булуы аңлашылып бетми. Рәсми туктатылса да, газета яшерен рәвештә чыгып, ул саннары сакланмаганмы? Сакланып та, безгә мәгълүм түгелме? Газетаның бу саны да, алдагылары кебек үк форматта, шундый ук начар сыйфатлы сары кәгазьдә. Ләкин 4 битле түгел, ә ике генә битле булып чыккан. Лозунглары үзгәрешсез, исеменең клишесе һ.б. техник чалымнары да әүвәлгеләреннән аермалы түгел. Нашире – мөхәррирләр һәйәте, мөхәррире – Габделбари Баттал булган бу нөсхә «Милләт» матбагасында басылган», – дип яза.

Газетада басылган кайбер хәбәрләргә күз салыйк.

---

[2] Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты: Альбом.1905-1925. – Казан: Гажур, 1926. – Б.64.
[3] Мәрданов Р. Вакытлы матбугатыбыз тарихыннан бер сәхифә // Гасырлар авазы. – 2001. – №3-4.

Сәяси имтиханнар

[...] Мәскәү кенәзләренә яу булып йөргән, аларны култыклап чиркәүгә йөрткән татар мирзаларының, татар ханлыкларын «Мәскәү» кул астына кертү юлында зур хезмәт вә һиммәт иткән «ханнар» вә бәкләрнең, рус самодержавиесенең тəрәге вә тугры хезмәтчесе булган чукынчык татар аксөякләренең исемнәре тарихларда калса да, чукынган татар олугларының ыруглары бу көндә һәм яшәсәләр дә, йөз елга якын тарихы булган рус хөррият хәрәкәтенә катышып, күзгә күренерлек роль уйнаган бер татарның булганлыгы мәгълүм түгел. [...]

Корылтай. – 1917. – 14 июль.

Ислам диненә кайту

Соңгы көннәрдә Мещанский управага православный булып язылган казан мещаннарыннан диндә хөррият игълан ителгәч православиедән ислам диненә күчәргә теләп гаризалар кергән. Бу кешеләр үзләренең һичбер вакыт православный булмаганнарын, аларны миссионерлар, поплар көчләп, аларның ризасыннан, кайвакыт алар белеменнән башка православный итеп яздырганнар. Әлеге гаризаларның күбрәге Пороховой бистәсендә торучылардан килә. Мещаннар управасы бу эшләрне үзе генә хәл кыла алмаганлыктан, шул хакта изах *(аңлатма)* сорап, губернский правлениегә мөрәҗәгать иткән.

Корылтай. – 1917. – 27 июль.

Казан, 4 нче август

Бөтен Русия мөселманнарының бу көндә иң әһәмиятле көннәре үтте. Олуг Казанымызда өч съезд булып узды. Голәмә съезды, хәрби съезд һәм икенче гомуми съезд. Өч съезд өчен дә, димәк, бөтен Русия мөселманнары өчен иң әһәмиятле булган ике мәсьәлә хәл кылынды: Эчке Русия мөселманнары өчен милли вә мәдәни автономия игълан кылынды. Димәк, милли вә мәдәни мәсьәләләрне, үз эшен үзе хәл кыла торган махсус бер ил хасил булды. Эчке Русия мөселманнары Милли идарәсе яхуд Татария.

Татария!

Нинди матур сүз!

Татария!

Икенче мәсьәлә – татар полклары ясау. Димәк, моннан соң татар солдатлары үз иптәшләре белән бергә ашап-эчеп, бергә өйрәнеп, бергә намаз укып, бергә рузә тотып, бергә уйнап, бергә җырлап, шау итеп торачак.

Әфитсәри татар, фельдфебельле татар!

Алга... бар!

Мылтык... ал!

Дүрт меңлек татар гаскәре, алдында атка атланган командиры белән, тантаналы рәвештә татар җырларын гөрелдәтеп җырлап урамнан узып китә! Моны күргән нинди татар шатланмасын, нинди татар карчыгы шатлыгыннан салават әйтә-әйтә егламасын!

Татар полклары, татар гаскәре, татар баһадирлары! Болар татарларның үзләре өчен бәхет вә сәгадәт булса, Русия өчен дә зур бер куәттер.

Татар гаскәре Русиягә дошманлык өчен түгел, бәлки Русияне көчәйтер, аның гаскәри куәтенә иске Чыңгыз гаскәренең рухын кертер өчен ясаладыр. Яшәсен татар гаскәре, яшәсен олуг Русия, олуг Русиянең милли нигезгә бина кылынган хөр һәм көчле гаскәре!

Милли вә мәдәни мохтәрияткә ия Татария!

Татар полклары, татар гаскәре!

Менә өч съездның тәсдыйк кылган ике мәсьәләсе:

Милли вә мәдәни мохтәрият булачакмы? Аны үзебезнең көчемез берлә башкарып чыга аламызмы? Аламыз, аламыз, алмасак, алырмыз! Аны мәйданга чыгару, акрынлап кую – киләчәк эше. Анысы үз эшемез.

Соң татар полклары, татар гаскәре булачакмы? Булачак, булачак! Ышанырга гына тиеш! Ышансак, ышанып эшләсәк, тырышсак, биш миллион татар бер агыздан сөйли алса, булачак һәм булыр!

Яшәсен татар гаскәре, яшәсен Татария!

Корылтай. – 1917. – 4 август.

Җомга көнге митинг

Казан губернасы Милли Шурасына Казан шәһәреннән вәкилләр сайлау мөнәсәбәте белән җомга көн сәгать 4тә Юнусовлар мәйданында митинг булды. Бу митинг мөселман комитеты тарафыннан пәнҗешәмбе көн сәгать 2дә, дип игълан ителсә дә, ул көн булмый калган иде. Пәнҗешәмбе көн Казандагы оешмаларның берләшүе белән ясалган спискадан башка, «Йолдыз» тарафыннан төзелгән икенче списка чыгарылган иде. Хәзрәтләр әлеге икенче списканы уздыру хакында җомгаларда халыкка сөйләп, халыкка мәйданда бу көн булачак җыелышка барырга дип аңлатканнар. Ишетелдегенә күрә, муллалар, үз спискаларын уздырырга катгый чараларга керешеп, үзләренең спискасын уздыру мөмкин булмаса, протест ясап, үзләренә ишләр ясаганнар.

Сәгать 3тә мәйданга җыелган халык төркем-төркем үзара фикерләр алыша иде. Бу төркемнәрдә күбрәк фикер сатучылар «шәригать эстәр»ләр иде. Сүзләр, Милли Шурага сайлау хакындагы киңәштән узып, хатыннар мәсьәләсенә күчкән иде. Хатыннар мәсьәләсе шулкадәр куерган иде, берникадәр хулиганнар мәйданга җыелган хатыннарга: «Китеңез моннан, сезгә монда ни калган?» – дип кычкыра башладылар. Бәгъзе хулиганнар, моның белән генә калмыйча, мәйданга кергән хатын-кызны тотып, куып чыгаралар иде. Шул арада хатын-кызны яклаучы Җарулла Хәйруллин дигән егетне «шәригатьче» хулиганнар бәргәләп тә алдылар.

Бу җыелыш урам җыены төсен алды һәм әлеге хәл дәвам иткәндә халык тынычлыгына хәвеф булганлыктан, тынычлык саклау өчен атлы милиция китерелде. Милиция килгәч, хулиганнар бераз инсафка килделәр. Габдулла мулла Апанаев чыгып, Милли Шурага сайлау хакында мөселман комитетына протест ясады. Шул арада мөнбәргә байтак кына муллалар менеп төштеләр. Прапорщик Хәлилулла Сафиуллин, Милли Шура хакында нотык сөйләп, бераз халыкны тынычландырырга муәффәкъ булды *(иреште)*. Насих Мохтаров Габдулла хәзрәткә җавап бирергә теләсә дә, халык: «Безгә хәзрәтләр сөйләсен!» – дип, аңа сөйләргә ирек бирмәделәр.

Социалистлар комитеты рәисе Мулланур Вахитов килеп халыкны тынычландырды һәм, мәҗлес тәртипле барсын өчен, Вахитовның үзен сайладылар. Шуннан соң гына халык Милли Шурага сайлау турында бертөрле тәртип белән сөйләшеп, бер-берсен аңлаша башладылар. Габдулла хәзрәт Милли Шурага сайлату комиссиясенең адресы белән тагын мәгънәсез протестлар ясап азапланды. Комиссия исеменнән Насих Мохтаров бу протестның урынсызлыгын күрсәтте. Соңрак, мәҗлес башындарак торган муллалар һәм бәгъзе байлар хәзрәтләргә сөйләргә ирек бирмиләр, дип, мәҗлестән чыгып киттеләр.

Корылтай. – 1917. – 18 август.

Текстларны басмага ***Рәйсә Шәрәфиева*** *һәм* ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №12 декабрь 2019

Гайнетдин Әхмәревнең тууына 155 ел

Затлы гаилә язмышы

Эльмира Сәлахова

«Волга вә Урал буйларында торучы мөселманнардан бу көннәргә кадәр өч тарихчы килеп китте. Болардан берсе – мелла Хөсәен Фәезханов, икенчесе – Мәрҗани вә өченчесе дә – ошбу Гайнетдин әфәндедер», – дип яза Ризаэддин Фәхреддин. Бу ике галим, беркайчан күрешмәсә дә, бер-берсенең иҗатыннан һәм хезмәтләреннән хәбәрдар була. Г.Әхмәрев Уфа тарафына баргач, олуг галим белән очрашырга уйлый, әмма күрешә алмый кала. Р.Фәхреддин, Г.Әхмәревнең мишәрләр һәм аларның теленә багышланган хезмәте дөнья күргәч, мәкаләнең әһәмиятен күрсәтеп һәм үзенең канәгатьлеген белдереп, авторга хат җибәрә. Мөселманнар арасында «типтәр» дигән кавем барлыгын әйтә, шул хакта өйрәнеп, тулырак мәгълүмат бирә алмассыңмы, дип тә мөрәҗәгать итә.


بلغار تاریخی

(تاریخ، آثار عتیقه وعلم الانساب جمعیتی اعضاسی عین الدین احمرفنڭ ۱۹۰۸ نجی سنه نویابر ۱۳ نده قزان شهرینڭ شرق قلوبنده خلقغه اوقوغان درسی).

КАЗАНЬ
Типографія Баянуль-ахбаръ
1909 г.


ОБЩЕСТВО
АРХЕОЛОГІИ, ИСТОРІИ И ЭТНОГРАФІИ
при
ИМПЕРАТОРСКОМЪ
КАЗАНСКОМЪ УНИВЕРСИТЕТѢ.

«26» мая 1904 года.
Казань.
№ 85.

Удостовѣрительное свидѣтельство.

Совѣтъ Общества Археологіи, Исторіи и Этнографіи при Императорскомъ Казанскомъ Университетѣ симъ удостовѣряетъ, что предъявитель сего действительный член Общества Гайнъ-ед-динъ Ахмаровъ состоитъ членомъ Общества, отъ котораго имѣетъ порученіе производить для Общества въ предѣлахъ Казанской губерніи

въ теченіи времени, на которое выдано настоящее свидѣтельство, различнаго рода изысканія, изслѣдованія и собраніе матеріаловъ, имѣющихъ отношеніе къ археологіи, исторіи и этнографіи

Вслѣдствіе сего Совѣтъ Общества покорнѣйше проситъ всѣ правительственныя и общественныя власти и учрежденія оказывать предъявителю настоящаго удостовѣрительнаго свидѣтельства всякаго рода законное содѣйствіе, а равно позволяетъ себѣ надѣяться, что и частныя лица, къ которымъ обратится предъявитель сего, не откажутъ въ просвѣщенномъ содѣйствіи своемъ задачамъ научной дѣятельности Общества.

Настоящее удостовѣрительное свидѣтельство дѣйствительно съ 26 мая 1904 года по 31 1905 года.

Подлинность свидѣтельства удостовѣряется надлежащимъ подписомъ и приложеніемъ печати Общества.

Предсѣдатель Общества Н. Катановъ



Гайнетдин Әхмәревнең «Болгар тарихы» китабы һәм аның шәхесенә бәйле документлар



قزان تاریخی

(قزان دار الفنونده تاریخ، آثار عتیقه وعلم الانساب جمعیتی اعضاسی عین الدین احمرفنڭ ١٩٠٩نچی سنه فیورال ١٢سنده شرق کلوبنده خلقغه اوقوغان درسی).

КАЗАНЬ.
Типографія газеты „Баянуль-хакъ“
1910 г.



Гайнетдин Әхмәрев һәм аның «Казан тарихы» китабы

Тел галиме Мөхетдин Корбангалиев хезмәттәше, дусты турында менәниләр язды: *«Без аны милли тарихымызга нигез салучы чын татар мөәррихе (тарихчысы), дияргә җөрьәт итәмез һәм дә исеме тарих сәхифәләрендә алтын кара белән язылып калырга тиешле мөхтәрәм бер зат, дия беләмез»*. Тарихчы Газиз Гобәйдуллин: *«Г.Әхмәрев татар галимнәре белән урыс галимнәре арасын бәйләп торучы иде, аның вафаты белән бу күпер җимерелде»*, – ди.

Замандашлары каршында ихтирам казанган тарихчы, педагог Гайнетдин Әхмәрев һәм аның фәнни мирасы, гаиләсе хакында безгә ниләр билгеле? Хәл кадәри шуларны барлап карыйк.

***

Гайнетдин Әхмәрев 1864 елда Тау ягындагы Татар Наратлысы авылында дөньяга килә. Әтисе Нәҗметдин сәүдә белән шөгыльләнсә, аның ике улы мәгариф юлын сайлый: мәдрәсә, аннары Татар укытучылар мәктәбен тәмамлый.

Галим, Ш.Мәрҗани традициясен дәвам итеп, татар халкының формалашу тарихы катлаулы һәм күпкырлы булуын искәртә. Татар кешесенә империя шартларында урыс теле аша киң даирәдә эш итү, Европада барган үзгәрешләрдән хәбәрдар булу

кирәклеген ассызыклый. Аның фикеренчә, милләтнең нигезе, терәге ана теле булса, урыс теле арадашчы тел булырга тиеш. Замандашларыннан аермалы буларак, галим гомумтөрки тел идеясе белән мавыкмый, киресенчә, аңа каршы була. Г.Әхмәрев «Тел саклау хакында» дип аталган мәкаләсендә: *«Ник сез, ата-бабаларыбызның теленнән нәфрәтләнеп, китапларыгызны төрекчә (госманлыча) язасыз?» – дип сораганыбыз бар. Бу әфәнделәрнең максатлары төрек телен бөтен Русия мөселманнарына аңлатып, гомуми бер әдәби тел итеп калдыру икән, ләкин бу бик мөшкел. Урысча укыган яшьләребез, образование күрсәтү өчен, телләрендә күбрәк урыс сүзләрен йөртәләр һәм хатларын да урысча язалар. Без боларның һәркайсын татарча язабыз, бәлки наданлык сәбәпле шулай яза, дип уйларлар. Телебезгә һич зарурсыз гарәп вә фарсы, төрек вә урыс сүзләре кереп, үземезнең шулар бәрабәрендәге сүзләр һаман югала вә онытыла бара»,* – дип яза. Галимнең йөз ел элек әйткән бу сүзләре хәзерге заман өчен дә актуаль.

Гайнетдин Әхмәрев татар баласын белемле, киң карашлы итәргә омтылган. Әмма Тәтештә укыткан елларында аңа шәһәр мулласы Хәсәнгата Бикташевның янаулары, өстеннән язган доноСлары белән көрәшергә туры килә. Мөгаллим үзе дә Тәтештә эшләү елларын бер елы ун елга тиң сәламәтлегемне алды, дип искә алган. Халыкның әхлагын, матур киләчәген кайгырту өчен хезмәт иткән ике шәхестә фикер каршылыгы татар җәмгыяте өчен табигый хәл. Әмма Гайнетдин Әхмәрев конфликтлы кеше булмый. Ул педагогик эшчәнлеге белән татарларны алдынгы милләтләр дәрәҗәсенә күтәрү өчен шартлар тудыруга хезмәт итә. 1900 елда Гайнетдин Әхмәрев укыткан Тәтеш шәһәре мәктәбе Парижда узган Бөтендөнья күргәзмәсендә җиңеп чыга һәм «Укыту эшенең югары дәрәҗәдә куелуы» өчен мактау дипломына лаек була.

1903 елда Казанга күчеп килгәч, Гайнетдин Әхмәревнең гаиләсе, ел саен диярлек тору урынын алыштырып, төрле фатирда яшәсә дә, эшчәнлегендә күп яклап уңышка ирешә. Галим татар балаларына урыс теле укытканда, хатыны – морза нәселеннән булган Бибисара Сакаева мәдрәсә бинасын юып-җыештырган. Гайнетдин Әхмәрев Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең иң эшлекле әгъзасына әйләнә, Болгар, Биләр, Ябынчы шәһәрлекләренә экспедицияләр оештыра. Аның экспедицияләрдә тапкан тарихи материаллары башта җәмгыять музеенда, хәзерге вакытта Россия этнографик музеенда саклана.

Г.Әхмәрев актив җәмәгать эшчәнлеге дә алып бара: 1896 елдан башлап, Казан губернасы укытучыларының үзара ярдәмләшү җәмгыяте әгъзасы булып тора, 1907 елдан Казан мөселман хәйрия җәмгыяте эшчәнлегендә катнаша.

Гайнетдин Әхмәревнең галим һәм җәмәгать эшлеклесе буларак таланты «Шәрык» клубында ачыла. Ул – клубны оештыручы 12 кешенең берсе. 1908 елның 13 гыйнварында җәмгыятьнең Аксакаллар шурасына сайлана, төрле комиссияләр әгъзасы булып тора. 1910 елның 29 апрель җыелышында галимне «Шәрык» клубы рәисе итеп куялар.

Г.Әхмәревнең «Шәрык» клубында укыган лекцияләре аеруча мәхәббәт казана. Галим Казан ханлыгының Болгарга мөнәсәбәтен тикшерә. Ул шанлы ике дәүләт тарихи процесста бер-берсенең дәвамымы яисә аерым, мөстәкыйль сәяси берләшмәләрме, дигән проблеманы куя һәм үз фикерен дәлилли. Казан шәһәренең барлыкка килү тарихын, исеменең килеп чыгышын тәфсилләп өйрәнә. *«140 мең нөфүсле (халыклы) бер зур шәһәр булып, бөтен шәркый Русия, хәтта Кавказ, Урта Азия вә Сибирия вилаятьләре өчен дә һөнәр, сәнагать, гыйлем вә мәгърифәт хәзинәсе булып саналганлыктан, һәм дә, әүвәлдә үзе мөселманнарның бабалары – болгар сәүдәгәрләре тарафыннан төзелеп, ике йөз микъдары пайтәхет (башкала) булып, ханнарның шунда торганлыкларыннан, безем мөселманнар өчен Казан тарихын белү кирәкле иде.*

Аннан соң Казан тарихы башка шәһәрләр тарихы кебек кенә булмыйча, кызыклы вә гыйбрәтле хәбәрләрне шамил (үз эченә алган) булганлыктан, моның тарихы бер безнең өчен генә дә әһәмиятле булмыйча, башка халыклар өчен дә әһәмиятле иде», – дип әйтә ул. Г.Әхмәревнең Казан ханлыгы тарихы турындагы мәгълүматы, лекция кысаларына гына сыеп бетмичә, «Бәянелхак» нәшрияты тарафыннан аерым китап итеп басылып чыга. Сүз уңаеннан шуны да әйтим: хәзерге көндә башкалабыз Казанның күркәм бер урамы атаклы тарихчы Гайнетдин Әхмәрев исемен йөртергә тиеш!

Шул чор вакытлы матбугатында басылган тәгъзияләргә караганда, Гайнетдин Әхмәрев 1911 елның 21 сентябрь көнне 47 яшендә «озак заманнар хасталыктан соң вафат» була.

***

Гайнетдин Әхмәрев белән Бибисара Сакаеваның 12 баласы дөньяга килеп, шуларның җидесе кече яшьтә үк бакыйлыкка күчә. Галимнең вафатыннан соң, хатыны биш бала белән тол кала.

Гайнетдин Әхмәрев балаларын да үзенең лаеклы дәвамчылары итеп тәрбияли. 1888 елда дөньяга килгән олы улы **Исмәгыйль** әтисе исән вакытта ук танылып өлгерә. Шәкертләр газетасы «Әл-ислах»та Исмәгыйль Әхмәревнең гимназияне яхшы билгеләргә генә тәмамлавы турында хәбәр басыла. Казан Император университетының хокук бүлегендә укыган елларында ук тәрҗемә белән шөгыльләнә. Ике телне берүк дәрәҗәдә белгән яшь белгечне тюрколог Николай Катанов күреп алып, үзе җитәкләгән «Инородческое обозрение» кушымтасы өчен татар матбугатыннан хәбәрләрне, аерым язмаларны тәрҗемә иттертә. «Инородческое обозрение» – Казан шәһәрендә руханилар академиясендә «Православный собеседник» журналының кушымтасы буларак чыга. Бу вакытта әле укып кына йөргән егет өчен әлеге эш күпмедер дәрәҗәдә тәҗрибә туплау һәм аз булса да хезмәт хакы алу мөмкинлеге бирә. Әтисе Г.Әхмәревнең вафаты уңаеннан язган некрологында М.Корбангалиев: *«...Һәм дә зур углы Исмәгыйль әфәндене бу сәнә (ел) дарелфөнүнне (университетны) хәере берлә тәмам итеп, атасы урынына бер милләтне сөюче, милләткә хезмәт итәрлек бер кадир (кодрәтле) кеше булгай иде, дия, дога кылабыз. Безнең хәзерге вакытта иң кыйммәтле, мисле аз булган милли тарихыбызга нигез салган мәрхүмнән аерганы өчен, Аллаһы Тәгалә ярдәмсез калдырмаенча, аның урынына Исмәгыйль әфәндегә атасының каләмене насыйп иткәй иде»*, – дип язган була. Кызганыч, лаеклы дәвамчы булыр, милләткә хезмәт итәр, дип зур өметләр багланган егет, әтисе вафатыннан соң ике ел узгач, 1913 елның 14 октябрендә бакый дөньяга күчә. Исмәгыйльнең дә, әтисе Гайнетдиннеке кебек үк, кабере билгесез.



Исмәгыйль Әхмәрев

Гайнетдин Әхмәревнең икенче улы

Ильяс та шул заманның билгеле шәхесе – офицер дәрәҗәсендәге хәрби кеше була, Беренче Бөтендөнья сугышында катнаша, ике мәртәбә яралана, мактаулы хезмәте өчен берничә тапкыр дәүләт бүләгенә дә лаек була. 1915 елгы «Аң» журналында һәм 1916 елгы «Заман календаре»нда Ильяс Әхмәревнең хәрби киемнән төшкән фотосурәте басыла. Хәрби егет кыска вакыт эчендә заманча карашлы татар яшьләре арасында ихтирам казанырга өлгерә. Әмма аның алдагы язмышы хакында мәгълүматыбыз юк, кабере дә билгеле түгел. Хатыны Рауза Солтан кызы атаклы Янышевлар нәселеннән икәне, аларның Илтөзәр исемле уллары туганлыгы мәгълүм. Илтөзәрнең улы Әскәр Әхмәрев – химия фәннәре кандидаты, галим.

Ильяс Әхмәрев

Г.Әхмәревнең 1891 елда туган **Зәйнәб** исемле кызы да XX йөз башында мәгърифәтле, укымышлы туташ булып җитешә. Тәтештә яшәгән елларында гимназия тәмамлый. 1904 елда имтиханнар тапшырып, Казан шәһәрендәге кызлар гимназиясенең (Казанская Мариинская женская гимназия) икенче сыйныфына укырга керә. Әтисе вафат булган 1911 елда, уку йортын яхшы билгеләргә генә тәмамлап, башлангыч сыйныф укытучысы белгечлеге ала. Өметле татар кызының язмышы 1917 елгы вакыйгалардан соң ничек булганын төгәл әйтә алмасак та, аның гомере озын булмаганы билгеле. Фаҗигале 1937 елда Гайнетдин Әхмәревнең бары тик бер улы – **Сәедгәрәй** генә исән була.

1904 елның 31 гыйнварында туган **Зәйтүнә** исемле кызның язмышы турында да мәгълүмат юк.

1902 елның 24 апрелендә дөньяга килгән Сәедгәрәй башта «Госмания» мәдрәсәсен, аннары абыйлары кебек үк, гимназия тәмамлый. 1920 нче елларда Эстәрлетамак шәһәрендә Халык мәгариф комиссариатында, аннан соң Уфада эшли. Казанда Совнарком һәм Планлаштыру комиссиясенең партия коллективы секретаре вазыйфаларын башкара. Бервакыт чәй эчеп утырганда, татар зыялысының улы буларак, илдә алып барылган милли мәсьәләгә белдергән мөнәсәбәтен яман зат органнарга җиткерә.

Зәйнәб Әхмәрева

Сәедгәрәй Әхмәрев

Шулай итеп, Сәедгәрәй 1937 елның 8 июлендә «троцкистлыкта һәм советка каршы милли агитация» алып баруда гаепләнеп кулга алына һәм Коммунистлар партиясеннән чыгарыла. Ун елга ирегеннән, биш елга сәяси хокукларыннан мәхрүм ителә, барлык мал-мөлкәте конфискацияләнә. С.Әхмәревнең кулга алынуы хезмәттәшләре, танышлары өчен көтелмәгән хәбәр була. Якыннан белгән кешеләр аңа тагылган гаепне раслалык бер генә дәлил дә китерә алмыйлар. Сәедгәрәй 1939 елда, эшен яңадан тикшерүне сорап, төрмәдән СССР Югары Советы Президиумына хат юллый. Озакламый хатыны Мария Яковлевнаны да биш елга хөкем итәләр. Гаиләдәге өч сабый төрле балалар йортларына җибәрелә. Иң олысына – өч, уртанчысына – ике яшь, кече сабыйларына бары тик алты ай гына була.

Гайнетдин Әхмәревнең хатыны – улы Сәедгәрәйнең гаиләсендә яшәгән, 12 бала тудырган 70 яшьлек Бибисара карчык әлеге хәлләрдән соң кайларда көн күргән? Бу хакта да төгәл генә әйтеп булмый. Улы кулга алынып, гаиләсе туздырылганнан соң, Мөхетдин Корбангалиев аны үзенә сыендырган булырга тиеш, дигән фикер бар. Бибисара Әхмәреваның кабере билгеле. Ул 1950 елда вафат була һәм Казан шәһәренең татар зиратына, Янышевлар нәселе кешеләре янына җирләнә. Янәшәдә оныгы – улы Ильясның баласы Илтөзәрнең дә кабере бар. Димәк, без Бибисараны соңгы елларда килене (Янышевлар нәселеннән), оныклары гаиләсендә яшәгән, дип уйлый алабыз.

Гайнетдин Әхмәревнең бар архивы, китаплары, матбугатта дөнья күрә алмый калган хезмәтләренең кулъязмасы хатынында калып, улы Сәедгәрәйне кулга алганда юк ителә, язып үткәнемчә, өйдәге бар мал-мөлкәт тартып алына.

Сәедгәрәй Әхмәрев шул китүеннән соң туган җирен бер мәртәбә дә күрә алмый. Җәзаны ул Красноярск өлкәсендәге Норильск лагеренда үтә. Срогы тәмамлангач та туган җиренә кайту хокукыннан мәхрүм ителә. Гаиләсен үз янына китерергә мөмкинлеге, моның өчен тору урыны да, юлга акчасы да булмый. Бары тик әтисеннән алты айлык вакытта аерылган улы Эльвир гына Норильскига күченә.

2000 нче елларда без, Гайнетдин Әхмәревкә багышлап «Шәхесләребез» сериясеннән китап әзерләгәндә, Сәедгәрәй Әхмәревнең балаларын, оныкларын эзләп таптык. Улы Эльвир абый Әхмәрев безгә әтисе Сәедгәрәйнең чын татар зыялысы булуы хакында елый-елый сөйләде. *«Анда әти кебек хөкем ителеп, туган җиренә кайтудан мәхрүм ителгән татарлар күп иде, алар, бергә җыелышып, татарча җырлап, туган җирләрен сагынып, елап өзгәләнәләр иде,* – дип искә алды. – *Әтине мин үз кулларым белән мөселманча җирләп кайттым»*, – диде.

Казан университетының физика факультетын тәмамлап, Мәскәү өлкәсенең Пушкино шәһәренә эшкә җибәрелгән Эльвир абый бар гомерен шунда үткәрә. Ул язган хатлар аша Гайнетдин Әхмәревтә булган затлылык, зыялылык, тыйнаклык аның улы Сәедгәрәйдә дә дәвам иткәнлеге беленде. Эльвир абый үзе дә гаять итагатьле, тыйнак,

намуслы кеше иде. Ул әтисенең каберен зыярәт итә алмавына өзгәләнде, җәсаден ата-бабасы җиренә алып кайту мөмкинлегенә өметләнде. Әтисенең каберен зыярәт итәр өчен ярдәм сорап, дини оешмаларга, Казан шәһәре түрәләренә мөрәҗәгатьләр язса да, ярдәм кулын сузучы табылмады. Миндә Эльвир абыйның әтисе турындагы хатлары саклана. Гайнетдин Әхмәревнең лаеклы улы, татар халкының асыл егете Сәедгәрәй Әхмәрев хакында киләчәктә аерым мәкалә язу кирәк булыр.

Сәедгәрәй Әхмәревнең олы улы – Вилен Тимер юл училищесын тәмамлый, Чкалов шәһәрендә паровоз төзекләндерү заводында, аннан соң автомобиль йөртүче булып эшли. Өч яшь ярымда гаиләсеннән аерылган, язмыш җилләре Украинага кадәр илтеп ташлаган бу бала асыл исемен, фамилиясен, әтисе исемен дә югалта. Аңа урысча исем-фамилия бирәләр. Әмма кан тартуы үзенекен итә: Вилен, гаилә башлыгы булгач кына, әнисен эзләп, Казанга кайта. Аннан туган балалар – Ирина һәм Вилен, озак вакыт әтиләренә бирелгән урыс фамилиясе белән йөрсәләр дә, ир уртасы яшенә җиткәч, абыйлары Эльвир Әхмәрев киңәше белән, ата-бабай фамилиясен кайтардылар. Бүген алар – Әхмәревләр.

Икенче улы Лерун Оренбург балалар йортында тәрбияләнә. Барлык киртәләрне үтеп, Казан Ветеринария институтын тәмамлый. Авыл хуҗалыгы министрлыгында, ТАССР Министрлар Советының Эшләрне оештыру идарәсендә эшли.

Әтиләре Сәедгәрәй Әхмәрев 1953 елда Норильскида вафат була. Аның исеме, балаларының зур тырышлыгы нәтиҗәсендә (алар берничә мәртәбә К.Е.Ворошиловка, Н.С.Хрущевка, СССРның генераль прокурорына хат яза), 1957 елның 6 октябрендә аклана.

Мәрхүмнең оныклары, оныкчыклары хәзерге көндә танылган эшкуарлар һәм спортчылар.

***

Г.Әхмәревнең энесе **Шәрәфулла** да, абыйсы кебек, укытучы була. Ул «Госмания» мәдрәсәсе шәкертләренә урыс телен өйрәтә, вакытлыча уку йортының җитәкчесе – мөдәррис тә була. Мөгаллимнең мәдрәсә шәкертләре өчен язган дәреслекләре дә бар. XX гасыр башында эше гөрләп барган яшь егетнең – өметле укытучының Октябрь инкыйлабыннан соңгы язмышы билгеле түгел. Аның нәсел дәвамчылары булганмы, юкмы – архив документлары болар хакында да берни дәшми.

Гайнетдин Әхмәревнең әтисе ягыннан бертуган абыйсы, аның нәселен дәвам итүчеләр Татар Наратлысында яшәп кала. Бу авылда йорт сатып алып, җәй көннәрен шунда үткәргән остазым, академик Миркасыйм ага Госманов Әхмәревләрне хәтерләгән бабайдан ишеткәннәрне сөйләгән иде. Ул карт: *«Гайнетдин Әхмәревнең әтисе – Нәҗметдин абзыйга пароходка утырып сәүдәгәрләр килә иде»,* – дип әйткән. Сәүдәгәрләрнең авыл яныннан аккан мул сулы Гөбенә елгасы аша көймәләрдә килүләрен бабайның истә калдырган булуы бик ихтимал. Гайнетдиннең дә, балалары белән авылга кайтып, көймәдә йөзеп ял иткәнен хәтерләүчеләр бар иде, диләр.

Нәҗметдиннең абыйсы Шәрәфетдиннең нәсел дәвамчысы булган **Илсур Касыймов**, Гайнетдин абзасы кебек үк, тарих белән кызыксына, география укытучысы булып эшли, борынгыдан калган әйберләрне җыеп, үз йортында этнографик музей да эшләп куя. Бу егетнең төбәк тарихына ихтирамы Гайнетдин Әхмәрев эшчәнлегенең тәүге елларын хәтерләтә...

Таш белән бастырсалар да, ташны ватып чыгып, яңадан тернәкләнгән гөл кебек бу нәсел. Ул яшәвен дәвам итә, лаеклы дәвамчыларын тәрбияли. ■

РУХИ ХӘЗИНӘБЕЗНЕ *барлаганда*

Хатыйп Миңнегулов

Ярты гасырдан артыкка сузылган гыйльми-педагогик эшчәнлек барышында мин фәкыйрегезгә илебезнең күп кенә төбәкләрендә, дистәләгән чит мәмләкәтләрдә булырга, төрледән-төрле кешеләр белән аралашырга туры килде. Бу сәфәр-сәяхәтләрнең, әңгәмә-аралашуларның рәвеш-формалары төрле булса да, аларның төп асылы, мәркәзи максаты, нигездә, халкыбыз белән ныграк танышуга, аның рухи мирасын тирәнрәк һәм тулырак аңлауга, өйрәнүгә юнәлтелгән

иде. Бу яктан махсус экспедицияләр аеруча нәтиҗәле булды. Университеттагы уку-укыту планы нигезендә беренче, икенче курслардан соң (җәйнең ямьле чорында!) студентларның ике атналык практикасы каралган. Ул, гадәттә, илебезнең татарлар яши торган төрле төбәкләренә барып, фольклор, диалектологик, археографик материалларны җыю, туплау рәвешендә уза. Бу төр экспедицияләр вакытында студентлар дөнья күрә, халык, аеруча мәктәп балалары белән аралаша, концертлар куя. Шуңа күрә алар булачак филологлар (укытучылар, галимнәр, әдипләр, журналистлар...) күңеленә үзенә күрә бер тормыш мәктәбе, матур бер истәлек рәвешендә кереп кала. Мондый практикада мин студент вакытымда да ике мәртәбә булган идем (Ульяновск өлкәсенең Мәләкәс, Малыклы, Төгәлбуга якларында, Татарстанның Кайбыч, Апас тарафларында. Җитәкчеләребез Хәләф Гарданов, Гомәр Саттаров иде). Ул вакытта күргән-кичергәннәр, кызыклы хәл-вакыйгалар хәзергәчә күңелдә якты бер хатирә рәвешендә сакланып килә.

Казан университетында эшләү чорында (аеруча 1968-1984 елларда) миңа студентларның дистә ярымнан артык экспедициясе белән җитәкчелек итәргә туры килде. Алар Чиләбе (Конашак, Мөслим...), Оренбург (Саракташ, Кувандык...), Башкортстан (Бакалы, Яңавыл, Борай, Караидел...), Горький (Пилнә, Кызыл Октябрь, Сергач...), Чуашстан (Батыр...), Ульяновск (Иске Кулаткы...), Пермь (Барда, Көңгер, Суксун, Березовка, Лысьва...), Свердловск, Татарстан (Чаллы, Зәй...) һәм кайбер башка өлкә һәм республикаларда, төбәкләрдә узды. Бу экспедиция-сәфәрләр вакытында студентлар күптөрле фольклор материалларына, язма истәлекләргә тап булдылар. Алар хакында конференция-кичәләрдә докладлар ясадылар, курс һәм диплом эшләре яздылар, матбугатта чыгыш ясаучылар да булды. Практика йомгаклары рәвешендә уздырылган махсус кичәләр еш кына зур аудиторияләрне җыя иде.

Халык авыз иҗаты әсәрләреннән тыш, без гарәби язулы ядкярләрне туплауга аеруча зур игътибар итә идек. Шунысы гыйбрәтле: әлеге төр язма истәлекләрнең, төрле тыюларга, афәтләргә дә карамастан, татарлар яши торган төбәкләрдә күпләп очравы, саклануы хәтердә калган. Бу үзе үк Евразиянең киң мәйданнарында яшәгән милләттәшләребезнең элеккеге чорлардагы эчке бер бөтенлеген, уртак бер рухи дулкында гомер кичерүен күрсәтеп тора.

Миңа шулай ук студентларның Ленинград, Мәскәү, Баку, Ереван, Тбилиси калаларында узган музей практикасы белән дә җитәкчелек итәргә туры килде. Андый сәфәрләр вакытында да, гәрчә бик күп булмаса да, аерым язма истәлекләр кулга кергәләде.

Югары уку йортларында укытучы-мөгаллимнәрнең биш елга бер мәртәбә 3-4 айлык стажировка узуы каралган. Андыйларны мин Ленинград (ике тапкыр), Мәскәү, Ташкент, Дүшәнбе калаларында үттем. Бу төр стажировкалар гыйльми, һөнәри үсешемә бик нык ярдәм итте: китапханә-архивларда эшләдем, үзгәләрнең тәҗрибәләрен өйрәндем, милләттәшләр белән дә очраштым; кулыма шактый гына китап һәм кулъязмалар да керде.

1990 елда мин Финляндиядә (Хельсинки, Тампере һәм Турку калаларында) өч айлык гыйльми командировкада булдым. Көне – айга, ае елга торырлык бу сәфәр мине рухи яктан бик нык баетты, күңел офыкларын киңәйтте. Китапханә-архивлардан шактый гына копия-күчермәләр алдым, Суомидагы милләттәшләребез күптөрле язма истәлекләр бүләк итте. (Моның өчен мин Финляндиядәге кавемдәшләребезгә хәзер дә кат-кат рәхмәтләр укып торам.)

Мин фәкыйрегез илебездә һәм чит мәмләкәтләрдә (аеруча Казакъстанда һәм Төркиядә) уздырылган конференцияләрдә, төрле чараларда еш булып тора. Андый чаралардан да китап һәм кулъязмасыз кайтканым юк. Студентлар, укытучылар, гыйлем әһелләре һәм, гомумән, төрле катлам вәкилләре миңа китаплар, бигрәк тә гарәби



«Ибне Гарәби». Р.Фәхреддин

язулы ядкярләрне бүләк итәләр. Үзем дә, кайда йөрсәм дә, гомумән, китап сатып алырга яратам. Үз чиратында, Хатыйп Йосыф угылы да саранлык күрсәтми: үзендәге рухи хәзинәләрне гавам белән уртаклашырга тырыша. Кулыма кергән, бүләк ителгән күп кенә китап һәм кульязмалар минем хезмәтләремдә шактый мул файдаланылды. Әһәмиятле дип тапкан әсәрләрнең, материалларның зур өлешен мин гәҗит-журналларда, китапларымда бастырып чыгардым. Болар арасында Финляндиядәге кавемдәшләребез бүләк иткән Гаяз Исхакый, Хәсән Хәмидулла, Сания Гыйффәт кебек мөһаҗир әдипләрнең язганнары, «Яңа милли юл», «Яңа япун мөхбире», «Kazan» журналларындагы материаллар мөһим урынны алып тора.

Бәлкем, кайберәүләр гаҗәпсенә дә торгандыр: мин үземнең басылып чыккан китапларымны (аларның саны җиде дистәгә якын) һәм, гомумән, мәкалә-хезмәтләремне (барлыгы – меңнән артык) үзгәләргә бүләк итәргә яратам. (Укыймы, актарып рәсем-иллюстрацияләрен карап чыгамы – анысы аларның эше. Бирүем хак булсын!) Шуның кебек башка авторларның хезмәтләре дә миндә хәрәкәтсез ятмый. Нигездә, теге яки бу дәрәҗәдә үзем файдалангач, мин аларны үзгәләргә биреп торам (аларның бер өлеше, бигрәк тә студент-аспирантларга биргәне кире дә кайтмый) яисә бүләк итәм. Студентлар белән экспедицияләрдә йөргәндә тупланган материалларның шактыен ел саен Казан университеты китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегенә тапшырып килдем. Минем өчен бик тә якын, газиз булган бу уку йортының Лобачевский исемендәге гыйльми китапханәсенә, гомумән, мин күп мәртәбәләр шактый гына (мөгаен, барлыгы берничә йөздән артыктыр) китаплар бүләк итеп торам. Алар арасында зур урынны гарәби язулы кульязмалар, басмалар алып тора. Арада төрек, казакъ, үзбәк, инглиз һәм кайбер башка телләрдәге китаплар да бар.

Татарстан Милли китапханәсе дә минем өчен кадерле-якын. Аеруча аның милли бүлегенә еш кереп торам. Бирелә эшләүче кызлар-ханымнар (күбесе – безнең элеккеге студентлар) һәрчак ачык йөз белән каршы ала, үтенечемне шундук канәгатьләндерә. Бу изге йортка даими рәвештә халкыбызга теге яки бу дәрәҗәдә мөнәсәбәтле шактый гына китаплар бүләк иттем. Мәсәлән, Финляндиядән, Төркиядән, Казакъстаннан алып кайткан күп кенә материалларны Милли китапханәгә тапшырдым (Алла боерса, әле тагын да бүләк итәргә теләгем бар). Мәгълүм ки, Төркия галимәсе Фатма Өзкан 1994 елда Анкарада «Габдулла Тукай шигырьләре» исемле мең битлек (төгәлрәге, 958 битлек) китап чыгарган иде. Анда бөек шагыйрьнең шигырьләре латин хәрефләре белән татар телендә һәм төрекчәгә тәрҗемәдә бирелгән. Җыентыкның шактый өлешен Фатма Өзканның Тукай турындагы гыйльми тикшеренүләре алып тора. Узган гасыр ахырларында (Анкарага баруларымның берсендә) төрек хезмәттәшләрем (коллегаларым) миңа дүрт данәдә шактый саллы бу җыентыкны бүләк иттеләр. Өстәвенә, башка


بطال.

تاتار تاريخى

(رشدى مكتبلر ئوچون درسلك).

بلغارلر - تاتارلر - بيوك ماغول ايمپراطورلغى - آلتون اوردا دولتى - قزان پادشاهلغى.

2055

مؤلفنك اوز نشرى.

КАЗАНЬ.
Электро-типографія „УМИДЪ"
1912.

«Татар тарихы». Г.Баттал


ПРОВЕРЕНО 2008 г.
ХАКИМОВЪ

كتاب مستطاب

محمدية

از تصنيفات قطب العارفين

محمد چلبى

الملقب به يازيجى زاده

КАЗАНЬ.
Типографія Торговаго Дома Братьевъ Каримовыхъ.
1900 г.

«Мөхәммәдия». М.Чәләби

китаплар да бар. Нишләргә? Калдырып китәсе килми. Багаж өчен өстәмә түләп, аларны Казанга алып кайттым. Бөек Тукаебызның төрекчә басмасын Милли китапханәгә, Лобачевский китапханәсенә, Тукай музеена бирүемне хәтерлим.

Республикабызның Милли, Тукай, Исхакый музейларында, Казанның Милли-мәдәни үзәгендә, аерым уку йортларында без бүләк иткән материаллар бар. 2000 елда, президент Н.Назарбаев чакыруы буенча, Төркестан каласының 1500 еллык бәйрәм чараларында катнашкан идем. 2004 елның көзендә мине бу шәһәрдәге Халыкара казакъ-төрек университетының «Шәрәфле профессоры» итеп сайладылар. Шул уңай белән без фәкыйрегезгә бүләк ителгән мантия-чапаннарның берсен Хатыйп Йосыф угылы Татарстан Милли музеена, икенчесен К.Тинчурин исемендәге театрга бүләк итте. Бу уңай белән шунысын да искә төшереп үтик: күренекле галим, әдип Күлбәк Ергобәк башлангычы белән, Төркестан каласында «Төрки китабы» китапханәсе оештырылды. Бу искиткеч бай мирасханәдә без тапшырган татар китаплары бүлеге дә мөһим урынны алып тора. Аңа хәтта без фәкыйрегезнең исеме дә бирелгән. Астанадагы «Халыкара төрки академия»нең уку залында да мин тапшырган йөзәрләгән китап бар. Ленинград, Ашхабад, Төмән, Истанбул, Уфа, Әлмәт һәм кайбер башка калаларның китапханәләренә дә китаплар бүләк иткәләдем.

Элегрәк мин, нигездә, китапханәләргә, музейларга үзем биргән материалларны күп очракта исем-фамилиямне күрсәтмичә генә һәдия кыла идем. Соңгы вакытта андыйларга еш кына «Личная библиотека профессора Х.Ю.Миннегулова» дип язылган штамп сугып бирәм.

***

Мәгълүм булганча, Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты составындагы «Мирасханә»дә халкыбызның тарихына, әдәбиятына, мәдәниятенә кагылышлы искиткеч бай рухи хәзинә тупланган.

Без аның белән инде шактый еллар буе хезмәттәшлектә. Хатыйп Йосыф угылы әлеге «Мирасханә»не баетуга да сизелерлек өлеш кертеп килә. Минем инде аңа шактый гына кулъязма һәм басма китаплар, төрле материаллар бүләк иткәнем бар. [Сәйф Сараи әсәрләрен туплаган «Китабе Гөлестан бит-төрки»нең (ул Лейденда саклана) һәм «Ядгярнамә» кульязмаларының күчермәләре; Шәмседдин Зәки шигырьләренең мәҗмугасы; фольклор материаллары һ.б.]

2018 елның февраль аенда «Мирасханә»гә үземнең шәхси китапханәмнән йөзгә якын басма һәм кулъязма китап бүләк иттем. Төрле елларда җыелган, төрле куллардан кергән бу материаллар төрле характерда. Болар арасында Г.Кандалый, Г.Чокрый, К.Насыйри, Х.Әмирхан, Г.Исхакый, Ф.Халиди, Р.Фәхреддин, М.Гафури, Г.Тукай, Г.Рәшиди кебек соңгырак чор авторларының басма һәм кулъязма әсәрләре бар. Шулай да «Әхмәд Ясәви хикмәтләре», «Кыйссаи Йосыф», «Кыйссасел-әнбия», «Мөхәммәдия», «Бакырган», «Кыйссаи Сәйфелмөлек», Өмми Кәмал, Гашыйк Гомәр шигырьләре шикелле Борынгы һәм Урта гасыр ядкярләре төп урынны били. Бәет-мөнәҗәтләр (аеруча «Сак-Сок», «Хикәяте Хуҗа Насреддин»), «Уку» китаплары, дини-әхлакый, тарихи язмалар, сүзлекләр дә бар. Элегрәк төрле характердагы берничә әсәрне бергә туплап, бер төпләм, бер җыентык рәвешендә куллану да киң таралган. «Мирасханә»гә тапшырган язмалар арасында андый тупламнар да бар. Мәсәлән, Барда районында табылган бер ядкярдә «Кыйссаи Бүз егет», «Җәмилә», «Бигаяте Мәгъшукнамә», «Бер шәкерд илә бер студент», «Низам һәм канунлар» кебек әсәрләр бер төпләмдә бирелгән. Октябрь инкыйлабына кадәр күп кенә зыялыларыбыз, үз туган теленнән тыш, гарәп, фарсы, госманлы телләрен дә яхшы белгән. Шуңа мөнәсәбәттә, ул телләрдәге китаплар Иделйортта киң таралган. «Мирасханә»гә бүләк ителгән материаллар бу тарихи чынбарлыкны янә бер мәртәбә искә төшереп тора. Аурупа телләреннән тәрҗемәләр дә очрый («Робинсон хикаяте»...)

Мәгълүм ки, күптән түгел халкыбыз тарихының бик тә изге төбәгендә Болгар академиясе ачылды. Һәм ул бик оператив рәвештә бу уку йортына лаеклы китапханә булдыру эшенә кереште. Аерым зыялыларыбыз аңа инде үзләрендә тупланган язма истәлекләрне тапшырдылар да. Ишетүемчә, Сарманда яшәүче шагыйрь, галим, археограф Дамир Гарифуллин үзенең бик тә бай шәхси китапханәсенең шактый зур байлыгын Болгар академиясенә бүләк иткән. Әлеге уку йорты китапханәсенең директоры, билгеле тарихчы Сөләйман Рәхимов безгә дә бу мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итте. Аның үтенечен исәпкә алып, мин фәкыйрегез дә 2018 елның июль аенда, нигездә, академия рухына туры килешле шактый гына басма һәм кулъязма китаплар тапшырды (болардан тыш – үземнең татар һәм рус телләрендәге хезмәтләрнең дә бер өлешен).

Милләткә хезмәт итүче һәр татар укымышлысы, аеруча дин галиме булырга җыенган шәхесләребез халкыбызның бөек улы Ризаэддин Фәхреддин мирасын теге яки бу дәрәҗәдә белергә бурычлы. Аның һәрбер язганы гыйбрәтле һәм файдалы. Минем карашымча, бу олуг затның ориенталистика (шәрыкшенаслык) темасына язылган хезмәтләре Болгар академиясендә белем алучы һәм эшләүче инсаннарыбыз өчен аеруча кыйммәтле. Нәкъ менә шуны күздә тотып, аның «Мәшһүр адәмнәр» сериясендә чыккан Әбү Галә әл-Мәгарри, Әл-Гарәби, Имам Газзали турындагы хезмәтләрен академия китапханәсенә бүләк иттем. Бу уку йортына тапшырылган язма истәлекләр арасында Г.Батталның «Татар тарихы», М.Һадиев-Чиләбинең «Башкорт тарихы», Җ.Вәлидинең «Татар әдәбияты барышы» кебек җыйнама хезмәтләре дә бар.

1990 елда миңа Хельсинкида гомер кичерүче шагыйрә Гәүһәр апа Туганай (чыгышы белән Баулы ягындагы атаклы Кәрәкәшле авылыннан), башка язма истәлекләр белән бергә, берничә мөстәкыйль әсәрнең бер җыентык рәвешендәге төпләмен дә бүләк иткән

Хатыйп Миңнегулов Лев Гумилев исемендәге Евразия Милли университеты студентлары арасында. Астана, 2016 елның декабре

иде. Аның эчендә Ф.Әмирханның «Урталыкта» романы, Муса Бигиевнең «Кавагыйде фикъһия» тәрҗемәсе һәм башка «китаплар» да урын алган. Шушындый төзелешле төпләмне безгә 1974 елда Башкортстанның Караидел районы Байкы-Юныс авылында Әзһәр Хәмитов тә бүләк иткән иде. Анда 7 китап бергә теркәлгән [Тормыш һәм дин/ Мөтәрҗеме–Закир Кадыйри. – Казан, 1911; Ишаннарга хитаб. – Эстәрлетамак, 1911; югарыда телгә алынган Г.Баттал, Җ.Вәлиди хезмәтләре һ.б.]

Урта гасырларда иҗат иткән госманлы шагыйре Әхмәд Биҗанның суфыйчыл рухлы атаклы «Әнварел-гашыйкин» поэмасы татар дөньясында бик популяр була. Аның (461 бит) бер данәсен миңа 2003 елда журналистика кафедрасы доценты Мөнҗия ханым Мәрдиева (Борһанова) «Минем бабай Госман Туктаров китабы. Әнием Госманова (Фарсалова) Мөкәррәмәдә калды» дигән автограф белән бүләк иткән иде. Бу китапны да Академия китапханәсенә тапшырдым. Әлеге уку йортына һәдия кылынган ядкярләр арасында гарәп һәм фарсы телләрендәге басмалар һәм кульязмалар, башка төр материаллар да бар [«Мөхәммәдия» китабы; «Мәшһүр шагыйрь Акменла. Шиһабеддин әл-Мәрҗани мәрсиясе» (Казан, 1907) һәм; «Акменла әфәнде»...].

Болгар академиясе халкыбызның мөһим бер дини-гыйльми, мәгърифәти мәркәзе булырга тиеш. Әмма әле моңа ирешү өчен бик нык тырышырга, фидакарьләрчә хезмәт куярга кирәк. Аның китапханәсен баету, тулыландыру да бик тә зарури, саваплы гамәл.

***

Халкыбызның күп гасырлык тарихы, гаҗәеп бай рухи мирасы бар. Безнең әби-бабаларыбыз элек-электән белем-мәгърифәтне зурлаган, җыр-бәетләр чыгарган, китаплар язган, башка кавемнәрнең һәм илләрнең, аеруча Мөселман Көнчыгышының рухи хәзинәләре белән таныш булган. Аның соңгы дәвердәге бөек Мәрҗани һәм Фәхреддиннәре, Исхакый һәм Тукайлары, Дәрдемәнд һәм Гафурилары нәкъ әнә шул бай мираска таянып үзләренең бөек әсәрләрен тудырганнар. Озын-озак тарихыбызны, гасырлар буе тупланган рухи хәзинәләребезне белү һәм үзләштерү безнең бүгенге эшгамәлләребезгә ныклы нигез бирә, киләчәккә зур ышаныч тудыра. ■

Рәсемдә (сулдан уңга): Вахит Хаков, Марсель Бакиров, Тәлгат Галиуллин, Николай Мышев, Фәрит Юсупов, Васил Гарифуллин

Гыйлем үзәге... бар иде

Тәлгат Галиуллин

Шартлы рәвештә һәм беркадәр купертебрәк «Гыйлем үзәге» дип аталган оешма турында матбугатта сирәк язалар, реклама такталарында да белешмә бирелми, түрәләрнеке шикелле, рәсми эш бүлмәсе дә юк, мәгәр аңарга, әгъзаларының хәерхаһлыгына аерым кешеләрнең язмышы гына түгел, бу сүзне авыз тутырып әйтәм, тулы бер фәнни юнәлешнең үсеше, хәтта киләчәге бәйле. Нәрсә соң ул шундый серле берәмлек? Укучының нечкә кылларында озын-озак уйнамыйча әйтим инде: сүз Кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен яклау шурасы (советы) турында бара.

Һәр аерым белгечлек буенча оештырылган ул советларга югары уку йортының үзеннән һәм шул фән буенча башка институтлардан иң абруйлы үз шәкертләре, саллы гыйльми хезмәтләре булган галимнәр кертелә. Хөкүмәттән дә, уку йортыннан да сукыр бер тиен алмаган мондый Советта әгъза булып тору мәртәбә, галимлегеңне тану санала, шуңа да вакыты белән дүрт-биш сәгатьләргә сузылган утырышларга сакалы «күкрәгенә» җиткән, тезләренә «тоз утырган» өлкәннәр, аркасын уклау йоткандай туры тотып, беркемне танымагандай яисә күрмәгәндәй узып киткән һавалы урта буын галимнәре дә йөгерә-атлый, беришесе такси яллап булса да, вакытында килеп җитәләр. Өстәвенә, яклау барышында четерекле сораулар биреп, чыгыш ясап, үзеңнең белемеңне, әзерлекле шәхес икәнлегеңне күрсәтеп алу мөмкинлеге дә бар бит әле! Хезмәтне Советка кабул итү, тикшерү, оппонентларны билгеләү, яклау барышы элеккеге коммунистларның бюро утырышы режимында бара, җыелыш вакытында

чыгып йөрүләр тыела, һәммәсе тасмага төшерелеп, башка документлар белән бергә, Мәскәүгә ВАКка (Высшая Аттестационная Комиссия) җибәрелә. Беренче елларда, яклаулар тәмамлангач, «куе» чәй эчүләр оештырыла торган иде, хәзер ул рәхәткә дә кара тамга салынды.

Ничек кенә булмасын, галимнәр вакытында (күбесе аралашу өчен берәр сәгатькә алданрак) килеп, яклау барышында үзләрен серле бөҗра эчендәгедәй тоеп, һәрдаим чыгыш ясарга әзер булып, колакларын тырпайтып тыңлап утыралар. Чөнки яклауда бер яисә ике булачак кандидатның яисә докторның язмышы, «якты киләчәге» хәл ителә. Шуңар да хезмәтен яклауга чыгарган кемсә яшерен тавыш бирүче һәр әгъзага ифрат ягымлы, игътибарлы... Казанда элек-электән югары математика, нисби физика, органик химия, биология, гомуми тарих һ.б. фәнни юнәлешләр буенча яклау Советларының гөрләтеп эшләп ятулары безләргә мәгълүм булса да, андый берәмлекнең милли юнәлешләр буенча юклыгы күңелне әрнетә иде. Дөрес, беренче мәлне бу бушлыкны, ничек кенә сәер тоелмасын, рус советы тулыландырды. Россиянең танылган галимнәренең берсе, романтизм юнәлеше буенча иң абруйлы профессор Н.А.Гуляев Рус филологиясе советына татар әдәбиятыннан да эшләрне кабул итте һәм менә дигән итеп яклатты. Бүгенге вазгыятьтән аермалы буларак, диссертацияңне үз туган телеңдә язсаң да ярый иде. Ул чорда милли мәктәпләр шәһәрләрдә бик санаулы булса да, хәзерге шикелле милли лөгатьләрне «кычкыртып кысу» юк иде. Мин, мәсәлән, «Хәзерге татар поэзиясе үсешенә халык иҗатының тәэсире» кебегрәк мәүзугъка кандидатлык диссертациямне татар телендә тәкъдим итеп, яклап та чыктым.

Мәскәүдән һәркайсына махсус рөхсәт алып, Хатип Госман, Гали Халит, Нил Юзиев кебек олуг галимнәребез докторлыкларын «Гуляев советы»нда якладылар. Николай Александровичны киң күңеллелеге өчен өнәп бетермәделәрме, әллә башка сәбәпләре булдымы, ул башка шәһәргә күчеп китте, Совет таркалды, эзләр җуелды. Чөнки яклау шурасын ачуга рөхсәт биргәндә, рәис буласы кешенең рәсми билгән дәрәҗәсе, фәнни абруе, басылган хезмәтләре исәпкә алына. Бик күп татар балаларын фән юлына бастырган өчен (күпмедер күләмдә аның йогынтысында да дип уйлыйм, татар әдәбият фәнендә романтизмны өйрәнү Й.Нигъмәтуллина, А.Саяпова, Д.Заһидуллина һ.б.иҗатында үзе бер гыйльми мәктәп буларак үсеп китте) Н.А.Гуляевка рәхмәтемне белдерәсем килә. Рус милләтендә, мин-минлек көчәю нәтиҗәсендә, хәзер шундый олы шәхесләрнең булмавы кызганыч. Темадан бераз читләшү кебек күренсә дә, шуны искә төшерәсе килә: татар язучылары исеменнән рус каләм ияләренә телебезнең аяныч хәлен аңлатып, теләктәшлек сорап хат язылган иде, ник берсе җавап бирсен! Димәк, рус әдәбиятында А.Твардовский, Л.Леонов, В.Астафьев, Е.Евтушенко кебек талантлы, киң күңелле шәхесләр юк. Фәндә дә шул ук хәл күзәтелә.

Үзебездә Кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен яклау советы булмауның «тәмен» мин үз хезмәтемне тәмамлагач тойдым. Үткән гасырның җитмешенче еллары ахыры. Татар, рус әдәбиятлары кафедраларының, Казан галимнәренең (Г.Халит, Н.Юзиев соңгы оппонентым да булды) хуплаулары кулда. Кай тарафларга юл тотарга? Яклау советлары Мәскәүдә һәм берничә союздаш республиканың башкаласында гына бар.

Беренчесендә чират зур, диделәр. Бакуга, никтер, күңелем тартмый. Ташкентка юл тотар идең, үзбәкнең берише зыялылары, аеруча галимнәре, «басмачылар хәрәкәте», дигән азатлык өчен көрәшне бастырырга җибәрелгән татбригада өчен гафу итә алмыйлар. Мәскәү шул рәвешле ике төрки телле, бер динле халык арасына чөй каккан.

Казакъ галимнәренең безгә җылы карашларыннан хәбәрдар булганга, Алма-Атага юл алдым. Яклау матавыклары турында «Безнең мирас»та элегрәк бераз язып чыккан

идем инде. Бу урында Казакъстан Фәннәр академиясенең әдәбият институты директоры, Яклау советы рәисе, кан кардәшебез, күренекле шигырь нәзарияты белгече Зәки Әхмәт углы Әхмәтовка олуг рәхмәтемне әйтәсем килә. Уртачадан биегрәк буйлы, җитез хәрәкәтле, ифрат мөлаем кеше булып күңелдә калган Зәки абый. Саргылт йөзен эчке нур бизәп торгандай тоела иде.

Минем 20-30 нчы еллар татар шигъриятенә багышланган хезмәтемә, матбугатта нәшер ителгән китапларыма тәҗрибәле карашын ташлагач, мондый хәбәрне колагыма иңдерде:

– Эшегез безнең Советта карарлык, якларлык, басылган хезмәтләрегез җитәрлек. Тик... бер кыенлык бар.

Ул, йомшак урындыгыннан күтәрелеп, паркет өстенә кызыл келәм җәелгән бүлмәсендә йөреп алганнан соң:

– Безнең Советның рөхсәт срогы чыкты. Документларны җибәргән идек: «Бериш кәгазьләр дөрес тутырылмаган», – дип, юк-барга бәйләнеп, кире кайтардылар. Яклавыгызны тизләтәсегез килсә, безнең юлламаларны алып, ВАКка үзегез барыгыз. Ректор кешегә бу эшне башкарып чыгу җиңелрәк булыр, – дигәндә, саргылт битен янә елмаю бизәде. Минем ризалашудан башка хутым юк иде.

Хәзер, билләһи, дим, Зәки абый белән кайсы телдә аралашуыбызны да хәтерләмим. Аның бөек гадилегеннән сәрхушләнеп калдым. Бары чыгу ишеге янына җитеп, төргәгем кулымны тартып куйгач кына аңыма килеп:

– Зәки абый, Сезгә бераз татар балы алып килгән идем. Кабул итсәгез иде! – дидем.

Ул, артык исе китмичә генә, бер кырыйдарак торган ялтыравык шкафка күрсәтеп, рәхмәтен әйтте дә ярдәмчесенә шылтыратып, мин алып барасы документларны кертергә кушты.

Мин – «йомышчы малай» – горурлыгымны култык астына «яшереп», казакълар советын озайту үтенечен, башка кәгазьләрне алып, Мәскәүгә очтым. Һич көтмәгәндә, анда мине җылы каршы алучы кеше табылды. Ул ВАКның филология фәне мөдире, христиан динен кабул иткән чечен Андрей Федорович Парастаев иде. Аның төрле милләтләргә ярдәмчел мөнәсәбәте шунда ук сизелде. Дөрес, төрттереп алырга да күп алмады:

– ВАКка, якланган эшләрне раслауны сорап, Кавказдан ящик-ящик коньяк килсә, сезнең яклардан кочак-кочак жалоба агыла...

Сөйләшә, аралаша торгач (ул тарихтан, безнең фәннәрдән шактый мәгълүматлы кеше булып чыкты), дуслашып ук киттек, киләчәктә, үзебезнең советны раслаганда, бу яхшы мөнәсәбәтнең файдасы искитмәле булды. Ике көн эчендә казакъларның шурасын озынайту турындагы приказны алып, ул чордагы хезмәт урыным Алабугага кереп тә тормыйча, янәдән Алма-Атага очтым.

Зәки абый рәхмәтен кулны кысу аша белдереп, мине хәзерге казакъ әдәбияты секторы мөдире янына җибәрде. Анысы шактый өлкән яшьтәге галим икән, хезмәтне игътибар белән карап чыккач:

– Хуш, хак. Эшегезне кафедра әгъзаларына укырга бирермен. Ике оппонент бездән, берсен Казаннан кертербез. Тик яңа Совет үзенең беренче яклавын татар әдәбиятыннан башлап җибәрсә, безне җәмәгатьчелек дөрес аңламас! Әүвәл, казакъ әдәбиятына багышланган бер хезмәтне куярбыз, аннан соң сезнекен тәвәккәлләрбез.

Миңа, Алабугага кайтып, алты айдан артык көтәргә туры килде, чөнки теге адәмнең эше тәгәлләнмәгән булып чыкты. Ниһаять, миңа эшне кафедрада тикшерү турында чакыру кәгазе килде.

Хәзерге казакъ әдәбияты бүлеге, хезмәтемне тикшереп, бертавыштан, Т.Н.Гали-

уллинның диссертациясен яклауга чыгарырга, дигән карар кабул итте, Казаннан килгән галимнәр катнашында уңышлы гына яклап та чыктым, тиз арада фән докторы дигән дипломны да алдым.

Шул рәвешле, мин гүзәл шәһәр Алма-Атада үз кеше булып киттем. Азат Әхмәдуллинның диссертациясенә бәяләүче-оппонент булып бардым. Шул ук эздән юл тотып, 1985 елда Фәрит Хатипов доктор булып кайтты...

Яклау мәсьәләре белән Алма-Атага алты тапкыр мәҗбүри сәфәр кылып, юл газапларыннан, чыгымнарыннан гаҗиз булганнан соң, Яклау советы үзебездә – Казанда булырга тиеш, дигән ныклы карарга килсәм дә, ошбу хыялымның кайчан, ничек гамәлгә ашасын тәгаен генә күз алдыма китерә алмый идем әле. Бик күпләр кандидатлык, докторлык диссертацияләрен яклау һәркемнең үз шәхси эше, дип кенә бәялиләр. Хәлбуки, бу – берьяклы һәм ялгыш караш. Башка милләт кешеләре белән төрле дәрәҗәдәге очрашуларда, аеруча фәнни конференцияләрдә халыкның аң үсеше, язмышы турында гәп куерганда, ничә докторыгыз, профессорыгыз бар, дигәнрәк сораулар еш бирелә иде. Җиңелгән халыкның мөмкинлеге бик чикле, дип һәркайсына аңлатып, мескенләнеп торып та булмый.

Үзебездә Татар теле һәм әдәбияты буенча совет ачу хыялын гамәлгә ашыру өчен, сиксәненче еллар ахыры – туксанынчы еллар башында дилбегәнең бераз йомшаруы, демократик үзгәрешләрнең пәйда булуыннан файдаланып калу кирәк иде. Әлеге чорда гомергә дәүләтләре булмаган халыклар тулы бәйсезлек алдылар, ә безнең авызга балы эләкмәде, мыеклар гына чыланып калды. Шул «чылануга» туган телебез һәм әдәбиятыбыз буенча Яклау советын ачып кала алуны кертергә була.

Казан дәүләт университетында Яклау советының пәйда булуында татар факультеты деканы буларак мин генә түгел, ВАК белән даими элемтәдә торуда, документларны әзерләүдә, 22 галимнең тиешле кәгазьләрен юллауда шул чорда КДУ проректоры булып эшләгән Миркасыйм Госмановның тырышлыгы зур иде, урыны җәннәттә булсын!

Казакъ кардәшләрнең Советын «озайткан» кеше буларак, КДУ ректоры кул куйган гозерне, булачак Совет әгъзаларының белешмәләрен һәм башка кәгазьләрне күтәреп, Мәскәүгә, ягъни ВАКка үзем бардым. Танышым А.Ф.Парастаев соңгы елын эшли икән, яше җиткән көнне үк тантаналы рәвештә пенсиягә озатачаклар, ди. Ул хәленнән килгәннең барысын да эшләде. Мәгәр Советны ачу җәһәт кенә хәл ителмәде. Җитешмәгән юлламаларны алып, диссертациясен беренче утырышка әзерләп йөргән Хатыйп Миңнегуловка, аннары методика кафедрасы доценты Камил Биктаһировка да, кайбер төзәтмәләрне алып, Мәскәү тарафларына барырга туры килде. Советка үзебез яхшы белгән, күбебезне укыткан, совет һәм көнбатыш әдәбиятлары буенча белгечләр Л.И.Ачкасова, Л.В.Савельева кебек профессорларны да кертергә туры килде (татар филологиясеннән докторлар җитешмәү сәбәпле). Әйтергә кирәк, алар һәр утырышка килеп, тикшерүләрдә катнашып, безнең советның эшчәнлегенә югары бәя биреп йөрделәр.

Ниһаять, Казанның иң мөхтәрәм тел-әдәбият галимнәрен туплаган Яклау советын ачу турында әмер килеп төште. Башларыбыз түшәмгә тиярлек дәрәҗәдә шатландык. Бу сөенечле хәбәр XIX гасыр башында Казанда «Азия» типографиясен ачуга тиң иде.

Олы тарихыбызда беренче Яклау советы, татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты кебек үк, милли мәдәниятебезгә югары дәрәҗәле белгечләр, үз фәнни мәктәпләрен үстергән олуг галимнәр, гомумән, зыялылар әзерләүгә гаять зур өлеш кертте.

Алдарак кисәтелгәнчә, яклауны оештыру – шактый катлаулы, мәшәкатьле шөгыль. Фәнни эшләрне алдан карап чыгу, Совет әгъзалары белән элемтәгә керү, кәгазь эшләрен,

яшерен сайлау бюллетеньнарын әзерләү һ.б. «вак-төяк» шөгыльләр гыйльми сәркатип җилкәсенә төшә. Рәискә, түр башына менеп утырып, җыелышны ачып җибәреп, алып барасы гына кала. Гыйльми сәркатип вазыйфаларын ун ел тирәсе Хатыйп Миңнегулов алып барды, аны Дания Заһидуллина алыштырды. Шунда бик җитди, авыз тутырып әйтәм, «бюрократик» мәктәп узган, тәҗрибә туплаган сәркатипләр соңыннан кафедра мөдирләре, тагын әллә кемнәр булдылар... Хәзер бу четерекле, мактаулы эшне булдыклы яшь галим, Кычытканлы авылы егете Айрат Йосыпов алып бара.

Бу игелекле Советта күпме кеше диссертация яклагандыр, аларның исәбен алып бармадым. Үземнең җитәкчелектә яклаган егермедән артык кандидатны һәм киңәшем белән (консультант буларак) ярдәм иткән өч шәхесне горурлык белән телгә алам. Алар: Фәннәр академиясенең вице-президенты, академик, профессор Дания Заһидуллина, КФУның Филология институтының әдәбият кафедрасы мөдире, профессор Флера Сәйфуллина һәм Ф.Кәрим иҗаты буенча докторлык диссертациясен яклаган Рамил Сарчин. Кандидатларым арасыннан алтай, хакасс кызлары, хатлар язып, кунакка, конференцияләргә чакырып торалар.

Мин укытып, Тәүфыйкъ Әйди, Хәсән Туфан иҗатлары буенча кандидатлык диссертацияләре язып яклаган, хәзергесе көндә «Казан утлары» журналы, «Шәһри Казан» гәзите баш мөхәррирләре Рөстәм Галиуллин һәм Радик Сабировлар фәндә калсалар да, ким-хур булмаслар иде. Уку-укыту эшләренә җигелеп тартылсалар да, татар шигъриятендә символлар хәрәкәте белән бәйле җитди темага докторлык диссертациясен яклап өлгергән Н.Йосыпова, Г.Гайнуллина, Л.Дәүләтшина... КФУның Алабуга институты, Яр Чаллы университетларының тел, әдәбият кафедрасы мөдирләре Г.Даутов һәм Р.Галиуллиннар – шул Совет шәкертләре. Алар, докторларның үкчәләренә басып, һәрьяктан үсеп киләләр.

Докторлык дәрәҗәсен алуга күптәннән лаек булып та, Совет ачылганны көтеп торган, әдәбият белеменең якты йолдызлары Резеда Ганиева, Фоат Галимуллин, Хатыйп Миңнегулов, Марсель Бакиров, Зөфәр Рәмиев, Рәмил Исламов, Әлфәт Закирҗанов, Әхәт Нигъмәтуллин...Тел белеме галимнәре Әлфия Йосыпова, Гөлшат Галиуллина, Фәнүзә Нуриева һ.б. шул Советта диссертация яклап, дистәләгән галимнәр әзерләп үз фәнни мәктәпләрен булдырдылар.

Яклау советларын үзләрендә ачканчы, күрше Башкортстанга, хәтта фин-угыр республикаларына да ярдәмнән баш тартмадык. Кыскасы, күршеләр белән гел ут-су алышып яшәдек. Мәсәлән, Мордовиядә Диссертацион советын ачу өчен фән докторлары җитмәгәч, безгә мөрәҗәгать иттеләр. Ике ел дәвамында, профессор Ф.Юсупов белән, Саранскига яклауларга йөрдек. Безнең Совет әгъзалары аеруча Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән тыгыз элемтәдә яшәде, анда эшләп алган шура белән даими аралашып, галимнәребез икесендә дә әгъза булып тордылар.

Казанда беренче Яклау советын ачу өчен җан атып йөреп, 25 ел аның белән җитәкчелек иткәннән соң, кинәт кенә, мине чакырып, аңлатып тормыйча, вазыйфамнан азат итү турында ВАК бюллетенының укып белдем. Дилбегәне шул ук Советта доктор булган тел галиме Әлфия Йосыповага тапшырдылар. Шура берничә ел дәвамында яңа җитәкче белән (сәркатип шул ук калды) шактый уңышлы гына эшләп алды. 2019 ел уртасында Советның эшен туктатуы турында хәбәр килде. Татар филология фәненә генә түгел, төрки, хәтта угрофин галимнәренә дә 30 елга якын ярдәм итеп килгән Совет юкка чыкты.

Хәзерге көндә, әлбәттә, иң борчыганы – татар мәктәпләре, факультетлары яшәүдән туктагач, фәнни алмашның акрын үсүе, телне, әдәбиятны өйрәнүгә ашкынып торган яшьләрнең фәнгә килмәве. ■

ТАТАР ГАЛИМНӘРЕН ТАНЫТКАН ХЕЗМӘТ

Гүзәлия Хаҗиева

Дөнья буйлап сибелеп яшәгән төрки халыкларның телләрен өйрәнү, фәнни яссылыкта тикшерү – тюркологиянең әһәмиятле бер өлкәсе. Үткән һәм хәзерге көн ноктасыннан якын килеп, төрки фән үсешенә саллы өлеш керткән галимнәрне барлап, аларны дөньяга таныткан хезмәтләргә һәрдаим ихтыяҗ бар. Дөнья тюркологларын барлап, аларны библиографик тәртипкә кертү эшенең башлангычы булса да, тулаем зур хезмәт юк иде әле. Төркиянең Фырат университетында филология фәннәре докторы, профессор Әхмәт Буран редакциясендә нәшер ителгән «Төркиядән читтә төрки дөнья тюркологлары» дигән саллы ике томлы хезмәт бу бушлыкны тутыра, дияргә нигез бар (Türkiye Dişindaki Türk Dünyası Türkologları. Dilciler. Editör: Prof. Dr. A.Buran. Ankara: Akçağ yayınları, 2019. 1 cilt. 1259 s. Türkiye Dişindaki Türk Dünyası Türkologları. Dilciler. Editör: Prof. Dr. A. Buran. Ankara: Akçağ yayınları, 2019. 2 cilt. 1279

s.). Хезмәттә төрки дөньяга танылган 430га якын тюркологның библиографиясе, иҗат портреты урнаштырылган. Хезмәтнең икенче томы татар галимнәренә багышланган.

Билгеле булганча, XIX гасырның беренче яртысында Казан университеты тюркологияне өйрәнүнең мәркәзе була һәм анда, көнчыгыш телләрне укыту белән беррәттән, әлеге телләрне, ул халыкларның тарихын, гореф-гадәтләрен фәнни яктан өйрәнү эше алып барыла. Әмма 1855 елда университетның көнчыгыш бүлеге Петербург дәүләт университетына күчкәч, Казан университетында татар теле укыту алгы планга чыга. Әлеге саллы хезмәтнең университетта татар телен беренчеләрдән укыткан мөгаллимнәрнең берсе Ибраһим Хәлфин исеме белән башланып китүе дә бик урынлы, дип әйтергә нигез бар. Бу хезмәттә төрки лингвистик мәктәпнең XIX гасырдан алып 1918 елга кадәрге чорында татар телен укыту һәм аны дөньяга танытуда тирән эз калдырган Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйри, Әхмәтһади Максуди кебек галимнәрнең киң кырлы эшчәнлекләре төрки дөньяга төрек телендә танытыла.

Хезмәттә 1918 елдан алып 50 нче еллар аралыгында татар телен танытуга зур өлеш керткән М.Корбангалиев, Г.Нугайбәк, Г.Ибраһимов, М.Фазлуллин, Х.Бәдигый, Җ.Вәлиди, Ш.Рамазанов, Г.Алпаров, В.Хангильдин, Р.Газизов, Л.Җәләй, Г.Шәрәф кебек күренекле галимнәребезнең иҗади портретлары бирелгән.

XX гасырның икенче яртысындагы татар тел белеме үсешен шартлы рәвештә ике чорга бүләргә мөмкин. XX гасырның 50 нче еллары ахырына таба татар телендә гомуми тел белеме буенча язылган грамматикалар дөнья күрә. Бу чорда татар галимнәренең СССРда яшәүче башка төрки халыклар белән фәнни бәйләнешләре ныгытыла һәм аларга зур игътибар бирелә.

Татар тел белеме эшчәнлегенең икенче чоры XX гасырның 90 нчы елларында башлана һәм әлеге чорда милли телләрне саклау, аларның үсешен тәэмин итү сәяси яңарыш белән бергә үрелеп бара. Бу чорда күп санлы фәнни алмаш әзерләнә. Хезмәттә тел тарихы, грамматика, синтаксис, фонетика (Ә.Кәримуллин, Ф.Фасеев, Х.Курбатов, М.Зәкиев һ.б.), диалектология (Н.Борһанова, Л.Мәхмүтова, Д.Тумашева, С.Ибраһимов, Д.Рамазанова, Ф.Баязитова, Ф.Юсупов), ономастика (Г.Саттаров, Ф.Гарипова, А.Шәйхулов, Х.Алишина) өлкәсенә караган хезмәтләре белән танылган галимнәрнең иҗади портретлары урын алган.

Тел белемен яңа призма аша карап, төрки телләрне үстерүдә, аларны саклап калуда зур өлеш керткән галимнәребез турында язылган «Төркиядән читтә төрки дөнья тюркологлары» дигән хезмәт, чын мәгънәсендә, төрки дөнья өчен зур бүләк булып тора. Фырат университетының хөрмәтле галимнәре, остазларыбыз – филология фәннәре докторы, профессор Әхмәт Буранга, филология фәннәре докторы, профессор Эрҗан Алкаяга, әлеге саллы хезмәтне әзерләп чыгарган өчен, чиксез рәхмәтебезне белдерәбез. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2019

АНЫҢ РУХЫ, ФӘҺЕМЕ БАР...

Хәләф Хәлилов

Хәтергә уелган китап... Ул да булса, язучы Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәре. Аны моннан 50 ел чамасы элек укысам да, әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалар хәзер дә күз алдымда. Тормышымда да әлеге әсәр сюжетына охшаш хәлләр еш булды. Дөрес, миңа китапны русча укырга туры килде, шулай да әле дә булса, әсәрдә сурәтләнгән табигать күренешләрен, образларны яттан беләм...

Минем әнигә дә гомеренең соңгы ике аен Башкортстанның 80 елдан артык яшәгән Аскын районындагы Иске Казанчы авылында түгел, ә олы кызы гаиләсендә – Татарстанның Кукмара районындагы Кәркәвеч авылында үткәрергә туры килде. Әсәрдә тасвирланган Ак әбинең язмышы минем әни язмышына бик охшаш. Соңгы көннәрдә аның да башына шундый ук уйлар килгәндер, дип уйлыйм. Ни кызганыч, кире кайтарып булмый шул...

Әнибез Тәгълимә Нигъмәтулла кызы XX гасыр башында туган, ил белән бергә аның барлык сикәлтәле юлларын үткән. Гражданнар сугышы, аннан соңгы ачлык, коллективлаштыру, Бөек Ватан сугышы – болар барысы да аның башыннан узган.

Утызынчы еллар башында карт әтиебез Нигъмәтулла мулланы Архангель өлкәсенә сөргенгә җибәргәннәр. Балалары, шул исәптән безнең әниебез дә, өйләреннән куып чыгарылып, урамда торып кала. Әниебез үзеннән аз гына өлкәнрәк абыйсы һәм апасы белән урман пунктына агач кисәргә җибәрелә. Шунда өч кыш йөреп эшли алар. Юллары берничә тапкыр Иске Казанчы авылы аша үтә (әниебез Балтач районының Штәнде авылында туган). Язмыш әниебезне шул авыл егете Хатип Хәлилов белән очраштыра. Яшьләр бер-берсен бик ошаталар. Күп тә үтми, матур гаилә корып яши башлыйлар.

Бөек Ватан сугышы башлангач, әтиебез фронтка китә. Әниебез берсеннән-берсе бәләкәйрәк өч бала һәм сиксән яшьлек каенанасы белән торып кала, шул чор кешеләре кичергән барлык михнәтләрне кичерә. Әтиебез, Брянск фронтында каты яраланып, госпитальләрдә алты ай дәваланганнан соң, икенче группа сугыш инвалиды булып, туган ягына кайтарыла. Көче җиткән кадәр колхозда эшли. Гаиләдә тагын дүрт бала дөньяга килә, шул исәптән мин дә.

Хәләф Хәлилов – Курган өлкәсенең Белозерный районындагы Степный Дол авылыннан.

Ул елларда югары сыйныфларда уку түләүле була. Олы абыйны һәм апаны укытырга акча булмагач, әниебез төзелүче яңа мәктәпнең нигезе өчен кичләрен чокыр казый. Абый һәм апа мәктәпне тәмамлап, илленче еллар уртасында ук, Казанчы төбәгендә беренчеләрдән булып, Казан шәһәрендә югары белем ала. Олы апа мәктәпне Мактау грамотасы белән тәмамлаган була (хәзер ул алтын медальгә тиң).

Инде тормыш беркадәр җиңеләя дигәндә, яңа сынаулар килә. Кеше ышанмаслык, йөрәккә кан саварлык кайгылар кичерә әниебез. Өч улы, бер кызы фаҗигале вафат була. Тетрәндергеч бу хәсрәт-сагышларның әрнүе аз гына сүрелә төште дигәндә генә, ике киявен, оныгын, аннары 60 ел буе бергә дөнья көткән әтиебезне соңгы юлга озата ул. Шулай да, әниебез шәфкатьлелек-изгелеклеген, кешегә карата ихлас мөнәсәбәтен, сабырлыгын җуймады. Казанчы халкын үз балалары кебек якын күреп яратты ул. Аның затлылыгы, итагатьлелеге, авырлыкларны, кайгыларны зур сабырлык белән кичерә белүе, искиткеч түзем-сабыр холкы, замандашлары өчен генә түгел, киләчәк буын вәкилләренә дә соклангыч үрнәк булды һәм булачак та.

Әниебезнең кылган догалары, укыган намазлары, тоткан уразалары хәвеф-хәтәр белән ике арада калкан булып торды. Бәлки шуның өчендер, авылыбызда бик күп еллар буе зур янгыннар, каты давыллар булганы юк.

Казанчы табигатен дә ихлас яратты ул, чөнки алар аның тирләп-пешеп печән чапкан болыннары, җиң сызганып урак урган басулары, арып-талып агач кискән урманнары иде. «Аллаһ Тәгалә табигатьнең иң матурын, иң ямьлесен Иске Казанчыга сайлап биргән», – ди иде әнием. Мин үзем дә табигатьнең кешегә, газиз ана кочагыдай шулкадәр якын-кадерле булуын иң беренче аннан ишетеп белдем. Тормыш юлымны урман һәм табигатьне саклауга багышлавым да, бәлки, шуннандыр. Инде менә 40 ел буе әлеге эшемне дәвам итәм. Миңа сәфәрдә бик күп йөрергә туры килде: Русияне аркылыга-буйга берничә тапкыр үттем, биш диңгез кичтем, чит илләрдә дә булдым. Ләкин аларның берсенә дә яңадан барасы килми. Әниебез озын, авыр һәм катлаулы тормыш юлын мәңге үлмәс җыр итеп калдырды, дип әйтсәм дә һич арттыру булмас, чөнки тирә-якта ул гыйлем биргән дистәләрчә мулла-абыстайлар бар. Аның рухы, фәһеме бар... ■

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

ЯПОНИЯДӘ МӘКТӘПЛӘР

Хәрефләр

Японнарның элек-электән кулланыла килгән хәрефләре [иероглифлар. – *Габдерәшит Ибраһимов искәрмәсе*] – кытай хәрефләре. Дөресрәге, болар –хәреф түгел, һәрберсе бер иҗек белдерә торган шәкелләр. Иҗек-хәрефләрнең һәммәсенең дә дүрт шәкеле бар.

Шул рәвешле, илле данә хәрәкәле, ягъни ас һәм өс тамгалы хәреф шәкеле бар. Бу хәрефләрнең барысы да кулланы-

Ханҗи Йаматогана Хирагана Катакана



Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

лышта йөри. Болардан башка, утыз меңгә якын кытай иероглифы да кулланыла. Әлеге шәкелләрнең барысын да өйрәнү өчен шактый вакыт кирәк. Хәрәкәле япон хәрефләренең саны ике йөзгә якын. Шулай булса да, японнарда укый-яза белмәгән кеше бик сирәк очрый. Рикшалар бик яхшы укый һәм яза беләләр, гади эшчеләр, йөк ташучылар арасында да укый-яза белмәүчеләр бөтенләй юк диярлек. Шундый сорау туарга мөмкин: хәрефләренең бу кадәр катлаулы булуы японнарның тәрәккыятенә ничек комачаулык итмәгән?! Японнарда башлангыч белем мәҗбүри. Бала мәктәпкә җибәрелмәгән очракта, атасы, анасы яки опекуны җаваплы булган кебек, шул мәхәлләнең хакимиятенә караган полиция идарәсе дә җаваплы булып санала.

МӘКТӘПКӘ КЕРҮ ЯШЕ

Бала, биш яше тулуга, мәктәпкә алына, ләкин беренче елда аңа берни дә өйрәтелми. Ул бары тик уеннар аша мәктәпкә ияләндерелә, теләгән вакытта килә, теләгән вакытта китә ала. Аларның биредә уйный торган уеннары – әлбәттә, уйланылган, программага бәйле уеннар. Бала нәкъ бер ел буе шулай мәктәпкә әзерләнә, алты яше тулгач, дәресләр укый башлый.

ЯПОННАРНЫҢ БУЕ

Япон милләте – башка милләтләр белән чагыштырганда, кечкенә һәм кыска буйлы, йөзләре бик яшь. 22-23 яшендәге япон кешесен күреп, аны нибарысы 15-16 яшендә, дип уйлыйсың. 30 яшьлек япон кешесе 18-20 яшьлек булып күренә. Сакал-мыек та булмаганга, бөтенләй дә яшь күренәләр. Японнарда, гомумән, сакал булмый, мыекларын да кыралар. Бары тик төньякка таба китәрәк, Хоккайда, Сахалин тарафларында гына сакал үстерәләр, үзәккә таба китсәк, Токио һәм аның әйләнә-тирәсендә сакал-мыек йөртүчене сирәк кенә очратырга мөмкин, кайберләрендә, сакал булмаса да, мыек була. Тик Киото, Кама Коре, Нара якларында боларның берсе дә юк. Гәүдәләре кечкенә, ләкин куәтләре буйларына күрә түгел. Япон ир-аты 100-150 кг әйбер күтәрә, арбага төялгән 250 кг авырлыктагы йөкне бик ерак җирләргә кадәр ташый ала. Ул, йөк тартып, еш-еш сулап, үр менә, бик авыр тауарларны бик ерак җирләргә кадәр ташый. Шул рәвешле, йөк хайваны башкара торган вазыйфаларны кешеләр башкара һәм бу хәлне башка милләтләргә карата күз алдына да китереп булмый. Бервакыт, авыллар буйлап йөрергә чыккач, мин бер япон кешесенең арбага төялгән дүрт телеграф баганасын үргә тартып менүен күргән идем. Ул кечкенә генә гәүдәле японда бу кадәр куәт бары тик табигый сәләт һәм күнекмә белән генә барлыкка килә алгандыр. Японнар, тәрбия аша фикерләрен агарткан кебек, гәүдәләрен дә, тәҗрибә аша, көчле, куәтле итүгә ирешәләр.

Бу хакта табигать фәннәре буенча белгеч булган япон галимнәре белән бик күп фикер алыштым. Алар да куәтнең артуында табигый сәләтнең ролен билгелиләр. Шул сәбәпле, япон мәктәбендә беренче сыйныфтан башлап ук гәүдә тәрбиясе, ягъни физкультура дәресләре мәҗбүри итеп куелган. Бу максатка ирешү өчен махсус чыгарылган кануннары да бар.

БУЙ КЫСКАЛЫГЫННАН ЧАРА

Шулай да, японнарда буй кыскалыгының сәбәбе нәрсәдә? Буйны, берәр чара табып, озынайту мөмкинме, юкмы? Бу хакта бик җитди итеп уйланалар. Моннан тыш, ир белән хатынның җенси мөнәсәбәтләре өчен дә билгеле вакытлар билгеләнгән һәм халыкның күпчелеге моны кабул иткән. Бүгенге көндә бигрәк тә япон авылларында балалар туу вакыты сентябрь ахырында башланып, бер айлап дәвам итә. Моның шактый файдасы бар икән. Японнарда җир эше бик авыр. Һәр ел иген чәчү алдыннан кырларга, аз дигәндә, биш тапкыр яңа туфрак, черемә, тирес

кертәләр. Болар барысы да кул хезмәте белән башкарыла. Шуңа күрә, ир-хатын аермасы ясалмыйча, кырларда барысы бергә эшлиләр. Хатыннарның сентябрьдә дөньяга килгән балалары, апрельгә кадәр, ананың кулыннан төшәрлек булып үсә. Бала, әгәр үзеннән олырак кардәше булса, аның аркасына, булмаса, хатын үз аркасына бәйләп асып йөри алырлык була һәм хатынның эшенә комачау итми.

БАЛАЛАРНЫ АРКАГА БӘЙЛӘП ЙӨРҮ

Ни гаҗәп, бөтен япон хатыннары, югарыда әйтеп үтелгәнчә, балаларын аркаларына бәйләп, күтәреп йөриләр. Нинди генә затлы, тәрбияле хатын булса да, баласы барыбер аркасына бәйләнгән була. Япон хатыннары һәр ел бала табалар. Балалар күбәйгән саен, әлбәттә, ана барысын да аркасында ташый алмый. Шуңа күрә, алты айлык, 1-2 яшьлекләрне 5-6 яшьлекләрнең аркасына бәйли. Уен мәйданчыкларында мондый балаларны бик еш күрәм. Кечкенә генә – 5 яшьлек, 6-7 яшьлек балалар аркаларында гел берәр кечкенә бала күтәреп йөриләр. Беренче күргәндә, бу бик сәер булып тоела. Бер өйдә кайчак 8-10 бала була. Соңрак, канун нәтиҗәсе буларак, күрәчәкбез: япон мәктәпләрендә сыйныфташлар һәммәсе дә бер буйда булалар. 1 нче сыйныф балалары барысы да бер үк буйда, 2 нче сыйныф укучылары шулай ук бөтенесе дә бер үк буйда, 3 нче, 4 нче һ.б. сыйныф укучылары да гел бер буйда булалар. Бер сыйныфта төрле буйдагы укучылар очрамый.

МИНЕМ ФИКЕРЕМ

Японнар ник бу кадәр кечкенә гәүдәле соң? Бу турыда мин дә бик күп уйландым. Безнең кебек читтән күзәтүче кеше күреп алырлык бер генә дә ачык сәбәп юк. Үз галимнәре дә эзләнә-тикшеренә, ләкин берни таба алмыйлар. Шулай да, миңа шул фикер тынгы бирми: балаларның аркада бик озак вакытлар бәйле булуларының катнашы бардыр кебек. Барыннан да элек, бала, туган көненнән башлап, һәрвакыт асып йөртелә, хатын утырганда, йөгергәндә, йөргәндә һәм, гомумән, бала һәрвакыт гел аркада бәйле хәлдә кала. Баланың бу хәле, һичшиксез, аның үсеш-үзгәрешенә киртә булып тора.

Моннан тыш, япон хатыннарында күкрәк юк дәрәҗәсендә, шул сәбәпле, бала өчен туклану җитәрлек, тиешенчә туя алырлык түгел. Моның да сәбәбе – аркаларында һәрвакыт бала бәйләп куеп йөртүләре булса кирәк. Әлбәттә, тора-бара бу табигый хәл алган.

Баланы аркага асып йөрүнең, һичшиксез, зарары бик күп, ә файдасына килгәндә, ул зарарын басып китәрлек дәрәҗәдә түгел. Ләкин бу хәл японнарда гадәт булып нык урнашкан, үзгәртелүе мөмкин кебек күренми.

ТЕАТР

Японнарда театр элек-электән киң таралган һәм алга киткән була. Бирелә барыннан да элек шуны әйтергә телим: японнарның театры да аларның үзләре кебек. Беренчедән, театр уены, кичен түгел, көндез күрсәтелә. Икенчедән, театрга югары катлау кешеләре генә түгел, гади халык та, гомумән, һәр кеше йөри ала. Барысы да, гаиләсе, бала-чагасы белән бергә, гаиләдә ничә бала булса, бары да – имчәк баласыннан башлап, иң зурларына кадәр – һәммәсе дә килә. Театрның эче тип-тигез, идәненә чыпта келәм җәелгән почмаклар ясалган. Һәр гаиләгә бер почмак, һәр почмакта дүрт мендәр һәм бер мангал бар. Һәркайсы бер почмакка урнаша, үз өендәге кебек утыра, ашарга, эчәргә шунда китерелә. Лоджияләрдән башка бөтен җир гел бер бәя, монысы кыйммәтрәк, тегесе арзанрак түгел. Лоджияләр бераз бүленгән булганга, бәя дә башкачарак.

Театр ишегеннән кергәндә үк, барысы

Безнең мирас №12 декабрь 2019

да аяк киемнәрен сала, эчкә йомшак башмак киеп керә.

Театрда уйнала торган сәхнә уеннары күбесенчә опера була, драмалар бик аз куела икән. Балет бөтенләй юк. Операларда японнарның гел үз әсәрләре, үзләре турында. Аврупада мәшһүр булган әсәрләрнең берсе генә дә хәзергә кадәр япон театрларында сәхнәгә куелмаган. Япониядә бүгенгә кадәр Аврупа ысулындагы театр биналары да юк. Театр сәхнәсе ике тарафлы итеп эшләнгән. Бер ягында уен барганда, икенче ягында декорация алышына, әзерлек бара. Бер пәрдә тәмамланганнан соң, бөтен сәхнә әйләнә, беренче бүлем, уенчылары белән бергә, пәрдә артына керә, яңа декорация белән яңа уенчылар утырган җирләрендә тамашачы алдына чыга.

Беренче тапкыр мин театрга, белмичә, очраклы рәвештә барып кердем. Телләрен дә белмәгәнгә, бик сәер булды. Аврупа кешеләре өчен аерым урыннары бар икән, мине шунда урнаштырдылар. Аяк киемнәремне салырга кушмадылар, өстеннән кияр өчен гаять җиңел, нечкә резин башмак бирделәр. Бу башмаклар махсус эшләнә икән, зур аякларга да, кечкенә аякларга да ярый.

Берүзем кердем, күрсәтелгән урындыкка утырдым. Миннән башка бу катта беркем дә юк. Тел дә белмим. Күп тә үтмәде пәрдә ачылды, уен башланды.

Мин, тел белмәгәнгә, уеннан берни аңламасам да, сәхнәнең декорациясе, уенчыларның хәл-торышлары, тамашачыларның гаиләләр хәлендә бер авыл кебек җыелып утырулары минем өчен уеннан тагын да кыйммәтлерәк гыйбрәт дәресе иде. Беренчедән, уенда чит мәдәният йогынтысы һич сизелми. Икенчедән, гаять табигый уйныйлар, суфлёр-фәлән дә юк. Өченчедән, башыннан ахырына кадәр һәрнәрсә миллилек нигезенә корылган. Уен карап утырганда, уемда гел болар булды. Моннан башка, игътибарымны бик нык җәлеп иткән тагын бер нәрсә бар иде: балаларның шулкадәр күп булуларына да карамастан – 200 олы кеше булса, балалар саны 600ләп булыр – тәнәфес вакытында да хәтта бер шау-шу, чыр-чу ишетелмәде. Бу исә минем өчен чынчынлап гаҗәпләнерлек хәл иде. Шундый уйлар белән анда нәкъ өч сәгать вакыт үткәрдем. Шул вакыт эчендә бер пьеса тәмамланды.

Яныма килеп, уенның тәмам булуын миңа белдергән кеше: «Бер сәгатьтән яңа пьеса башлана, әгәр калырга теләсәгез, кабат билет алырга кирәк», – диде. Минем максатым бер килеп күрү иде, ул тормышка ашты, икенче уенга калуны кирәк күрмәдем.

ЯПОННАРДА ТӨНГЕ ТОРМЫШ ЮК!

Японнарның бар нәрсәләре дә шулай: театрлары да көндез эшли. Аврупадагы төнге тормыш Япониядә юк. Төнлә бар да йоклый, иртән иртүк торалар, кичке сәгать унда, иң соң унбердә урамнарда беркем дә калмый. Бары тик кулларына фонарь тоткан почта һәм телеграф хезмәткәрләре генә арлы-бирле йөренәләр.

Японнарның бу сыйфатларын искиткеч, дип санап ошаттым. Болар, чынлап та, бик матур әхлак күрсәткечләре булып тора.

Япониядә яшәгән вакытта бертуктамый сәяхәт иттем. Шәһәрләрдә, авылларда, тауларда – кайда гына булсам да, бервакытта да японнарның әхлак үзенчәлекләрен күз уңыннан ычкындырмадым. Японнарда тәрбия һәм әхлак шулкадәр югары иде ки, бары тик безнең мөселманнарга лаек дәрәҗәдә иде. Бервакыт иртән, бер авылдан үтеп барганда, бер чәйханәгә кереп чәй эчтем. Китәргә кирәк булганда, чәйханә хуҗасы күренмәде. Мин дә, чынаягым янына бер сен акча куеп, китеп бардым. Ул көнне көн буе йөрдем, гиздем һәм кичкә таба Токиога кайтырга чыктым. Иртән чәй эчкән чәйханәнең янынннан үтеп бара идем, чәй ясап бирүче хатын миңа эндәшә икән, борылдым. Миңа таба йөгерә-йөгерә килә.

Мин шунда ук: «Ах, чәй ике сен булган, ахры», – дип, кесәмнән янчыгымны чыгардым, акча бирергә әзерләндем. Хатын миңа үзе вак акчалар суза: чәй 4 рин тора икән дә минем алты риным калган. Карагыз сез шул дөреслеккә, төгәллеккә, шул әхлакка! 1 сен акчаның кыйммәте дә әллә нәрсә түгел, безнең акча белән биш акча. Биш акча алар акчасы белән бер сен дә 10 рин була. Безнең алты рин, ягъни 3 акчабыз аларда калган да, хатын йөгерә-йөгерә ул акчаны миңа китереп бирде. Бу әхлакны Аврупада эзләп тә маташмагыз, чөнки таба алмаячаксыз!

ТАГЫН АВЫЛ ТОРМЫШЫ ЭЧЕНДӘ

Ходокайа исемле бер авылда идем. Кыш көне. Авыл буйлап барам, кемне күрсәм дә, аңа берәр сорау бирү, ни дә булса өйрәнү максаты белән йөрим. Мийато исемле бер карт белән сөйләшкәндә, үземнең Русиядән килгән татар кешесе булуымны әйттем. Ул исә мине рус диеп аңлаган, миңа ихтирамын белдерергә тырышып: «Без русларны яратабыз, чөнки руслар булмаса, без үз кыйммәтебезне белә алмаган булыр идек», – диде.

Әңгәмәне дәвам итеп, бу авыл кешесе миңа: «Шуны беләсем килә: руслар үзләре үз кыйммәтләрен белә, аңлый алдылармы икән?» – дип сорау бирде.

Мийатоның бу сүзләре миндә зур кызыксыну уятты, чөнки моны авыл карты сөйли иде. Мин аңа: «Руслар үз кыйммәтләрен болай да беләләр иде, тик менә сез генә базарларын төшердегез», – дидем. Минем бу сүзләремә Мийато, көлеп, болай диде:

– Без русларны мактыйбыз. Дөресе дә шул, алар – чын сугышчы халык. Безгә күп нәрсә өйрәттеләр. Кешенең үз остазына ихтирам күрсәтүе гаять табигый хәл, шулай булгач, без дә русларны ихтирам итәргә тиеш. Без руслар ярдәме белән үз урыныбызны, бәябезне билгели алдык. Кеше үз урынын билгеләргә тырыша икән – моңа хакы бар. Әмма эш бары тик тырышуда гына түгел, моның өчен әле сәбәпләрнең дә булуы кирәк.

– Сез сугышта катнаштыгызмы?

– Катнаштым, ләкин минем кебек карт кешенең сугышта катнашуының әһәмияте күпме була ала? Тик шулай да, милләтемнең данлы ир-атлары белән бер сафта була алганыма үземне бик бәхетле хис итәм.

– Кайларда булдыгыз?

– Ялу сугышында булдым, Мукденга кадәр бардым*.

– Бу сугышта иң исегездә калган, бәлки бераз гаҗәпләндергән берәр вакыйга турында сөйләсәгез иде.

– Мин – олы яшьтәге авыл кешесе, укый-яза белүем дә бик чамалы. Сезгә берәр нәрсә сөйләргә уйласам, ул бары тик күзем белән күргән берәр вакыйга гына була ала. Ә үз күзләрем белән мин шактый нәрсә күрдем! Тик күбесе инде исемдә түгел. Ләкин Мукденны алганда булган бер вакыйганы яхшы хәтерлим: бу – бер рус сәүдәгәренең комсызлыгы аркасында күрсәткән батырлыгы. Тыңларга теләсәгез, шул турыда сөйләп китим.

– Рәхим итеп сөйләгез, бик теләп тыңлаячакмын.

– Сугышта бик сәер хәлләр була. Мин үзем японнарның эчке сугышларында шактый катнашкан кеше. Тик аврупа милләтенә каршы сугышта беренче тапкыр катнаша идем, шуңа күрә бу сугыш минем өчен, гомумән, сәер иде.

Төрекчәдән
***Асия Рәхимова** тәрҗемәсе* ■

*1904-1905 нче еллардагы рус-япон сугышының Ялу елгасы ярларында һәм Мукден шәһәре өчен барган иң зур бәрелешләре турында сүз бара (тәрҗ. иск.).

Безнең мирас №12 декабрь 2019

ЗАМАНЕ ИҖТИҺАД МӨНКАРЫЙЗМЫ, ДӘГЕЛМЕ?

Габдулла Буби

Ислам нигезләрендә гыйлемгә каршы һичбер сүз юк, бәлки ислам һәрвакыт акылны мактаганлыктан, бүген игътибар белән өйрәнүчеләрнең аңлаганнары кебек, ачылган хакыйкый гыйлемнең һәрберсе Коръәндә ачык, йә ишарә [белән] искә алынганлыктан, гыйлем арткан саен ислам куәтләнәчәк, аңа иман артачак һәм Коръән бар ителгән зат (кеше. – *А.Г.*) эше түгел, бәлки Аллаһ сүзе икәнлеге тәмам аңлашылачак. Менә Коръәннең һәрбер заманда могҗизалы булуының сере бу. Чыннан да, грек философлары аңлаткан, кешеләрнең акыллары меңнәрчә ел раслаган, хакыйкать дип белгән кагыйдәләренең бик күбесенең хорафат икәнлеге бүген тәмам мәйданга чыккан хәлдә, Коръән һәм Сөннәтнең көн саен ачылган нык хакыйкатьләргә туры килеп баруы, әлбәттә, иң зур галимнәр каршында кабул ителгән, гыйльми булган могҗизалардан. Элекке һәм хәзерге философлардан иң галим бер адәмнең хикмәткә караган сүзләреннән фәкать бармак белән санарлык бик аз хакыйкать булган хәлдә, әхлак һәм канунга, сәясәт һәм өйрәтүгә, моннан башкаларга караган Коръән һәм Сөннәт кагыйдәләренең һәрберсе гыйлем һәм белем булып чыгуы, әлбәттә, философларның акылларын шаштырачак һәм алар каршында Коръән белән Сөннәтнең кадер-хөрмәтен бик арттырачак. Ләкин бу хакыйкатьләр һәм могҗизалар тәкълид белән түгел, фәкать иҗтиһад белән мәйданга чыгачаклар. Мәдрәсәләр тулы укый торган шәкертләребезнең мөселманлыклары да тәкълид белән түгел, бәлки әүвәлге исламга каршы хорафат, бидгать һәм басымнар бетү белән сакланачаклар. Андый хорафатлар габбаси хәлифәләре заманында башланып, бүгенгә кадәр арта-арта килгәннәр.

Кайсыдыр вакытта габбаси хәлифәләре кәлям гыйлеменә тирән карый башладылар һәм бу турыда чит ил кешеләре дә бик күп хезмәт иттеләр. Менә шулвакытта «әйтелде», «әйттеләр» күбәйде, кәлямдә башланган бәхәсләр фикһка да керде: кайсы мәзһәп беренче? Шуннан бәхәскә тотындылар. Әбү Хәнифә белән Шафигый арасындагы каршылыклар турында бәхәсләр башланды, фетнәләр кубарылды, сугышлар ачылды, һәркем үз мәзһәбен таратырга һәм башкаларны бетерергә кереште. Менә шушылай шәригать хөкемнәренең даирәсе төрле хыяллар белән киңәйтелде дә соңгылар, кай нигезгә мөрәҗәгать, хәтта нигез булмаган нәрсәләрдән дә, илтифаттан да гаҗиз калдылар. Димәк, өммәт тәкълидкә карады, галим исемендәгеләр шул дин исемендәге хыялларда тирәнгә ябышты. Һичкемнән дәлил таләп итмәгәнлектән, мөфәссирләр[1] тәфсир китапларын гаҗәеп вакыйгалар һәм җен хикәяләре белән тутырды. Һәрбер кызыклы хикәяләр-хәбәрләрне җыярга тотынды. Фәкыйһләр дә төрле-төрле шөбһәләр белән хөкем чыгарырга тотынды. Димәк, дәртләр кимеде, бетте. Шулкадәр [бетте] ки, хәтта иман белән көферлек арасын аеручы һәм ислам нигезе булган тәүхид[2] мәсьәләсендә дә тәкълид ихтыяр кылынды. Адашу – нурдан,

[1] Мөфәссир - Коръәнгә аңлатма язучылар.
[2] Тәүхид – ихласлык белән бер Аллаһка гына табыну.

* **«Иҗтиһад заманы үттеме, юкмы?»** Ахыры. Башы журналның 7 нче (2019) санында. Текст кыскартылып һәм хәзерге әдәби телгә якынайтылып бирелә.

Габдулла Буби гаиләсе. Хатыны Хөснефатыйма, кызлары Галия һәм Ситдыйка. 1912 ел
(Фото А.Мәхмүтованың «Лишь тебе, народ, служенье!» (2003) исемле китабыннан)

хаклык ялганнан аерылмады. Китаплар катыргысы арасында ни күренсә, шул яхшы, дип табыла башлады. Һәрбер наданлык тәкълид һәм каршылыксыз тану белән өретелде, һәрбер фирка үзенең элекке шәехе чыгарган китапларга, ачык текстка (Коръән һәм хәдисләргә. – *А.Г.*) каршы булса да, фанатизм кыла башлады, каршылыкларны яраклаштырып куллануны нигез итте, һичберсе адәмнәргә дин өлкәсендә ясаган авырлыкларны муенына алудан курыкмады. Болар: «Өммәттәге төрле карашлар – рәхмәт», – диделәр. Дөрес, рәхмәт, ләкин әгәр дөрес кулланылса; әмма әгәр бүген Казан һәм Бохара халкы белән Иран халкы арасында булган кебек, диндә бүленү һәм бер-берсен күралмауга сәбәп булса, ул вакытта, кая рәхмәткә сәбәп булсын, киресенчә, ләгънәт һәм һәлакәт. Болар һәрберсе үзләрен котылган фирка һәм башкаларны яңалыклар кертүче, дип [гаепләп] бәхәсләр генә түгел, хәтта сугышлар кылыштылар. Аллаһ Тәгалә хөрмәтле Китабында һәрбер урында берләшергә куша һәм сәхабәләр йөрәкләренең өлфәтен Аллаһның рәхмәтеннән саный торып, кайсы акыл бу бүленүне рәхмәт дип әйтер?

Дөрес, элеккедәге каршылыклар һичбер фанатизмсыз һәм Китап белән Сөннәттән башка һичбер нәрсәгә багланусыз булганлыктан, бик файдалы һәм өммәткә бик бөек рәхмәт иде. Чөнки һәрбер фәкыйһ үзенең тарафындагы халыкның хәлләренә һәм хәерлегенә карап хөкем йөртер иде. Һичкем бер мәзһәпкә бәйләнеп, ул мәзһәпнең хөкемнәре бер кавемнең әхлагына яки тормыш хәлләренә, яисә илләрнең табигатенә муафыйк, мөлаем килсен-килмәсен хөкеме бирмәс иде. Һәрбер фәкыйһ һәрбер мәзһәпнең дәлиленә карар, тикшерер һәм кайсысының дәлиле куәтле булса, шуның белән хөкем бирер иде. Соңра бер заман килде, һәрбер кавем йә өстен күрү, яки варислык, яисә гади фанатизм белән мәгълүм мәзһәпләрдән бер мәзһәпне ихтыяр [итте] һәм шул мәзһәпнең һәрбер хөкеменә сукырларча тәкълид кылдылар. Бер хөкем үзләренә зарар, аны йөкләү бик авыр булса да, икенче мәзһәптә, аның киресенә, бик ачык дәлилләре күренсә дә, икенче мәзһәптән кайбер хөкемнәр алуны, тәлфыйкны[3] дин белән уйнау мәгънәсендә хәрәм, диделәр. Болар аңламадылар ки, дәлилләрне дикъкатьләп карап һәм гомуми файдаларны саклап, төрле мәзһәптән төрле хөкем алу бер дә дин белән уйнау түгел, бәлки тулысынча дөреслек.

[3] Тәлфыйк – төрле мәзһәптәге карашларны бергә кушу, җыю, берләштерү.

Безнең мирас №12 декабрь 2019

Әгәр бер мөкаллид, мәлики [мәзһәбендәге] галим әйткәнчә, ике савыттан ким суга бер тамчы хәмер төшсә, аны таза (чиста. – *А.Г.*) дип, шуның белән коенса; хәнәфи галим әйткәнчә, ышкымаса; шәфигый галим әйткәнчә, тәһарәте бозылганнан соң, башының кайбер чәчләренә мәсех кылса; хәнбәли галим әйткәнчә, бераз кан чыкканнан соң, иртәнге намазны укыса; зәйди галим әйткәнчә, бу намазны кояш чыкканнан соң укыса; җәгъфәри галим әйткәнчә, әүвәлге фарыздан чыкмыйча, икенче намазга кушса, бу мөкаллиднең намазы Аллаһ каршында дөрес түгел, дип кем исбат итәр? Һичкем [исбат] итә алмас. Хәтта бу намазның каршылыгына да дәлил табу мөшкел; чөнки һичбер мөкаллид дини әмерләренең һәммәсен билгеле бер галимнән алырга шәригатьчә беркайчан да мәҗбүр түгел. Хөрмәтле сәхабәләр дә иҗтиһад һәм хөкемнәрдә каршылыкларга керделәр һәм, шулай була торып, берсе башкасына оеп намаз укыды. Шул ук вакытта, болар, үз иҗтиһадларына нигезләнеп, имамның намазы дөрес түгел һәм аның дөреслеге имамга оючы намазының дөреслегенә шарт, дип хөкем итәләр иде. Димәк, бөек сәхабәләрнең, гомумән, болай эшләүләреннән соң, Әбү Хәнифә имам Мәликкә оюдан, Җәгъфәрнең суйган малын ашаудан сакланыр, шушындый фанатизм-наданлыкка капланыр иде, дип әйтергә кем батырчылык итәр? Шул ук вакытта, бу мәзһәпләрдән һәрбер мәзһәптә өстенлек бирүче исеме белән танылган бик күп фәкыйһләр бар ки, аларның һәрберсе мөҗтәһид һәм һичберсе тәмам үз имамының мәзһәбе белән чикләнмәгән, азмы-күпме хөкемнәрдә аңа каршы килеп, икенче мөҗтәһиднең дәлиле яисә үз имамы тапкан бер дәлилне алыр иде. Чөнки ислам – һәрбер мәсьәләдә имамга түгел, шәригатькә иярү һәм башканың иҗтиһады белән түгел, үз иҗтиһады белән гамәл кылу.

Башка диннәр башына килгән каза ислам башына да килде: күзләр сукырайды, тарафларны тәкълид золымлыгы басты, хәтта [һиҗри белән] бишенче гасырдан соң иҗтиһад бетте, дип әйтүгә кадәр барылды. Шул ук вакытта, бу тарихтан бик күп соң, ягъни һиҗрәттән 751 елда вафат булган Ибне Каййим, шәригать дәвам ителгән кебек, иҗтиһадның дәвам ителүен сөйләгән һәм бу турыда «Игълям әл-мөвәккыйгыйн» исемле бер китап язган.

Ибне Каййим тәкълидтән тәмам бизгән, иҗтиһадның чикләнмәгәнлеген һәм чикләнә алмаячагын бик ачык, бик катгый дәлилләр белән исбатлаган, исламның бидгатьләр белән тулып, нигезеннән чыкканын сөйләгән. Шуңа күрә төзәтү юлына кереп, мәзһәп-фәлән [дип] карамыйча, ислам нигезенә кайтуны өстен күргән һәм киңәш биргән. Әгәр: «Иҗтиһад заманы үтмәде һәм билгеле бер имамның сүзенә тәкълид тиешле түгел», – дип әйтү, сез [әйткән] кебек, көферлек һәм адашу булса, бездән элек кяфер, бездән элек азгын Ибне Каййим һәм дүрт имам үзләре булырга тиешле иде, азрак инсафлык кылыгыз! Эшне уй белән түгел, бәлки дәлилгә карап йөртегез! Аллаһ Тәгаләнең хокукта тигезлекне һәм гаделлекне исбатлау өчен, кешеләр җәмгыятенә иң яхшы һәм иң муафыйк итеп җибәргән ислам ничек бу заманда килеп, мөселманнарга яхшы түгел булып китсен? Исәпләгез ки, ни өчен мөселманнар исламның башлангыч чорында бу кадәр прогресс таптылар һәм ислам эченә мөселман һәм мөселман булмаган бөтен дөньяны рәхәт-рәхәт сыйдырдылар да, хәзер мөселманнар бу кадәр артка киттеләр һәм исламны хәтта үзләре дә сыймаслык бик тар итеп куйдылар? Әгәр сез бөтенләй риза булмасагыз, бу сорауның җавабын Аллаһ Тәгаләнең: *«Сездән алдагы кешеләр белән дә шундый ук хәлләр булды (кешеләр шундый ук сынауларга дучар булды). Җир өстендә йөрегез һәм карагыз»* **[Коръән: 3:137]**; *«Элек яшәгәннәр өчен Аллаһның гадәте шундый булды. Аллаһ гадәтенең үзгәргәнен тапмассың»* **[Коръән: 33:62]**; *«Әгәр аларга: «Аллаһ иңдергән Коръән хөкемнәренә һәм рәсүл гамәленә килегез», – дип әйтелсә, алар: «Ата-бабаларыбызны нинди юлда, нинди гамәлдә тапсак, шул*

безгә җитә», – дип җавап бирәләр. Аларның ата-бабалары хаклыкны белмәсәләр дә һәм туры юлда булмасалар да, шулай эшләрләрме?» **[Коръән: 5:105]** – дигән сүзләрендә табачаксыз! Бар булып торуның хакыйкатендә [Аллаһның] шундый бер сөннәте һәм бер кануны бардыр ки, аңа игътибар иткән адәм мәдәниятнең иң югарысына менгән кебек, аны игътибарсыз куйган адәм дә түбәнлекнең иң түбәненә төшә.

Менә элекке мөселманнар исламның күрсәтмәсе буенча бу канунны аңлап, золым урынына гаделлекне, бозык әхлак урынына вөҗдан сихәтлеген, «Без һәркемнән өстен», дип уйлау урынына дуслыкны, тәкълид урынына иҗтиһадны һәм гыйлем белән хикмәт Кытай мәҗүсиләрендә булса [да], сезнең кебек кире какмыйча, кабул итүне ихтыяр иткәннәр. Шул сәбәпле, тормышларын саклаганнар иде. Соңра бер заман килде: мөселманнар ислам күрсәтмәсен оныттылар, золым һәм бозык әхлакка чумдылар, һәрбер дәүләттән аерылып, мәдәни эшләрдән мәхрүм калдылар, гыйлем һәм хикмәтне, кая мәҗүсидән алсыннар, хәтта яһүди һәм нәсарада күрсәләр [дә] чиркана башладылар. Иҗтиһад һәм фикер йөртүне куеп, яшь балалар кебек, [болар] сукырларча тәкълидне ихтыяр иттеләр, яңа бер файдалы гамәлгә тотынган адәмне юләр [дип], бер китаптан бер мәгънә чыгаруы белән мәшгуль кешене ахмак [дип] санадылар һәм әйттеләр ки: «Кая безгә мондый гамәлләрне эшләргә, кая безгә бу китапларны аңларга?! Куй! Борынгыларга хас эш белән маташма! Инде иҗтиһад заманы узды, безгә тәкълидтән башка нәрсә калмады».

Менә болар иҗтиһад һәм фикерләүне бетереп, тәкълидне исбат [итү] юлында шулкадәр тырыштылар ки, хәтта бер мөселманны үзләре каршысында тезләндереп, тәкълид киемен кияргә мәҗбүр иттеләр. Нигездә, кеше табигате үзе дә тәкълидкә тартым. Яшь баланың хәрәкәте башта, тууыннан соң, төгәл һәм тигез булмаса да, үскән саен имезүчесенең һәм ата-анасының хәрәкәтләренә ияреп тырыша, шулвакытта гамәлендә беренче үзләштерү һәм беренче охшату күренә башлый. Тәрбияле кеше янында торган балаларның әхлаклы, тәрбиясез кеше янында торган балаларның әхлаксыз булулары һәм сыйныфтагы бер әхлаксыз баланың бөтен сыйныфташларына зарар биргәнлеге безнең бу дәгъвабызны, ягъни тәкълиднең кешедә табигый булуын бик ачык күрсәтә. Шуның өчен дә кешедә тәкълид әсәренең бәласе куәтле. Шул дәрәҗәдә ки, кеше тәкълид итә-итә фикерләүләрен куя, хөкем чыгаруларын югалта да, тәкълиде табигый булып китә. Инде бер кеше бу дәрәҗәгә төштеме – сез аннан һич хәерлек көтмәгез! Һичбер гыйлем һәм һичбер эштә прогресс табар, дип исәпләмәгез!

Димәк, табигый булган тәкълидтән котылу өчен билгеле бер чара кирәк ки, әүвәлдә ул – Рәхимлеләрнең Рәхимлесе [Аллаһ] биргән акыл һәм вөҗдан. Хайваннар, акыллы булмаганлыктан, тәкълидләрендә һәм бер хәлләрендә калган хәлдә, кеше акылы белән аз-аз тәкълидтән чыга һәм шулай акрын-акрын прогресс таба. Шуның өчен дә Аллаһ Тәгалә, акылларын файдаланмыйча, тәкълидләрендә калган адәмнәрне хайван кебек, бәлки хайваннан да начаррак, дигән.

Димәк, хайванлыктан һәм тәкълид дәрәҗәсеннән чыгып, кешелек һәм мәдәният дәрәҗәсенә җитү өчен, әлбәттә, акыл һәм фикерне файдаланырга кирәк. Ләкин, кызганыч ки, кешеләрнең бик күбесе, бик күп вакыт бу кануннан чыкканнар һәм акылсыз, фикерсез тәкълидтә нык булып калганнар. Безгә тарих күрсәтә ки, бик элекке заманнан бирле вакыт-вакыт иҗтиһад нуры галәмне яктыртып, гыйлем белән эшне күтәреп җибәрсә дә, аннан соң тагын тәкълид караңгылыгы басып, дөньяны наданлык, әхлаксызлык белән тутырган һәм бу икесе, кичә белән көндез кебек, әйләнеп торган.

Текстны басмага филология фәннәре кандидаты
***Айдар Гайнетдинов** әзерләде.* ■

ХӨСӘЕН МИРЗА

Борынгы татар тормышыннан трагедия

....

Фәтхи Бурнаш

Солтан. Җибәрегез!

Иргали. Әй, кем бар анда! *(Сакчы керә.)*

Сакчы. Ни боерасыз?

Иргали. Шул юлбасарны алыгыз!

Солтан. Мине хуҗага җибәрегез!

Иргали. Каравыл базына ябыгыз! Минем әмеремнән башка беркая чыгармагыз! Барыгыз! *(Ике сакчы Солтанны алып чыгалар.)*

Иргали ялгыз

(*хәлсезләнеп креслога ава.)*

Иргали. Ул һәммә нәрсәне белгән. Хәзер аның башыннан бүтән бернәрсә дә мине коткара алмый. Ләкин элек, нинди бәя белән генә булмасын, аның сүзен алырга кирәк. А! *(Ыңгыраша. Малай керә.)*

Малай. Сезне бер кеше күрергә тели.

Иргали. Ах, тагын. Мин хәзергә бер кешене дә күрергә теләмим... Ә, юк... тукта... кем аның исеме!

Малай. Исемен әйтмәде. Бик алама киенгән бер абзый.

Дәвамы. Башы журналның 8 нче (2019) санында.

Иргали. Барыбер, әйт, керсен! *(Пауза. Әхмәт керә.)*

Әхмәт, Иргали

Иргали. Әхмәт! Син ничек...

Әхмәт. Ул бик яшерен. Миңа хуҗа хәзрәтләрен күрергә кирәк.

Иргали. Ул авыру, кабул итә алмый.

Әхмәт. Урманнан килүче булсадамы?

Иргали. Җәһәннәмнән булса да.

Әхмәт. Качкыннардан илче булсадамы?

Иргали. Шайтан булса да! Ул миңа тапшырды бу эшләрне. Ләкин син бу хезмәтне юкка йөкләгәнсең өстеңә!

Әхмәт. Ни өчен?

Иргали. Өстенә башыңны куярга туры килгәнлеге өчен.

Әхмәт. Мин бит бары илче генә.

Иргали. Барыбер. Чөнки качкыннардан бер кешене дә кичермәскә, кылычтан үткәрергә, дигән әмер бар.

Әхмәт. Син мине куркытыр өчен сөйлисеңме?

Иргали. Бәхетсезлеккә каршы, дөрес, туганым.

Әхмәт. Соң миңа хәзер нишләргә?

Иргали. Хәзергә бер генә юл: үлемгә әзерләнергә.

Әхмәт. Иргали! Без синең белән өченче буын кардәшләре. Үз гомеремдә мин сиңа күп яхшылыклар иттем.

Иргали. Син нәрә әйтергә телисең?

Әхмәт. Мине берәү дә күрмәде: атам бул, җибәр мине, үзебезнекеләр янына китим.

Иргали. Юк, мин моны эшләп, синең урыныңа үзем башны куя алмыйм.

Әхмәт. Соң миңа нишләргә хәзер?!

Иргали. Ах! Нигә син бу эшкә алындың? Синнән башка кем генә килсә дә, миңа җиңелрәк булган булыр иде. *(Пауза.)* Ә, тукта... Сине кемнәр җибәрде?

Әхмәт. Муса белән Бикморзадан кала, бөтен картлар... Мирза безне кичерсә, без аларны тотып бирергә сүз беркеттек.

Иргали. Алайса, сине коткарыр өчен әле бер юл калган.

Әхмәт. Шулаймы?

Иргали. Син аларның кайда торганын әйтәсең.

Әхмәт. Әйе.

Иргали. Үзеңне, алардан качып, тәүбәгә кайту өчен килдем, диярсең?

Әхмәт. Җә.

Иргали. Шулай итсәң, мин, Муса белән Бикморзадан кала, бөтенегезнең гомерен саклап кала алырмын.

Әхмәт. Шулаймы?

Иргали. Ул хәзер чыгар. Син әйтерсең, Муса белән Бикморза һаман халыкны кулларында тоталар, илне күтәрергә, утарларны яндырырга, мирзаларны асарга, кисәргә котырталар, диярсең.Төшендеңме?

Әхмәт. Төшендем. Шулай булса...

Иргали. Шулай булса, мин һәммәгезне дә коткарырмын. Хәзер мин сезне күрештерермен. *(Сулга керә.)*

Әхмәт ялгыз

Әхмәт. Илчегә үлем юк, диләр иде картлар. Ә хәзер кәфенеңне муеныңа урап йөрергә туры килә... Моның ахыры нәрсә белән бетәр икән... Юк... Иргали ялганламас... Ул мирзаны артык яхшы белә. *(Хөсәен, Иргали чыгалар.)*

Хөсәен. Иргали, Әхмәт

Иргали. Менә ул Мөхәммәт улы Әхмәт.

Хөсәен. Ә... хәзер минем каршыма килдеңме?

Әхмәт. Мин шуңа батырчылык иттем, хуҗам.

Хөсәен. Җә...Инде миннән нәрсә өмет итә аласың?

Иргали. Хуҗам! Ул бөтен гөнаһларыннан тәүбә итәр өчен килгән. Әгәр сез аңа тормышын һибә итсәгез, ул сезгә бик күп нәрсәләр хәбәр итә алыр.

Хөсәен. Күрик, ул нинди хезмәтләр белән үзенең гомеренә бәя куя алыр икән...

Иргали. Качкыннарның урыннары турында, шиксез, ул дөрес хәбәр китергән.

Әхмәт. Алар хәзер моннан 10-15 чакрым җирдә, Нагаевлар урманында торалар.

Хөсәен. Сезне ничек безнең казаклар очрата алмадылар?

Әхмәт. Әлегә кадәр безне беркем дә борчыганы юк. Соңгы көннәрдә халык ачлыктан, ялангачлыктан аптырый төште... Алай да...

Иргали. Әле һаман да явыз ниятләреннән кайтырга теләмиләр, ди... *(Әхмәткә.)* Сөйлә!

Хөсәен. Теләмиләр?

Әхмәт. Әйе. Алар әле Сезнең белән килешү турында...

Хөсәен. Мин алар белән һичбер вакыт килешмәм.

Иргали. Муса белән Бикморза халыкны кулларында нык тоталар, ди... *(Әхмәткә.)* Сөйлә!

Хөсәен. А, мин аларның көлләрен җилгә очыртырмын.

Әхмәт. Алар илне күтәрергә, боярларны таларга, утарларны яндырырга котырталар.

Иргали. Хөсәен мирзаның нигезен җир белән тигез итәрбез, диеп әзерләнәләр, ди.

Хөсәен. Шулаймы? Мин аларның тиреләрен энә белән тунармын, мин аларны үз күзем алдында җәһәннәм утына салдырырмын.

Иргали. Рөхсәт бирегез, хуҗам... Мин хәзер үк Әхмәтне алыйм да, капитан-исправникның бар кадәр казаклары белән үзем китим.

Хөсәен. Барыгыз, ашыгыгыз! Әгәр шул явызларның үзләрен, йә киселгән башларын китермәсәгез, бусагамнан кире атлап кермәгез.

Иргали. Сез миңа ышаныгыз, хуҗам! Әгәр дә сүзләрегезне үти алмасам, ачуыгызның иң катысы беренче минем башыма төшсен.

Хөсәен. Барыгыз! Тизрәк! Тизрәк! *(Диванга ава.)*

Пәрдә

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәхнә өченче пәрдәдәгечә. Вакыт кичкә таба. Пәрдә күтәрелгәндә уң кулда Хөсәен белән Мәрьям бикә утыралар.

Хөсәен, Мәрьям

Хөсәен. Син Сараның кичә чынлап та Билал картларда кунуын белеп сөйлисеңме, кошчыгым?

Мәрьям. Дөрес. Билал картның кызы Хәдичә белән алар бергә кунганнар. Башка кызларның әйтүләренә караганда, ул монда кайтырга курыккан.

Хөсәен. Курыккан?

Мәрьям. Әйе, курыккан. Һәм беләсеңме, кемнән... Иргалидән.

Хөсәен. Иргалидән? Бу ничек?

Мәрьям. Керче кызының әйтүенә караганда, Иргали аны борчый торган булган.

Хөсәен. Мин моңа ышанырга да теләмим.

Мәрьям. Акыллым, бәхетсезлеккә каршы бу шулай. Иргалинең Сарага дөрес карамавын мин үзем дә сизгәнем бар.

Хөсәен. Кошчыгым, син акылыңдамы?

Мәрьям. Мин хәзер һәммәсенә төшендем. Иргали аның кулын сорарга теләгән.

Хөсәен. Юк, мин әле һаман ышанмыйм. Иргалинең гаиләсе, ике баласы бар. Аның өстенә ул бит крепостнойлар арасыннан чыккан кеше. Ул бары минем мәрхәмәтем аркасында гына шушы дәрәҗәгә иреште.

Мәрьям. Болар бары да дөрес. Ләкин аның Сарага булган карашлары турындагы бу сүзләр дә дөрес.

Хөсәен. Мин нигә моңача ул турыда бернәрсә дә сизмәдем.

Мәрьям. Сара андый нәрсәләрне чәчеп йөрерлек акылсыз кыз түгел. Аннан соң аның күңеле бит Иргалидә дә түгел...

Хөсәен. Ай, сөйләмә миңа артык. Ахыры болай булса, минем йортым бөтенләй диваналар йортына әйләнер.

Мәрьям. Бүген дә Бибисараны тапмасалар, Алла сакласын, мондый вакытта аның качкыннар кулына эләгүе мөмкин.

Малай. Сезгә капитан керергә тели.

Хөсәен. Керсен!

Мәрьям. Мин калдырыйм сезне. *(Капитан керә.)*

Хөсәен, капитан

Капитан. Хәерле кичләр телим!

Хөсәен. Капитан әфәнде, Сезне тыңлавыма бик шатмын.

Капитан. Урманнан хәбәр алдым. Качкыннар, безнең хәзерләнүләрне сизеп, урыннарын алмаштырганнар. Шуңа карамастан, безнең казакларыбыз үз бурычларын каһарманнарча үтиләр. Хәзер без эзләренә төштек. Берничә сәгатьтән алар камалган булачак.

Хөсәен. Ниһаять!

Капитан. Мин бүген килгән отрядтан тагын 60 кешене Халит старшина карамагында качкыннарның каршысына чыгарга җибәрдем.

Хөсәен. Илнең тынычлыгын ничек күзәтәсез?

Капитан. Бүген кичен урманга тагын биш егетнең китүен хәбәр иттеләр. Янәсе качкыннарның тиздән илне басарга килүләре турында яман телләр халык арасына шактый коткы таратканнар.

Хөсәен. Сез нинди чаралар күрдегез?

Капитан. Мин сезнең киңәшләрегезне көттем.

Хөсәен. Утардагы сакчыларны көчәйтегез. Калган көчләрегезнең һәммәсен урманга!

Капитан. Тыңлыйм!

Хөсәен. Качкыннар чыккан һәммә йортлардан, яшь балалардан калганнарын подвалларга төягез.

Капитан. Тыңлыйм!

Хөсәен. Бүген кичен урманга китүчеләрнең калган ата-ана, кардәш-ыруларын каравыл базына тутырыгыз. Барыгыз!

Капитан. Баш өсте!

Хөсәен. Губернатор хәзрәтләренә рапортыгызны хәзерләгез. Мин дә аңа үземнең сәламемне язармын.

Капитан. Һәммәсе тиешенчә эшләнгән булыр. *(Капитан чыга, малай керә.)*

Малай. Сезгә картлар керергә телиләр.

Хөсәен. Картлар? Әйт шул этләргә, керсеннәр... *(Малай китә.)* Карыйк, хәзер алар ничек сөйләшерләр икән минем белән. *(Тәрәзәдән карый. Картлар керәләр.)*

Хөсәен, картлар

Картлар. Әссәләмегаләйкем!

Хөсәен. Бүген мин кирәк булдыммыни, сөйләгез!

1 нче карт. Хуҗам! Сез безнең хәлебезне үзегезнең биш бармагыгыз кебек беләсез.

Хөсәен. Сез миңа йомышыгызны сөйләгез!

1 нче карт. Яшьлек-җүләрлек, дигәндәй, Сез улымның качкыннар коткысы белән киткәнен беләсез.

Хөсәен. Синең улың беренче нәүбәттә тотып асылырга тиеш. *(Икенче берәүгә.)* Шулай ук синең улыңның да үз кулы белән амбарларга ут төрткәнен күргәннәр – ул да табылган урынында тотып атылачак.

2 нче карт. Улларыгыз качкын диеп, бөтен игеннәребез, бөтен нәрсәләребез тартып алынды. Без хәзер ачлыктан үләчәкбез.

Хөсәен. Сезнең икмәкләрегезне генә түгел, күптән җаннарыгызны суырып алырга кирәк иде.

3 нче карт. Минем улым качкыннар белән китмәде, Ходаның язмышы белән, читкә киткән җиреннән юк булды. Шуның өчен Сез минем унбиш яшьлек бердәнбер кызымны урыс казагына тотып бирдегез.

Хөсәен. Кызыңа шайтан да булмаган. Үзең теләмәсәң дә, бер айдан аны сиңа кайтарып бирерләр.

3 нче карт. Ә соң намусы?..

Хөсәен. Анысын, әнә, качкыннардан сорарсың. Җә, тагын?

4 нче карт. Бүген минем арысландай өч улымны калага озаталар... Алар бернәрсәгә катнашмадылар...

Хөсәен. Син әле аларның әнә шул имән агачларына асылмаган булуларына шөкер ит. Җә, беттеме?

4 нче карт. Сез минем балаларымны кайтарыгыз!

Хөсәен. Барыгыз! Бүген сез миннән чәчәк очы кадәр дә мәрхәмәт көтмәгез. Мин бүген сезнең этләрегез – качкыннар белән хисабымны өзәчәкмен. Аларны көткән җәза иң элек үзегезгә төшүен теләмәсәгез, алыгыз моннан башларыгызны!

3 нче карт. Оятсыз!

Хөсәен. Молчайть! Югалыгыз, этләр! *(Картлар чыгалар. Хөсәен, ачуыннан хәлсезләнеп, креслога ава. Бераздан малай керә.)*

Малай. Сезгә тапшырырга куштылар... *(Хат бирә.)*

Хөсәен. Бу кемнән булырга мөмкин. *(Ачып укый.)* «Мин кичәдән бирле сезне күрә алмыйча каравыл базына ябылдым. Коткара күрегез. Солтан». *(Урыныннан тора.)* Солтан! Ул ничек анда ябылган! Әй, кем бар анда? (*Малай керә.)* Бар, әйт, хәзер үк Солтанны каравыл базыннан коткарсыннар, монда китерсеннәр! Тизрәк! *(Малай китә.)* Кем аны ябып куйган булырга мөмкин? Билгеле, Иргалидән башка кеше булырга мөмкин түгел. Ләкин бу ничек мөмкин? Монда нәрсә булса да минем белүемнән тыш нәрсә яшеренгән булырга тиеш. *(Солтан керә.)*

Солтан, Хөсәен

Солтан. Хуҗам, Сезгә җаным фида булсын!

Хөсәен. Сиңа ни булды, сөйлә тизрәк!

Солтан. Хуҗам, мин аны соңгарак сөйләрмен. Ә хәзергә мин сездән үтенәм...

Монда сезнең капкагыз алдында Иргалине көтеп торган бер карчык бар. Ул сезнең өчен җәүһәрдән дә кадерлерәк булачак. Зинһар, хәзер үк шул карчыкны яныгызга китерергә әмер итегез.

Хөсәен. Әй, ябалак! *(Малай керә.)* Капка төбендә Нургалине көтеп торган бер карчык булыр. Хәзер үк аны миңа китерсеннәр! *(Малай китә.)* Йә, Солтан, инде син миңа үзеңнең хәлләреңне сөйлә.

Солтан. Мин кичә көндез үк килгән идем. Сәбәпләрен тиздән төшенерсез. Хәзергә кадәр мин сезне күрә алмадым.

Хөсәен. Җә!

Солтан. Мин Сезгә качкыннар турында искитәрлек хәбәрләр белән килгән идем.

Хөсәен. Хәзер алар турында безгә күп нәрсәләр ачылды.

Солтан. Шулай булырга кирәк иде. Шуның өчен мин сезне күрергә ашыккан да идем. Качкыннар арасында Муса белән Бикморзага каршы зур эш оештырылды, алар хозурыгызга кайтып баш иярга сүз беркеттеләр.

Хөсәен. Мин әле моны беренче тапкыр ишетәм.

Солтан. Шулай ук, әгәр Сез качкыннарны гафу итсәгез, алар Муса белән Бикморзаны тереләй китереп кулыгызга тапшырырга булдылар.

Хөсәен. Син дөрес сөйлисеңме?

Солтан. Аяк астыгызда туфрак булсам икән. Без шул хакта Сезгә илче дә сайлап җибәрдек.

Хөсәен. Әйе, Әхмәтне. Ләкин ул миңа бөтенләй моның киресен сөйләде.

Солтан. Бик дөрес. Чөнки сезгә кадәр Әхмәтне Иргали кабул итте.

Хөсәен. Мин бернәрсә дә аңламыйм.

Солтан. Сез хәзер аңларсыз, хуҗам. Мин кичә шушы хәбәрләр белән килгәндә, гадәтемчә яшеренеп кергән идем. Мин анда Иргалинең бер яшь егет белән яшертен сүзләр алып баруын тыңладым. Иргали мине тотты һәм, миннән бер сүз дә ала алмагач, каравыл базына яптырды.

Хөсәен. Минем колакларым дөрес ишетәләрме?

Солтан. Ә ул, Иргали белән сөйләшкән яшь егет, бу карчыкның улы булса кирәк. Менә шунда бәйләнгән дә искиткеч бу эшләрнең җеп очлары. *(Гөлбәһар керә.)*

Гөлбәһар, Хөсәен, Солтан

Солтан. Менә ул, сезнең күптән зарыгып көткән кешегез Гөлбәһар карчык түгелме, хуҗам?

Хөсәен. Туктагыз! (*Артка чигенә.)*

Солтан. Гөлбәһар карчык безгә һәммәсен дә аңлатып бирергә тиеш.

Хөсәен. Чү! Кил мондарак, карчык! Син чынлап та балаларның сөт анасы Гөлбәһармы?

Гөлбәһар. Хуҗа хәзрәтләре үзләренең сүзләрендә ялгышмыйлар. *(Мәрьям чыга.)* Мин – Гөлбәһар!

Мәрьям һәм башкалар

Мәрьям. Бу ни күрәм? Гөлбәһар!

Хөсәен. Әйе, Гөлбәһар. Бакчачы Хәсәннең, минем бердәнбер улымны һәлак итүче Хәсәннең карчыгы...

Гөлбәһар. Туктагыз, сезнең юлыгызда мең газаплар күреп, кырык кат туфракның күкрәгенә иңгән картның исемен яманлык белән яд итмәгез.

Хөсәен. Җә, Гөлбәһар... Нинди өметләр белән син минем бусагамны яңадан атларга уйладың?

Гөлбәһар. Миһербанлы хуҗам! Минем агарган чәчләрем нинди дә булса өметләргә бәйләнүдән узганнар инде. Тик минем ир булып килә торган улым Ибраһим бар. Хуҗа хәзрәтләре гомерен һибә[1] итсен дә, миңа үлемемне тыныч каршыларга ирек бирсен иде.

Хөсәен. Сез минем артык ачулы сәгатемә очрадыгыз.

Гөлбәһар. Сез минем улымны кичерергә бурычлысыз.

Хөсәен. Һичбер вакытта.

Гөлбәһар. Әгәр дә сезнең үз улыгыз исән булсадамы?

Мәрьям. Чү!

Хөсәен. Кем? Искәндәрме?

Гөлбәһар. Әйе. Сез ул вакытта минем улымны нишләтер идегез?

Хөсәен. Тукта, син акылыңдамы? Әллә юкса бер хурланган күңелне тагын бер мыскылларга әйтәсеңме?

Гөлбәһар. Түгел. Мин бары улыгыз Искәндәрнең бүгенге көн сәламәт булуын гына әйтергә телим.

Мәрьям. Мин нәрсә ишетәм!

Хөсәен. Гөлбәһар!

Гөлбәһар. Әйе. Бүгенге көнне ул сәламәт.

Мәрьям. Ярабби!

Хөсәен. Чү! Син акылыңдамы? Әллә юкса мин төш күрәмме?

Мәрьям. Гөлбәһар! Әйт, кайда ул Искәндәр?

Гөлбәһар. Сабыр итегез! Егерме елдан артык чиккән хәсрәтләрегезне җуярлык сүзләремне бер-ике минут кына тыңларга батырчылык итегез.

Хөсәен. Сөйлә, Гөлбәһар, тизрәк сөйлә!

Гөлбәһар. Моннан 22 ел элек балагыз Искәндәр көпә-көндез юк булды. Баланың ачуы үзебезгә төшәсен сизеп, нигезебездә бер җан калдырмыйча, без дә шул ук көнне илне ташладык.

Хөсәен. Шулай... шулай...

Гөлбәһар. Без баланың урлануыннан шикләнеп, аны тапканчы илгә кайтып күренмәскә булдык.

Хөсәен. Шулай...

Гөлбәһар. Без Уралга киттек. Сезнең токымыгыздан булган бер мирзаның да бусагасын калдырмадык. Уралда Адашовлар бар...

Хөсәен. Әйе... минем сеңлем аларда...

Гөлбәһар. Соңыннан без бу эшнең шул Адашовлар кулы белән эшләнгәнен белдек.

Мәрьям. Ах, нинди ерткычлар!

Хөсәен. Җә, сөйлә, сөйлә!

Гөлбәһар. Ләкин алар, 8 яшь тулгач, Искәндәрне бер көтүчегә балалыкка биргәннәр.

Мәрьям. Ай, бәбкәм!

Хөсәен. Мошенниклар!

Гөлбәһар. Ул арада унбиш ел вакыт үтте. Искәндәр, кулдан-кулга сатылып йөргәч, качкыннар арасына эләккән дә...

Мәрьям. А, йөрәгем...

Хөсәен. Сөйлә, сөйлә...

Гөлбәһар. Казаматка кергән.

Мәрьям. Ярабби!

---

[1] Һибә – бүләк.

Гөлбәһар. Качкыннар аны казаматтан чыгарганнар. Ул шуннан соң талаучыларның башында йөргән. Боярларның утарларын, малларын, үзләрен яндырып йөргән.

Хөсәен. Минем улым качкын булган!

Мәрьям. Ах! (*Хәлсезләнә.)*

Гөлбәһар. Мин, чәчләрем агарып, билләрем бөкрәйгәч кенә, Искәндәрнең эзенә төштем. Шул арада мин картымны җирләдем, ике кызымны чит-ят илләргә кияүгә биреп калдырдым.

Хөсәен. Тизрәк, тизрәк, сөйләп бетер, карчык.

Гөлбәһар. Сабыр итегез. Бу арада мин әллә ничә кат Сезнең утарыгыз яныннан үтеп, капка төбегездә ял иттем.

Мәрьям. Зинһар өчен, тизрәк!

Гөлбәһар. Әйтегез әле...

Хөсәен. Җә, нәрсә?

Гөлбәһар. Моннан нәкъ ике ел элек сезгә помещик Красильников килдеме?

Хөсәен. Әйе, ул безгә киләдер иде, җә?

Мәрьям. Нәрсә булган?

Гөлбәһар. Яхшы хәтерләгез, ул Сезгә бер егет китереп сатмадымы?

Хөсәен. Әйе, Мусаны китерде. Җә, җә, ул минем Искәндәремне белә, шулаймы?

Гөлбәһар. Түгел.

Хөсәен. Ул – Искәндәрнең иптәше, шулаймы?

Гөлбәһар. Юк... Ул үзе Искәндәр...

Мәрьям. Ах!

Хөсәен. Искәндәр! Тукта! Син акылың белән сөйлисеңме? Йә булмаса... тукта...

Гөлбәһар. Мин дөресен әйтәм. Аңа Муса исеме соңыннан бирелгән, ул сезнең улыгыз, Сараның туганы Искәндәр.

Солтан. Хуҗам! Тәдбир[2] күрегез!

Мәрьям. Муса – Искәндәр...

Хөсәен. Минем нигеземне туздыручы, миңа кылыч күтәрүче, минем данымны таптаучы Муса – үз балам.

Гөлбәһар. Мин улым Ибраһимны алдан җибәргән идем. Ләкин Сезнең ышанычлыгыз бу нәрсәләрне Сездән яшерергә тиеш күргән.

Солтан. Хуҗам! Инде төшендегезме Иргалинең нәрсә өчен болай ашыгуына.

Хөсәен. Ах, нәләт төшсен ул Иргалигә! Мин кичә генә, Искәндәрнең башын кисеп кайту өчен, биш йөз мылтыкка баш иттереп, аны качкыннарга каршы җибәрдем.

Солтан. Хуҗам... чара күрегез...

Мәрьям. Кошчыгым! Тизрәк!

Хөсәен. Әйдәгез!.. Кайда кем бар? Кайда минем егетләр, юргалар?.. Әйдәгез урманга, Искәндәрне коткарырга! ***(Солтан алдан чабып чыга, малай йөгерә, артта быргы тавышлары килә, артка китәләр.)***

Пәрдә

[2] Тәдбир – эшне ахырын уйлап эшләү; чара күрү.

Безнең мирас №12 декабрь 2019

«Тылсымлы тартма»ның... беренче адымнары

Әгъзам Фәйзрахманов

Дикторлар Әминә Сафиуллина, Абдулла Дубин, Иркә Сакаева һәм Айрат Арсланов. 21 март, 1964 ел

Күренекле сәнгать белгече **М.И.Андроникова** «Кинога ничә яшь?» дигән китабында болай дип язган иде: *«Телевидениенең пыяла экранында сурәт һәм сүз нәкъ менә шушы вакытта, шушы минутта адреслана. Тере нәрсә кебек ул хәрәкәт итә, сөйли, безгә мөрәҗәгать итә. Сәнгать әһелләре бу хакта ничә гасырлар дәвамында хыялланды. Рәсем һәм кино сәнгате осталарының, графикларның, скульпторларның, фотографларның озак еллар дәвамында алып барган эзләнүләре шушы нәтиҗәгә китерде. Телевидение безнең көндәлек тормышыбызга нык үтеп керде».*

Казан телевидениесе тапшыруларын оештыру буенча эш үткән гасыр урталарында башлана. Радиосөючеләр, шәһәр предприятиеләре инженер-техник хезмәткәрләре, Татарстан җитештерү-техник элемтә идарәсе һәм республиканың ДОСААФ комитеты көче белән, Казанда үзешчән телеүзәк оештырыла. Уртак көч куеп, ул, тәҗрибә рәвешендә, 1955 елның 27 февралендә тапшырулар бирә башлый: фильмнар күрсәтелә, үзешчән һәм профессиональ артистларның чыгышлары тәкъдим ителә.

1955 елның 3 мартында «Советская Татария» газетасында ТАССРның ДОСААФ радиоклубы башлыгы А.Трашковның «Казанда телевидение» дигән мәкаләсе басыла: *«1953 елның көзендә үк шәһәрнең радиотехник җәмәгатьчелеге Казанда кече телеви-*

«СССРның халык рәссамы В.А.Серов белән очрашу» дигән тапшыру башланыр алдыннан (сулдан уңга): А.Дубин, В.А.Серов, А.Арсланов, Х.Якупов. 26 гыйнвар, 1962 ел

зион үзәк булдыру мәсьәләсен күтәрде. Телеүзәк төзү буенча практик бурычларны хәл итү өчен, 1954 ел башында ДОСААФ радиоклубы каршында инициатив төркем оештырылды, – дип яза автор. – *Шактый эш башкарылды инде. Көчәйткеч куәтләр, кинескоп камералары, башка җиһазлар әзерләнде һәм көйләнде. Сигналларны тапшыру өчен махсус телетапшыру антеннасы куелды, телеүзәктә тулаем көйләү эшләре башланды. 27 февральдә, беренче тапкыр буларак, кинофильм, сынау таблицасы (телевизорларны көйләү өчен) бирелде. Шәһәрнең кайбер агитпунктларына куелган телевизорларда тапшыруның сыйфаты канәгатьләндерерлек иде.*

Казанда кече телеүзәк булдыру буенча гамәлләрне эшчәнлекнең беренче этабы, дип санарга кирәк. Икенче этап куәтләрне сизелерлек көчәйтүне күздә тота. Ул тапшыруларны шәһәрдә генә түгел, аның тирә-ягында да карау мөмкинлеген бирергә тиеш. Гамәлдәге телеүзәкнең эшен туктатмыйча, 5-6 ай эчендә моңа ирешергә мөмкинлек булачак».

Шунысын да әйтергә кирәк, казанлылар Мәскәү тәҗрибәсен җентекләп өйрәнә, алар кулланган ысулларны үзләрендә кат-кат сынап карый.

Казан телевидениесе тапшыруларын башлап җибәрүгә элемтәчеләрдән Г.Б.Бобек, С.Д.Трутнев, В.Т.Варанов, А.Н.Трашков, Ә.Ш.Шаһиваәлиев күп көч куя. Радиокомитет рәисе М.Ф.Долгов та оештыру мәсьәләләре белән даими шөгыльләнә. Татарстан радиосының кайбер хезмәткәрләре телевидение һөнәрләрен үзләштерүгә керешә. Иҗтимагый-сәяси тапшыруларны радионың баш мөхәррире Итфал Ихсанов редакцияли һәм алып бара. Промышленность тапшыруларын радио редакторы Николай Грачев әзерли.

Кече телеүзәк эшчәнлегенең беренче айларында, нигездә, нәфис фильмнар күрсәтелә. Ә 1957 елның ахырында тамашачылар инде театр спектакльләрен, үзешчәннәр чыгышын карый башлый. Бер үк вакытта иҗтимагый-сәяси, балалар-яшүсмерләр программаларын да формалаштыру башлана. 1958 елда инде һәр көнне диярлек телевидениедән

Яңа елга багышланган тапшыру вакытында (сулдан уңга): Э.Хамматова, А.Дубин, Л.Заһидуллина, И.Сакаева. 26 декабрь, 1976 ел

«Соңгы хәбәрләр» тапшырыла.

1959 елның октябрь ахырында Казанда заманча проект буенча салынган телеүзәк төзелеп бетә. Ул 300 һәм 50 квадрат метрлы ике студияне берләштергән дүрт камералы аппарат-студия блогыннан тора. Яңа телеүзәк 1959 елның 1 ноябрендә ачыла. Бу көнне дүрт сәгатьлек программа күрсәтелә. Студиягә бик күп кунаклар чакырыла. Алар арасында төрле тармакларда эшләүче хезмәт алдынгылары, барлык театрлар-

Дикторлар Иркә Сакаева, Абдулла Дубин, Рөстәм Нәбиуллин. 1 май, 1976 ел

Телевидение режиссерлары (сулдан уңга): Эдмас Үтәгәнов, Эмиль Ключарев һәм телеоператор Әнвәр Миңнуллин

дан артистлар, җырчылар, музыкантлар, язучылар, партия-хуҗалык җитәкчеләре дә була. Алтмыш ел элек Ш.Усманов урамында ачылган телевидение студиясе бүген дә тапшырулар алып бара. Билгеле инде, ул алтмыш ел дәвамында шактый киңәйтелгән, яңа корпуслар төзелгән. Телевизион техника да бөтенләй башка төрле инде.

Яңа студиянең төп иҗат составын кече телеүзәктә эшләп бераз тәҗрибә туплаучылар тәшкил итә. Телеүзәкне Герман Бобек (немец милләтеннән) җитәкли. Бирегә эшкә элек радиода эшләгән редакторлар Итфал Ихсанов, Николай Грачев, Кыям Янгулов, Фәүзия Бурнашева, дикторлар Айрат Арсланов, Әминә Сафиуллина, директор булып Зәйнәп Хәйруллина күчә.

Казан телевидение студиясендә кино төркеме оештыручы һәм аның беренче башлыгы В.Говорухин булды. Соңрак ул Мәскәүдә төрле студияләрдә эшләде, кинорежиссер буларак, нәфис фильмнар төшерде. Казан телестудиясендә штатка беренче кинооператор итеп Искәндәр Шәмсетдинов, аның ассистенты итеп Эльдар Юмакулов кабул ителә. Беренче телеоператорлар төшереп кайткан киноматериалларны, бик примитив юл белән, мичкәләргә салып «проявить иттеләр». Бу эшне Куйбышев исемендәге химия заводы лабораториясеннән килгән Галина Гревцева башкара иде.

1959 ел ахырында режиссерлар төркеме дә оештырыла. Телевидениенең беренче баш режиссеры итеп Кәшфи Гаделшин билгеләнә. Элеккеге радио һәм театр режиссерлары телевидение режиссеры һөнәрен үзләштерергә керешә. 60 нчы елларда телевидениедә В.Мурзин, Г.Хөсәенов, Вера һәм Иван Прошкуратовлар, К.Косарева, Р.Сакаев, Р.Шиһапов, Н.Кузовенкова һәм башка режиссерлар бик нәтиҗәле эшли иде инде. Беренче телефильмнарның музыкаль режиссеры вазыйфасын Мансур Сабиров башкарды.

Шул ук чорда республика телевидениесенең төп бурычлары һәм вазыйфасы билгеләнде. Нәтиҗәдә, төрле кешеләрнең ихтыяҗын канәгатьләндерү мөмкинлеге туды. 1961 елда тамашачыларның хыялы тормышка ашты – төрле вакыйгаларны ту-

Әдәби-драматик тапшырулар редакторы Эльс Гаделев (сулда), Үзәк радио һәм телевидениенең Идел буе төбәкләрендәге үз хәбәрчеләре Абрам Кринкин һәм Ильяс Латыйпов

Кинооператор Юрий Гвоздь

рыдан-туры урыннан күрсәтә торган күчмә телевизион станция (ПТС) эшли башлады. Театрлардан, концерт залларыннан, стадионнардан, завод-фабрика цехларыннан репортажлар бирелде.

Татарстан телевидениесенең башлангыч чоры тарихындагы тагын бер датаны билгеләп үтү урынлы булыр. 1962 елда Казан телеүзәге СССР Үзәк телевидениесенең беренче программасын ретрансляцияләү һәм үз тапшыруларын каналлар аша Үзәк телевидениедән күрсәтү мөмкинлеген алды. Бераз соңрак җирле программа өчен махсус канал булдырылды.

Татарстан дәүләт телевидениесе тапшырулары башлануга 60 ел тулды. Минем үземә дә, үткән гасырның алтмышынчы еллар урталарыннан башлап 26 ел дәвамында, телевидениедә хезмәт куярга туры килде. Башта өлкән, аннары баш мөхәррир булып эшләдем. Бер үк вакытта телевидениенең партком секретаре да идем. Бүген дә мин радио-телевидение коллективы җитәкчесе Фаик Надыйровны, аның телевидение буенча урынбасары Хәйдәр Шакирҗановны, шулай ук минем белән бер чорда (һәм аннан соңгы елларда)

Телеоператор Дамир Батыршин һәм диктор Абдулла Дубин. 1 май, 1982 ел

Дикторлар (сулдан уңга): Айрат Арсланов, Рөстәм Нәбиуллин һәм Әминә Сафиуллина

эшләгән хезмәттәшләремне, әйтик, И.Сакаева, Р.Нәбиуллин, А.Дубин, И.Хәйруллин, Т.Сәгыйтов, В.Булычев, Н.Ногманова, Л.Нигъмәтова, И.Сирматов, Г.Зиннәтуллина һәм башкаларны зур хөрмәт белән, сагынып искә төшерәм. Ни кызганыч, Казан телевидениесенә нигез салган, аның программаларын формалаштырган затларның күпчелеге бүген безнең арада юк инде. Әмма аларның хезмәте бушка китмәде, шөкер.

Фотолар Ә.Фәйзрахманов һәм А.Дубин архивыннан алынды. ■

ИСКЕ МӘҢГӘРНЕҢ
борынгы зиратындагы ташъязма истәлекләр

Ирек Һадиев, Раиф Мәрданов

Иске Мәңгәрнең борынгы зираты янындагы «Әүлия кабере»

Казан ханлыгы чорыннан калган гарәп язулы ташъязма истәлекләрнең иң күп тупланган урыннарыннан берсе – Әтнә районындагы Иске Мәңгәр авылының борынгы зираты. Анда XV гасыр ахырына һәм XVI гасырга караган, төзек хәлендәге яки ватылган кисәкләр рәвешендәге 15 данә борынгы ташбилге хәзерге вакыткача сакланган. Ташларның иң элеккесе – 1495 ел, соңгысы 1543 ел белән даталана.

Әдәбиятчы һәм тарихчы Гали Рәхим 1927-1928 елларда ташъязма истәлекләрне өйрәнгән вакытта биредә шулай ук 15 кабер ташы булганлыгын язган, унберенең тулы яки өлешчә текстларын бастырган, язулары сакланмаган дүртесенә кыскача тасвирлама биргән[1]. Хәзерге вакытта ташлардагы язулар шактый җуелган булса да, берничәсенең

[1] Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз.: Р.Мәрданов, И.Һадиев. – Казан: Җыен, 2008. – Б.259-266.

Иске Мәңгәрдәге борынгы зират күренеше

текстларына безнең тарафтан өстәмәләр һәм ачыклыклар кертелде. Мәсәлән, берсендә кеше исеме дөресләнде һәм датасы танылды, тагын җидесендә ян-як язулары укылды (Г.Рәхим хезмәтендә күп истәлекләрнең ян-як текстларына әһәмият бирелмәгән, кайберләренең андый язулары булса да, юк, дип күрсәтелгән). 1495 һәм 1531 елларда куелган ташъязмалар турында мәгълүмат һәм аларның текстлары Гали Рәхимдә бөтенләй юк, гомумән, алар – татар эпиграфикасында әһәмиятле өр-яңа табышлар. 1594 елда вафат булган Җәнәйсолтан Чапкын хатынына Иске Мәңгәр авылының борынгы зиратында куелган, Г.Рәхим күреп өйрәнгән ташъязма бүген Татарстан Дәүләт сынлы сәнгать музее фондларында. Зиратта хәзергәчә сакланмаган тагын бер таш 1920 нче еллар ахырында ук ватылып яткан, Г.Рәхим аның кисәкләрен җыеп укыган мәгълүматлардан күренгәнчә, мәрхүм «кяфер кулындин шәһид» булган. Яхшырак сакланган арткы өслегендә ташбилгене анасы Күрекле бикә куйдырганлыгы бик үзенчәлекле матур бизәк эченә язылган. Әлеге ташның фотосы Г.Рәхим һәм Һ.Йосыпов

хезмәтләрендә бар. Шуңа охшаш штамп-бизәкләрне без бу төбәкнең Олы Бәрәзә һәм Комыргуҗа зиратларындагы борынгы ташларда күрдек. Аларның беренчесе – 1520 елга, икенчесе 1541 елга карый. Димәк, Иске Мәңгәрнең борынгы зиратында без тапмаган ташны да якынча 1520-1541 елларда куелган, дип санарга мөмкин.

Галим Һарун Йосыпов Иске Мәңгәрдәге борынгы зиратның өч кабер ташын эпиграфик истәлекләргә багышланган мәгълүм китабына керткән, гарәп язулы текстларын һәм аларның русчага тәрҗемәләрен, фоторәсемнәрен бастырган[2].

Татарстанның археологик һәйкәлләренә багышланган белешмәлектә Иске Мәңгәрнең XVI гасырга караган ташъязмалары уннан артык дип күрсәтелә, унбер ташның үлчәмнәре бирелә, калып-бизәлешләре турында кыскача әйтеп үтелә[3].

Иске Мәңгәр авылының борынгы зиратындагы эпиграфик истәлекләр арасында сәнгати эшләнеше җәһәтеннән аеруча затлы һәм купшы бизәкле, чәчәк-үсемлек һәм геометрик орнаментлар мул һәм зәвыклы кулланылган, гарәп каллиграфиясенең гаҗәеп матурлыгын чагылдырган үрнәкләр бар.

Иске Мәңгәрнең борынгы зиратына якын гына, аның көнбатыш тарафында чардуган белән әйләндереп алынган, ике зур агач үсеп утырган аерым каберлек бар. Халык телендә ул «Әүлия кабере» дип йөртелә. Гали Рәхим андагы ялгыз ташның текстын тулаем һәм төгәл итеп укый алмаган, датасын да XVI гасырның беренче яртысына нисбәт итү белән чикләнгән. Безнең тарафтан ташъязманың елы (927 һиҗри = 1521 миладӣ) укылды, Г.Рәхим «Әҗем угылы Бикбау» дип күрсәткән исемнең дөресе «Хаҗим угылы Баубик» икәнлеге тәгаенләнде. Ә шушы исемнән соң язылган хатын-кыз исемен «Кичәш бикәч» дип укыйбыз. Алга таба шушы хатын-кызга караган «Аккына бикәч» дигән сыйфатлама таныла. «Бикәч» сүзенең мәгънәсе «кәләш» һәм «яңа гына кияүгә барган яшь хатын» дигәнне белдерә.

Ташның артындагы текстның укылышын Г.Рәхим тулаем биреп бетерми. Безнең вариант тулырак һәм ул мондый: «Бу ләүхне атасы Хаҗим белә валидәсе ... бина кыйлды». Димәк, Баубикнең атасы Хаҗим һәм анасы яшь киленнәре Кичәшкә шушы ядкәрне куйдырганнар.

Тарихи әһәмияткә ия татар ташъязма истәлекләренең хәзерге сакланышы, тулаем алганда, зур борчу тудыра. Әмма ауган һәм кыйшайган ташларны күтәреп, бастырып куйган, чардуган кору, ватык ташларны төзәтү кебек саваплы гамәлләр кылган игелекле затлар да бар. Андыйлар элек тә булган. Гали Рәхим язганча, сәүдәгәр Бакиров XIX гасыр ахырында Иске Мәңгәрнең борынгы зиратын саклау чараларын күргән: аның әйләнәсенә канау казыткан, агачлар утырттырган, кабер ташларын чистарттырган[4].

2015 елда шушы ук борынгы зират ул вакытта **Лотфулла Шәфигуллин** җитәкләгән **«Таттелеком» АҖ** тырышлыгы белән кабат төзекләндерелде: тимердән челтәрләп ясалган капка-коймалар, чардуганнар куелды, борынгы ташлар реставрацияләнде.

Борынгы зиратлар һәм алардагы ташъязма истәлекләргә карата мондый игътибар, әлбәттә, бик куанычлы. Милли тарихыбыз истәлекләренә иң бай төбәкләрнең берсе булган Әтнә районындагы башка каберлек һәм ташбилгеләргә дә алга таба шундый ук әһәмият бирелер, дип ышанабыз. Бу уңайдан Әтнә төбәгенең үзендәге элекке ташларга уелган «Асаре кадимне сакламак – Аллаһка сөекле эш» дигән тирән мәгънәле гыйбарәне искә төшерү бик урынлы булыр.

[2] Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.–Л.: изд-во АН СССР, 1960. – Приложение: табл. 65, 67, 70.

[3] Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – С.102.

[4] Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз.: Р.Мәрданов, И.Һадиев. – Казан: Җыен, 2008. – Б.259.

* * *

Иске Мәңгәр авылындагы һәм, гомумән, әлеге төбәктәге гарәп язулы 1477 данә кабер ташының текстларын һәм фоторәсемнәрен аерым китапка туплап нәшер иттек[5]. «Безнең мирас» журналын укучыларга Иске Мәңгәр авылының борынгы зиратындагы бер ташъязманың текстын һәм фотосын әлеге китаптан алып тәкъдим итәбез. Ул таш кайчандыр авып, озак еллар туфрак астында күмелеп, бөтенләй билгесез хәлдә яткан. «Таттелеком» хезмәткәрләре, зиратны тәртипкә китергән чакта, аны табып, чистартып һәм бастырып куйганнар.

Сәлам Әлгазый улына куелган таш. 1531 ел

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) ... вә ма...

2) нәфси би-әййи арди тәмәүетү вә калә Сөбханәһә

3) вә Тәгалә көллү нәфсин заикател-мәүт

4) һәза мәкъбәрәи мөнәүвәрә солтанел-гали

5) тарих тукуз йөз утыз сикезд[ә]

6) сәфәр аенда[6] Сәлам Әлгазый угылы даре фәна-

7) -дин даре бәкага рихләт кыйлды

Уң ягында (күпертмә язулы):

1) күрәрмән дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс юк карары

Сул ягында (күпертмә язулы):

1) әрә әд-дөнья хәрабән би-игътибари фә-лә йәбка мәдамән бил-карари

Үлчәмнәре: 134 х 51 х 15 см.

СҮЗЛЕКЧӘ:

әрә әд-дөнья хәрабән би-игътибари фә-лә йәбка мәдамән бил-карари – дөньяны җимерелеп бетә торган итеп күрәм, ул мәңгелек түгел – Аллаһның моңа әмере юк;
вә – һәм;
даре бәкага – мәңгелек дөньяга;
даре фәнадин – фани (вакытлы) дөньядан;
калә Сөбханәһә вә Тәгалә – һичбер кимчелексез бөек Аллаһ әйтте;
көллү нәфсин заикател-мәүт – һәр җан үлем ачысын татыр;
күрәрмән дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс юк карары – дөньяны җимерелеп бетә торган итеп күрәм, ул мәңгелек түгел – Аллаһның моңа әмере юк;
мәкъбәрәи мөнәүвәрә – нурлы кабер;
нәфси би-әййи арди тәмәүетү – нинди җирдә җан бирәчәк;
рихләт кыйлды – күчте;
солтанел-гали – бөек солтан;
һәза – бу. ■

---

[5] Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әтнә төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Казан: Татар. китап нәшр., 2018. – 595 б.

[6] Һиҗри 938 елның сәфәр ае милади 1531 елның сентябрь-октябрь айларына туры килә.

Безнен мирас №12 декабрь 2019

Сүз һәм сурәт

ТАТАРНЫҢ ГАЯРЬ ИРЛӘРЕ

Илгизәр Сәлахов

Дәү әтием Бәдретдин Сәлахетдин улы Сәлахов Татарстанның хәзерге Әлки районына кергән Иске Алпар авылында 1890 елда гаиләдә унынчы бала булып дөньяга килгән. Яшьтән үк хезмәт сөючән, туры сүзле, җор телле була ул. 1909 елда аны гаскәри хезмәткә алалар. 1914 елда Беренче Бөтендөнья сугышы башлану сәбәпле, фронтка җибәрелә. Бәдретдин Сәлахетдин улына Гражданнар сугышында да катнашырга туры килә. Сугыштан исән-сау әйләнеп кайтып, ул Казан мәдрәсәләренең берсенә укырга керә. Аны тәмамлагач, указлы мулла булып, туган авылы Алпарга кайта.

Илдә үзгәрешләр чоры... Муллалыкка укып кайткан Бәдретдин – авылның беренче мөгаллиме балаларга белем бирә. Алпар урта мәктәбе музеенда, башка укытучылар белән беррәттән, аның да фотосурәте тора. 1920 нче елларда князь Оболенскийның спирт заводы урынында, Алпар авылыннан 6 чакрым ераклыкта минем туган авылым – Кызыл Уракчы оеша. Бәдретдин Сәлахов тә, Алпардан гаиләсе белән күчеп килеп, тормыш һәм хезмәт юлын Кызыл Уракчы авылы белән бәйли.

Илебезгә кайгы-югалтулар алып килгән Бөек Ватан сугышы дәү әтием гаиләсен дә читләтеп үтми. Аның олы улы Рияз – хәрби очучы, лейтенант, ике орден иясе – 1944 елның 15 сентябрендә Карпат тауларын азат иткәндә батырларча һәлак була. Газиз баласын югалткан Бәдретдин күңелендәге җан ачысын үзе язган бәет аша җиткерә. Дәү әтиемнең кулы белән язылган бәет – гаиләбезнең иң кадерле ядкаре. Икенче улы Әүхәт тә, Ульяновск шәһәрендә абыйсы Рияз белән очучылар училищесын тәмамлап,

Кызыл Уракчы авылы халкы. 1932 ел

Сулдан уңга: Рияз һәм Әүхәт Сәлаховлар

сугышка китә. Уллары өчен җан атып торган ата, атын җигеп, Кызыл Уракчы авылыннан Ульяновск шәһәренә уллары белән күрешергә бара. Аларның очыш күнегүләре вакытына туры килә ул. Олы улы Рияз, командирыннан рөхсәт алып, әтисен хәрби самолетка утыртып очыш ясый. Дәү әтиемнең улы Рияз белән соңгы күрешүе була бу. Күзләренә яшьләр килеп искә ала иде ул әлеге очрашуны. Горурлана иде дәү әтием уллары белән. Шөкер, Әүхәт абыем сугыштан исән-сау әйләнеп кайтты. Хезмәт юлын хәрби авиация өлкәсендә дәвам итеп, полковник дәрәҗәсендә лаеклы ялга чыкты. 2007 елда вафат булды.

Сәлаховлар нәселенең дәвамчысы булуым белән горурланам. Нәсел шәҗәрәмне төзегәндә, морзалар нәселеннән икәнемне белгәч, менә кайдан килгән икән дәү әтиемә һәм аның улларына укымышлылык, затлылык, дип, кабат уйланып куйдым. ■

Истә, һаман да истә!

Артистка Мәбрурә Рәхмәтуллинаның тууына 100 ел

Татарстанның атказанган артисты (1974) Мәбрурә Барый кызы Рәхмәтуллина 1919 елның 8 декабрендә Саба районының Өчөйле авылында туган.

Башта ул Арча педучилищесын тәмамлый, аннары Арча район колхоз-совхоз театрында, 1939-1941 елларда Казан курчак театрында, 1949 елга кадәр, театр ябылганчы, Мамадыш колхоз-совхоз театрында эшли.

М.Рәхмәтуллина 1949 елда Минзәлә драма театрына килә һәм театрның күренекле артисткаларының берсенә әйләнә. Җырлау сәләтенә ия булу аңа музыкаль сәхнә әсәрләрендә ешрак катнашырга мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта ул характерлы рольләрне дә, әйтик, яшен-картын, малайларны һәм әбиләрне дә зур осталык белән уйный.

М.Рәхмәтуллина башкарган рольләрнең кайберләре: Тәлли («Аршин мал алан», Г.Хаҗибәков), Хупҗамал («Язылмаган законнар», Ю.Әминов), Окси («Кара бүре», Н.Арбан), Майшәкәр («Һиҗрәт», Н.Исәнбәт), Бәдер («Җыр дәвам итә», Х.Сафина).

Мәбрурә Рәхмәтуллина 1976 елның 21 маенда вафат булды.

Педагог Гариф Багдановның тууына 130 ел

Педагог, балалар язучысы, тәрҗемәче, дәреслекләр авторы Гариф Вәгыйз улы Багданов (кайбер чыганакларда Богданов дип язылган) 1889 елның 11 декабрендә Казан губернасына караган Спас өязе (хәзерге Алексеевск районы) Зур Тигәнәле авылында (күренекле язучы Салих Баттал (1905-1995) да шушы авылдан) туган.

1897-1906 елларда Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый, 1910 елда исә Татар укытучылар мәктәбен тәмамлый.

1907 елда ул А.Островскийның «Бедность не порок» («Хуҗа һәм приказчик») һәм 1910 елда Ф.В.Рутковскийның «Ревнивый мужчина» («Көнче ир») пьесаларын тәрҗемә итә. Алар «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәдә куела.

Г.Багданов 1910-1917 елларда – туган авылында, 1917-1926 елларда Казан татар педтехникумында укыта. 1930 елда ул Шәрык пединститутын тәмамлый, 1934-1946 елларда Казан педучилищесында уку-укыту бүлеген җитәкли, М.Х.Корбангалиев, Н.К.Мөхетдинов һәм С.Җәләл белән бергәләп, гомуми белем мәктәпләре өчен табигать белеме һәм математика дәреслекләре яза.

Г.Багданов 1955 елның 10 августында Казанда вафат булды.

Язучы Локман Бадыйкшанның тууына 100 ел

Язучы Локман Әхмәтхан улы Бадыйкшан 1919 елның 12 декабрендә Татарстанның Әлмәт районы Әлмәт авылында крәстиян гаиләсендә туган.

1934 елда Норлат (1997 елдан – Нурлат) районы газетасына әдәби кушымта итеп



чыгарылган «Күтәрелеш» дигән җыентыкта аның «Сөтле комган» исемле беренче хикәясе дөнья күрә.

Авылда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, унбиш яшьлек Локман 1935 елда Казан химия-технология институтының рабфагына укырга керә, 1937-1939 елларда исә Казан укытучылар институтында белем ала. Җиде ел хезмәттә булганнан соң, инде сугышлар тәмамланып, туган якларга кайту турында хыялланып йөргән бер мәлдә, 1947 елның 10 мартында аны, Советка каршы нахак гамәлләрдә гаепләп, кулга алалар һәм ун елга Колымага озаталар. Бары тик алты ел газап чиккәннән соң гына, Сталинның шәхес культы фаш ителеп, Хрущев «җепшеклеге» заманында, ягъни 1953 елда аңа туган ягына кайту насыйп була.

Л.Бадыйкшанның 1959 елда «Атау кызы» исеме белән җиде хикәя һәм җиде әкиятне үз эченә алган бер җыентыгы һәм 1971 елда биш хикәясе тупланган «Атау егете» дип аталган икенче китабы, шулай ук «Казан утлары»ның 1994 елгы 5-6 саннарында «Мөртәт» исемле романы, 2001 елда «Мирас» журналының 7-8 саннарында «Колымадан кайткач» дигән күләмле әсәре басылып чыга.

Л.Бадыйкшан 1998 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы иде. Ул 2015 елның 2 февралендә Казанда вафат булды. Җәсәде Киндерле зиратында җирләнде.

Режиссер Зәкия Туишеваның тууына 100 ел

Режиссер, ТАССРның халык артисты (1969) Зәкия Хафиз кызы Туишева 1919 елның 29 декабрендә Куйбышев өлкәсендәге (хәзерге Самара өлкәсе) Чаллыбаш районының Зәет авылында туган.

Бөек Ватан сугышы башлангач ул, шәфкать туташлары әзерли торган кыска вакытлы курсларны тәмамлап, фронтка китә. Кызыл Йолдыз ордены, II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, «Хәрби хезмәтләре өчен» һәм «Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнә.

Зәкия Туишева 1951-1976 һәм 1990-1994 елларда Әлмәт татар драма театрында режиссёр һәм баш режиссёр вазыйфасын башкара.

Башкарган рольләре: Машенька («Машенька», А.Афиногенов), Анна («Урланган бәхет», И.Франко), Кручинина («Гаепсездән гаеплеләр», А.Островский), Гайнавал («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Әлфинур («Яланаяклы кыз», А.Гыйләҗев), Тулганай («Анам кыры», Ч.Айтматов), Тәңкәбикә («Ай тотылган төндә», М.Кәрим).

З.Туишева куйган спектакльләр: «Тирән тамырлар» (А.Дюссо), «Законлы никах белән» (Ә.Атнабаев), «Чаткылар» (Т.Гыйззәт), «Диләфрүзгә дүрт кияү» (Т.Миңнуллин), «Хаҗи әфәнде өйләнә» (Ш.Камал), «Шаян яшьлек» (И.Абдуллин), «Трибунал» (А.Макаенко), «Сөюең чын булса» (Х.Вахит), «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш), «Әхмәдигә дүрт әби» (Ф. Бүләков), «Банкрот» (Г.Камал), «Татар хатыны ниләр күрми» (Г.Ибраһимов).

З.Туишева 2018 елның 26 декабрендә вафат булды.

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

МОҢЛЫ ЯДКАРЬ

Рәдиф Сәгьди

Халык алдына чыгып, җавап тотар алдыннан китаплар актарырга, роленә охшаш кешеләрне табарга, күзәтергә туры килә. Холыкларын өйрәнү уңыш китерә. Театр ул борынгылыкта калган тарихка да мөрәҗәгать итә. Артист, шул чорлардагы шәхесләрне уйнар өчен, тарихи язмаларны өйрәнергә тиеш. Н.Фәттахның «Итил суы ака торур» әсәрендәге Алмыш ханны уйнар өчен «Сызгыра торган уклар» романын кабат-кабат укып чыгарга туры килде. Нәтиҗәдә, тамашачыны ышандырырлык Алмыш хан образы дөньяга туды.

Тимер Зиннуров,
Татарстанның халык артисты

Аны яздырып алырга Татарстан радиосында эшләүче Нәсим Акмалга шалтыраттым! «Бер кеше дә мәңгелек түгел, искиткеч гармунчы, яхшы артист, киләчәк буын өчен яздыртып калыйк әле!» – дип аңлаткач: «Әлбәттә, эшлибез, Рәдиф туган, үзем дә Тимер абыйны эфирга кайчан чыгарып булыр икән, дип уйланып йөри идем», – диде. Яхшы язма килеп чыкты. Икәүләп гармуннарда уйнап, халык җырларын да башкарып, истәлекләр белән баеткач, затлы тапшыру туды. Нәсим дә, без дә бик канәгать калдык Тимер агага багышланган тапшырудан. Әлбәттә, радиотыңлаучыларыбыз кәефләнү дә, сагышлану да кичергәндер, чөнки әлеге истәлектә аның яратып уйнаган, аның өчен махсус атап язылган спектакльләрдән өзекләр яңгыратылды. Төрле уен коралларында да уйный белүен искә алып, «Сынган беләзек»тә төп рольләрнең берсе Зиннур өчен язылган иде, икенче «Яз галәмәте» пьесасында К.Тинчурин театрының баш режиссеры Рәшит Заһидуллин: «Менә, шулшул артистларга атап рольләр яз әле!» – дип тәкъдим ясагач, әлбәттә, Тимер аганы күз алдында тотып, тулай торакта эчү мәҗлесләре оештырырга гына маһир түгел, ә

гармунда да оста итеп уйнаучы, зимагуррак, гаиләле, ике баласы янына хәтта сиксән яшьлек дәү әнисен дә тулай тораклагы кысынкыга сыйдырган Рөстәм роле туды. Ике пьесамда да үзенең каһарманнарын бик яратты ул. «Сынган беләзек» мелодрамасындагы персонажның исеме башта Васил иде. «Рәдиф, Василны Зиннурга үзгәртсәм ярыймы?» – ди бу. Аптырап калдым: «Нишләп?» – дим. «Чөнки Василның язмышы минем әтинеке белән тәңгәл килә», – дигәч: «Ярый, тик режиссер Исламия Мәхмүтова белән киңәш?» – дим. «Нәрсә әйтсен инде ул, ярый, үзем аңа җиткерермен!» – дип, китеп барды. Нәтиҗәдә, ул елларда театр залларын тоткан, елаткан да, көлдергән дә искиткеч музыкаль спектакль туды. Әсәрне куярга алынган Исламия ханымның артистларны дөрес итеп сайлый белүе, вакыйганы үзенең йөрәге аша үткәреп эшләве соңыннан йөзләгән халык театрларын да шушы әсәрне сәхнәләштерегә мәҗбүр иткән көчле энергетикалы әсәр туугa сәбәпче булды. Әлбәттә, Зиннур – Тимер ага бу иҗатның зур бизәге, безнең бердәм иҗатыбызның йолдызы иде. Аның «Арча», «Сарман», «Урам» көйләрен өздереп уйнавы беркемне дә битараф калдырмады. Бу ролен үзе бик яратты шул, халкыбызга шуның аша тагын да ныграк якынайды. Тамашачыларыбызның сөекле артистына әйләнә генә барды Тимер Зиннуров еллар узган саен. Чөнки, әйтеп үткәнемчә, профессиональ артист кына түгел, бик оста баянчы да иде ул...

Лаеш районының Пәрәү авылында 1949 елның 18 ноябрендә дөньяга килгән Тимергали бала чагыннан ук гармунчы булырга омтыла. Тимергалинең әтисе Зиннур абзый үз колхозларының танылган умартачысы була. Дусты, гармунчы Галимҗан да, уен коралын бик еш култык астына кыстырып, күмәк оешманың умарталыгына йә булышырга, йә, колхозга берәр кунак килсә, гармун уйнап күңелләрен күтәрергә дә йөри. Тимер дә, көн саен диярлек, алар арасында чуала. Абзыйның гармунда сыздырып җибәрүенә соклана, үзе дә уйнап карарга кызыга. «Йә ватарсың, бир әле кеше гармунын!», – дип, әтисе гармунны ераграк алып куйгалый. Ләкин аларның – ике фронтовикның урман аланындагы корт оялары янына чыгып китүләре була, үсмер Тимер, гармунны алып, шыңгырдата ук башлый. Хуҗасы аның тавышын ишетеп кире кайта да: «Йә ватарсың, Тимер улым», – дип, гармунны алып җыештырып куя. Шул чакта үпкәләп елый бәләкәй малай. Хуҗасына ни дәрәҗәдә кадерле корал икәнен аңлап бетерә алмый шул сабый күңеле. Соңрак, үзе дә танылган артистка әйләнгәч кенә, әлеге уен коралының Галимҗан агасына ни дәрәҗәдә кадерле булганына төшенә...

Сугыштан соңгы елларның шыксыз-хәерсез көннәренең берсендә аларга кунакка кардәш тиешле бер апалары кайтып төшә. Авыл кибетенә кирәкле нәрсә китергәнлек билгеле булгач, барысы да шул тарафка чаба. Кунак та: «Бар әле, бар, беткәнче син дә алып кайт, Тимер энем!» – дип, малайның кулына өч сум акча тоттырып, кибеткә йөгертә. Алдан ук авылдашы Зиннәтулла абзасының гармунын сатарга җыенганлыгын ишеткән, шул уен коралын кулына төшерергә хыялланган малай, башкалар алып өлгергәнче, дип, шул очка юнәлә. «Калган ике сумын соңыннан бирәбез, Зиннәтулла абзый!» – дип, әлеге уен коралын күтәреп тә кайта. Әнә шуннан соң шыгырдата башлый да инде ул. Өйдән кусалар – чоланга, аннан, «тавышы башка капты», дип сөрсәләр, ындыр артына, йә булмаса, мунчага шыла ул. Озакламый, барысын да шаккаттырып, татар халык көйләрен сыздыра башлый! Тимер, гармунда ныклабрак өйрәнәм, дип, дәресләргә дә йөрми башлый. Сумкасын яшереп куя да, тау башына менеп осталыгын чарлый. Көннәрдән бер көнне укытучылар килеп кереп, баланың мәктәпкә йөрмәвен әйтеп, өйдәгеләрне аптырашта калдыралар. Әмма Зиннур ага улының гармунда уйнарга үҗәтләнеп өйрәнүенә сөенә генә. «Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс! Укуыңа да йөрергә, гармуныңны да уйнарга кирәк, улым!» – дип, сугышның төрле вәхшәтләрен кичереп, тән җәрәхәтләре алып кайткан ата кеше, баласының тырышлыгын күреп,

«Баламның баласы – балдан татлы» (М.Гыйләҗев). Рольләрдә: Роза Хәбибрахманова һәм Тимер Зиннуров

ничекләр генә яхшы гармун алып бирергә икән, дип уйлана башлый. Гармунда уйнаганын ишеткән авылдашлары бишенче сыйныфта укыган яшүсмерне төрле мәҗлесләргә чакыра башлыйлар. Мәктәп бәйрәмнәрендә дә катнаша, клубта да үз кешегә әйләнә Тимер. Ата кеше дә, улының иске гармун белән чиләнгәненә борчылып йөри торгач, бозауларын сатып, аңа Казаннан 25 сумга баян алып кайта. Үзе дә тик ятмый үсмер. Хәзер өлкәннәргә бераз гына булса да ярдәмем тияр, дип, җәйләрен комбайн ярдәмчесе дә, сабанчы-пресслаучы булып та хезмәт куя. Әҗере итеп әзме-күпме акчасын да, икмәген дә бирәләр. Кыш көннәрендә дә – дәресләрдән соң, кая чакырсалар шунда иптәш малайлары белән колхоз эшенә йөри. Сигезенчене бетерүгә, документларын кулга алгач, Әтнәдә яңарак кына ачылган авыл хуҗалыгы техникумына китеп бара. Әмма имтиханнар биреп йөргәндә: «Тукта, зоотехник дипломы белән мине кире авылга кайтарачаклар ич!» – дип, артист булырга хыялланган үсмер кире туган нигезенә әйләнеп кайта. Көзгә кадәр тракторда эшли дә Казанда халык иҗаты йортында ачылган баянчылар курсына барып керә. Белем алу түләүле булу сәбәпле, җае чыккан саен яшелчә базарына барып, бушату-төяү эшләрендә хезмәт куя башлый. Шундый көннәрнең берсендә Курчак театры бинасы янынан үтеп барганда «Өйрәнчек артистлар кабул итәбез» дигән игъланга күзе төшә. Кызыксынып керүе театрга эшкә урнашу белән тәмамлана. Шунда сәхнә эшчесе, ут бирүче булып сәхнә серләренә төшенеп гастрольдә йөргәндә, Азат Хөснетдинов дигән артистлары кинәт кенә авырып китә. Аның кечкенә генә ролен өйрәнчек Тимер Зиннур улына тапшыралар. Шуннан инде, осталыгын күреп алып, зуррак күләмдәге рольләрне дә ышанып тапшыра башлыйлар. Авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә спектакльләр куеп йөргәндә администратор да, режиссер ярдәмчесе дә, артист та, кирәк чакта хәтта шофер да була. Ләкин өч бала белән өйдә калучы хатыны Гөлфиягә дә бик кыен. Шуңа, гел юлдан кайтып кермәгән эшен калдырып, яраткан хатыны белән балалары янында көн саен булырга, дип, театрдан китә. Инде икенче эшкә урнашам, дип кенә йөргәндә, аңа элек Курчак театрында бергә эшләгән танышы Ринат Ногманов очрый. Тимерне, көчләп диярлек, Күчмә театрның ул чагындагы баш режиссеры Равил Тумашев янына мәҗбүриләп алып керә. Шундук

«Сынган беләзек» спектакленең премьерасыннан соң. Рәсемдә (сулдан уңга): Тимер Зиннуров, Лилия Мәхмүтова, Рәдиф Сәгъди, Исламия Мәхмүтова, Харис Төхвәтуллов

аны, А.Гыйләҗевнең «Ефәк баулы былбыл кош» спектакленә, сессиягә киткән артист урынына баш рольдә уйнаучы итеп билгелиләр. Сиксән битле пьесаның кырык биш бите аныкы, өйрәнеп кенә бетер. Курчак театрына килгән беренче мәлләрендә артист зур кыенлыкларга дучар була. Сүзен сөйләсә, атларга оныта, атласа, сүзләре хәтердән җуела. Ни әйтсәң дә, биредә бөтенләй башка өлкә шул. Тора-бара барысы да җайлана, ул драма актерлыгының кануннарына төшенә башлый. Яшьлек мәхәббәте, авылдашы, түземле, тыйнак Гөлфия апа да аңа ныклы терәк була. Тормышның бөтен авырлыкларын бергәләп күтәрәләр.

Мин актер булып эшкә килгәндә, Тимер абый җиң сызганып иҗат итә иде инде. Аның белән Туфан ага Миңнуллинның «Без бит авыл малае» спектаклендәге яшь авыл егете Иршатны башкаруы аша таныштым. Бу образны тудыру аңа җиңел бирелмәгән. Исламия һәм Хәлил Мәхмүтовлар шулвакытта Тимер Зиннуровка даими ярдәм кулын суза. Наил ага Шәйхетдинов та киңәш-тәкъдимнәрен биреп тора. Мин караганда инде ул спектакль гөрләп бара иде. Шул көннәрнең берсендә ул мине читкә чакыртып алды да: «Кара әле, энекәш, бу Илшат роленә минем урынга кер әле, гармунда да әйбәт уйныйсың!» – дип үгетли башлады. Аптырап калдым. «Нишләп?» – дим. «Соң, иллегә җитеп киләм, һаман шул яшь авыл җегетен башкарам!» Ләкин мин баш тарттым, чөнки үзебезнең группа бар, анда минем курсташларым уйный, Илгизәр Хәсәнов, Ринат Мифтахов кебек кирәк чакта терәк булучы якташларым бар! Үпкәләде ул, әлеге үтенечен кире каккач. Бәлкем, аңа, көне-төне гастрольдә йөргән спектакльдән аерылып торып, гаиләсе белән күбрәк өйдә булу өчен кирәк булгандыр бу гамәле. Шулай! Оланнарының күчеш чоры, мәшәкатьләре дә килеп чыккалагандыр. Безнең аралар яңадан җылыну сәхнәгә «Сынган беләзек» мелодрамасы менгәч башланды. Ул бу әсәрдә яратып уйнавын: «Пьеса әйтерсең лә минем әтием хакында. Ул 82 яшендә вафат булды. Ләкин бу пьесада мин Зиннур ролен аңа багышлап, аны күзаллап уйныйм. Мине дөньяга бар иткән, үстергән, тәрбияләгән әтием образын уйнау ансат та, җаваплы да... Театрның бу спектакле тамашачының иң яратканнарының берсенә әйләнде», – дип аңлатты.

Мөнәсәбәтләребез, тора-бара, иҗади иптәшлектән чын дуслыкка әйләнде.

«Яз галәмәте» (Р.Сәгъди). Рольләрдә (сулдан уңга): Тимер Зиннуров, Зөфәр Харисов, Илгизәр Хәсәнов һәм Нуретдин Нәҗмиев

Үземнең «Яз галәмәте» комедиясендә аңа багышлап махсус роль язылгач, бигрәк тә. Драматургның кемгәдер атап-багышлап персонаж иҗат итүе бар артистка да тәтеми. Ә монда инде (беренчесендә – «Сынган беләзек»тә Зиннур роле) аңа, аның холкына, осталыгына туры килгән рольләр тудырылды. Оста баянчы, гармунчы, тальянчы Тимер аганың Рөстәм ролен башкарганда кулыннан гармуны төшми диярлек. Уйный, җырлый, сөйли. Бу образ аның үзенеке. Өстәвенә, зимагурлыгы да ташып тора.

Андый киң кырлы артистлар (Илгизәр Хәсәнов, Нуретдин Нәҗмиев, Роза Хәбибрахманова, Нурия Вәлиева, Зөфәр Харисов, Тәслимә Фәйзуллина, Ләлә Миңнуллина һәм башкалар) уйнаган әсәрне карау тамашачыга да күңелле. Халык яратып кабул итте безнең спектакльне. Артистларның, язучының, режиссерның уртак уңышы иде ул. Тимер Зиннур улы үзенең талантын ошбу спектакльдә бөтен тулылыгы белән чагылдыра алды. Утыздан артык образ тудырды ул бу чорда. Алар арасында И.Юзеевның «Кыр казлары артыннан»да – Әкбәр, Т.Миңнуллинның «Гармун уйный беләсеңме?» комедиясендә – Мәрди, Ш.Хөсәеновның «Әни килде» драмасында – Мәгъсүд, Р.Суфиев «Сакаллы сабыйлар»ында һәм башка авторларның пьесалары буенча куелган спектакльләрдә зур осталык белән башкарган рольләре тамашачы күңеленә якты хатирәләр булып кереп калды. Бәйрәм концертларыбыз аннан башка үтми торган иде. Алар Искәндәр Биктаһиров белән дә бергәләп иҗат иттеләр. «Халык җырларын бигрәк өздереп җырлый, уйнарга рәхәт аңа», – дия иде ул. Кыска гастрольләргә дә вакыты булса, гел бергә чыгып киткәләделәр. Шундый көннәрнең берсендә, юлдан кайткач, миңа шылтырата: «Үзем кереп тормыйм, урамга чыгып кер әле», – ди. Анда, ике рәтле хромка тотып, Тимер ага үзе басып тора. «Мә, истәлегем булыр, энекәш, син бу гармунда бик яхшы уйныйсың», – дип, кулыма тоттырды да, борылып, машинасына таба китеп барды. Хәзер аның төсе итеп саклыйм бу кадерле ядкарьне.

«Кеше китә, җыры кала!» – диләр. Хак сүзләр. Ишетәсезме, әнә, радиодан тальян моңы яңгырый, Тимер Зиннур улы уйный! Үткән заманнарда сәхнә тотканлыгын һәм халкыбызның яраткан артисты булганлыгын дәлилләп чыңлый ул тальян моңы!.. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2019

МӘКТӘПЛӘР ҺӘМ САБАКТАШЛАР

Ләбиб Лерон

Киров авылының унъеллык мәктәбе. 1978 ел. Ләбиб Лерон фотосы

С.М.Кировның (1886-1934) балачак фотосы

КИРОВ АВЫЛЫ. ӘЗ-МӘЗ ТАРИХ

Кайбер мәгълүматларга караганда, 1931 елның ноябрендә, Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы карары белән, Яңа Әлем авылы янында «201 нче Актаныш итчелек-сөтчелек совхозы» оештырыла. Күпмедер вакыттан соң, ул Иске Сәфәр авылына күчерелә һәм «Сәфәр совхозы» дип йөртелә башлый. Бераздан совхоз хәзерге урынына (ягъни соңыннан Киров авылы буласы җиргә) күчерелә. 1931 елда аның карамагында бер йөк машинасы, алты «Фордзон» тракторы була. Эшкә тирә-як авыллардан гына түгел, хәтта илнең төрле төбәкләреннән дә күчеп киләләр. Эшчеләр өчен тулай тораклар төзелә.

1934 елда күренекле революционер һәм дәүләт эшлеклесе С.М.Киров (чын фамилиясе – Костриков, 1886-1934) атып үтерелә. Берникадәр вакыттан соң, аның исемен мәңгеләштерү башлана. СССРның төрле төбәкләрендә Киров исемен йөрткән торак пунктлар, шәһәрләр, урамнар барлыкка килә. Бу эштә Татарстан да актив катнаша. Ни өчен дигәндә, С.М.Кировның яшүсмер чоры Казан белән бәйле икән – ул 1901-1904 елларда шәһәрнең механик-техник сәнәгать училищесында укыган булган. Шулай итеп, 1935 елның 1 февраленнән әлеге хуҗалык С.М.Киров исемен йөртә башлый. Ул вакытта совхоз Калинин районына

Ахыры. Башы журналның 8 нче (2019) санында.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе, драматург Данил Салихов

Җырчы Дәниф Шәрәфетдинов

«Ак калфак» татар хатын-кызлар иҗтимагый оешмасының рәисе Кадрия Идрисова

Шагыйрь Рифкать Закиров (1938-2007)

карый, ә инде 1959 елның 10 февралендә, Калинин районы бетерелгәч, совхоз Актаныш биләмәсенә кертелә. Мин унынчы сыйныфны тәмамлаган 1979 елда Киров авылында 1302 кеше яшәгән икән. Татарстан Язучылар берлеге рәисе, драматург Данил Салихов, заманында Хәния Фәрхи төркемендә җырлаган Дәниф Шәрәфетдинов – шушы авыл тумалары. «Ак калфак» татар хатын-кызлар иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисова (Чынык авылында туган), шагыйрә Чулпан Әхмәтова (әдәби кушаматы – Таңчулпан, Олыймән авылыннан) – Киров урта мәктәбен тәмамлаучылар. Актаныш районының Усы авылында дөньяга килгән шагыйрь Рифкать Закировның (1938-2007) җәсәде шушы авыл зиратында җирләнгән.

МӘКТӘП

Олы Имән белән Киров авылы арасы сигез чакрым чамасы. Мин тугызынчы-унынчы сыйныфларымны шушы Киров авылы мәктәбенә йөреп укыдым. Бәхетемә, әни 1979 елның сентябрендә «Восход-2М» дигән мотоцикл сатып алып бирде. Мин ике авыл арасын бер итеп, еш кына сыйныфташларны да утыртып, шул мотоциклга атланып «чаптым». Ул елларда яшьтәшләремнең байтагы, мин

əйтеп үткəн «матай»дан тыш, «Электрон» мотороллеры һəм «Минск» мотоциклларын иярлəде. «Тула», өч тəгəрмəчле «Муравей» мотороллерлары, «Иж-Планета», «Иж-Юпитер», «Урал» бишекле мотоцикллары, хəтта «хан заманы истəлеге» булган «Ковровец» белəн җилдерүчелəр дə булмады түгел.

Шулай итеп, Киров авылының агач мəктəбендə укый башладым. Төрле авыллардан җыелган укучыларны, ягъни безне өч класска бүлделəр. Мин «Б»га элəктем. Бергə укыган сыйныфташларымны искə төшерəм: Олы Имəннəн – Рəфинə Əхмəтова, Айзирəк Хəтимова, Дəбир Нəгыймов, Данир Сафин, Лемон Леронов (мин бахырыгыз), Усы авылыннан – Фəрит Минһаҗев, Инсөя Кашапова, Əхтəм Шəехҗанов, Алма-Ата авылыннан (бу авыл юк инде) – Роза Шəехова, Киров авылыннан – Илсинə Миңнекəева, Сəрия Габдрахманова, Раушания Шəехҗанова, Зөһрə Кəрəмуллина, Роза Морзаханова, Нияз Бикмөхəммəтов, Камил Шəйхелмəрдəнов, Нəзирə Җиһангирова, Салават Шəйхелмəрдəнов, Нияз Идрисов («Ак калфак» татар хатын-кызлар иҗтимагый оешмасы рəисе Кадрия Идрисованың бертуган энесе), Нəзлия Мөхəммəдиева; «А» классында укучылар: Олы Имəннəн – Азат Вəлиев, Дəнирə Нигъмəтуллина, Рəдиф Наҗаров, Рисхəт Фатыйхов, Мəрвə Əһлиева, Усы белəн Киров авылыннан – Гөлсинə Солтанова, Илнур Казыйханов, Рəсим Шəвəлиев, Марсила Салихова, Глүзə Гарипова, Фанзур Гыйльфанов, Тəвис Заманов, Инсаф Бəхтигəрəев, Алмаз Гайнетдинов, Дилə Заһитова, Валерий Илекбаев, Əнвəр Рəшитов, Рəмзия Мо-

Сыйныфташым Илсинə Миңнекəева. 1978 ел



Сыйныфташым, Усы егете Фəрит Минһаҗевның гармунда уйнаган чагы. 1978-1979 нчы еллар

Сабакташлар очрашуы (сулдан уңга): Рəдиф Наҗаров, Дəбир Нəгыймов, Индус Хəертдинов. 2014 ел



Киров авылы унъеллык мәктәбенең бер өлеше. 1978 ел.
Ләбиб Лерон фотосы



Сыйныфташым
Салават Шәймәрдәнов

тавалова, Айрат Сабитов; «В» классында белем алучылар: Олы Имән авылыннан – Римма Шакирова, Илдар Саматов, Мөнир Әһлиев (Мәрвәнең игезәге), Рәмилә Заһидуллина, Мөнирә Ганиева, Илһар Вәлиев, Индус Хәертдинов, Фирдания Гарипова, Илгизәр Нәгыймов, Садыйк Ибраһимов, Гөлшат Фәхрисламова, Наилә Рәшитова, Әлфинур Сабирова, Фәрит Хафизов, Рөстәм Рәшитов, Дәниф Хөрмәтуллин, Әхияр Камалов, Кадрия Миргалимова, Закирҗан Камалов. 1979 елда Киров мәктәбен тәмамлаган сабакташларымның кайберләре якты дөньяда юк инде: Мәрвә Әһлиева, Рәмзия Мотавалова, Айрат Сабитов, Фәрит Минһаҗев, Салават Шәйхелмәрданов, Нәзирә Җиһангирова, Илһар Вәлиев, Индус Хәйретдинов, Фирдания Гарипова, Илгизәр Нәгыймов, Садыйк Ибраһимов. Бу сабакташларымның урыннары оҗмахта булсын!

Инде укытучыларымны барлар вакыт: Әбүсәгыть Гафуров (татар әдәбиятыннан укытты, аның: «Татар шагыйре һәм әдәбият галиме Зәет Мәҗитов белән бергә укыдык», – дип сөйләгәне хәтердә калган), Мәдәния Хәмидуллина (татар әдәбияты), Рузалия Галләмова (алгебра, геометрия), Разия Касыймова (биология), Мирга-

Укытучым Әбүсәгыть абый Гафуров. 1979 ел

Ульяновскида экскурсиядә. 1978 ел

Сабакташларым Әхияр Камалов, Марсила Салихова һәм Раушания Шәехҗанова. 26 июль, 2014 ел

яз Разов (тарих, георгафия), Венера Сәхәбетдинова (рус теле һәм әдәбияты), Раил Ибраһимов (режиссер Фаил Ибраһимовның һәм шагыйрь Мөхәммәт Мирзаның бертуган абыйлары, сызым һәм трактор дәресеннән укытты), Шамил Латыйпов (физкультура), Мосаяра Фазуллина («Ялкын» һәм «Сабантуй» журналларының баш мөхәррире Илназ Фазуллинның әтисе Фаис абыйның бертуган апасы, химиядән укытты), Фидания Гарифуллина (рус теле һәм әдәбияты), Рәмилә Әбуярова (тарих, җәмгыять белеме), Флорид Исламов (башлангыч хәрби әзерлек), Ринат Мәҗитов (физика, астрономия), Хәнәфи Гәрәев (башлангыч хәрби әзерлек). Без укыган чакта Ринат абый Мәҗитов («А»), Рузалия апа Галләмова («Б»), Шамил абый Латыйпов («В», тугы-

Сыйныфташым Айзирәк Хәтимова. 26 июль, 2014 ел

Илнур Казыйханов, Рисхәт Фатыйхов. 26 июль, 2014 ел

Укытучым, сыйныфыбызның җитәкчесе Рузалия апа Галләмова. 1979 ел



Физкультура укытучысы Шамил абый Латыйпов. 1979 ел

Рус теле һәм әдәбияты укытучысы Фидания Гарифуллина. 1979 ел

Укытучым Мәдәния апа Хәмидуллина. 1979 ел

зынчы сыйныфта) һәм Фидания апа Гарифуллина («В», унынчы сыйныфта) класс җитәкчеләребез булды. Мөхтәрәм мөгаллимнәребезнең барысын да якты хисләр белән искә алам. Зур рәхмәт аларга!

Без укыганда спортка игътибар бик зур иде. Мин аеруча чаңгы шуарга һәм биеклеккә сикерергә ярата идем. Спортның шушы төрләре буенча мәктәп чемпионы булуымда физкультура укытучысы Шамил абый Латыйповның роле аеруча зур.

Хатирәләр күп. Мәктәп уздырган Яңа ел бәйрәмендә Кыш бабай булуым; кышын интернатта яшәгән вакытта кичләрен матайларыбызны йокы бүлмәсенә алып кереп ремонтлауларыбыз; төрле спорт ярышларында һәм туристлык слетларында катнашуларыбыз; тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, Ульяновск каласына баруларыбыз; апрель уртасында, үзара бәхәсләшеп, кар

Химия укытучысы Мосаяра апа Фазуллина. 1979 ел

Сабакташларым Камил Шәймәрдәнов, Әлфинур Сабирова. 26 июль, 2014 ел

Сабакташларым Кадрия Миргалимова һәм Наилә Рәшитова белән. 1978 ел

Сабакташым Наилә Рәшитова. 26 июль, 2014 ел

суында коенуларыбыз; яп-яшь һәм чибәр укытучыларыбызга гашыйк булып йөрүләребез; трактор йөртергә өйрәнүләребез; дивар газеталарын чыгаруларыбыз; озын чәч үстереп йөрүебез яисә берничә егет, бергәләп, җәяүләп, Пучы авылына барып, балагының киңлеге 27 сантиметр булган чалбарларга (мода!) заказ биреп кайтуыбыз; тәнәфес вакытында гына шигырьләр ятлап, аны «бишле»гә сөйләүләребез; кызлар өчен «маңгайга-маңгай килү»ләребез; үскәч, «әллә кемнәр» булабыз, дип хыяллануларыбыз... турында язсам...

Кыскасы, барысын да сөйләп яисә язып бетерү мөмкин эш түгел. Әлегә сөекле укытучыларымны һәм кадерле сабакташларымны искә төшереп, барчасын күңелемнән барлап чыгарга тырыштым. Киләчәктә, җай табып, истәлек-хатирәләрне тагы да киңәйтебрәк кәгазьгә төшерермен әле, Алла бирса!

16 ноябрь, 2019 ел ■

Сабакташларым Кадрия Миргалимова һәм Дәниф Хөрмәтуллин. 26 июль, 2014 ел

Сабакташларым Дәнирә Нигъмәтуллина һәм Рәфинә Әхмәтова

Сыйныфташым Мөнирә Ганиева

Безнең мирас №12 декабрь 2019

БОРЫНГЫ ТАТАР МИЛЛИ МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

Ринат Гыйләҗев,
«Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе

КУБЫЗ

Дөньядагы иң борынгы музыка уен коралларының берсе – кубыздыр, мөгаен. Кешенең агач чырасына иң беренче тапкыр кайчан игътибар иткәнен кем белә? Тәгаен, шул вакытта ук әлеге чырага берәм-берәм чиертеп тә, ирененә тидереп, көй уйнап та карагандыр.

Тыва халкы мондый чырадан ясалган кубызларда хәзер дә уйный. Ул тывача *ыяш-хомус* дип атала.

Галимнәр раславынча, кубыз моннан биш мең еллар элек үк Көньяк-Көнчыгыш Азиядә билгеле булып, соңрак бөтен дөньяга таралган. Ул Европага бөек күчеш чорында килеп кергән булырга мөмкин. Шунысы да игътибарга лаек: кубыз бары тик Чыңгыз хан узган җирләрдә генә «төпләнеп» калган.

Аңарчы һун гаскәре дә айлар, еллар буе ат өстендә барган, ат өстендә яшәгән, билгеле. Атлы сугышчының иярендә һәрвакыт кубыз йөргән. Уйнап, *үзләп бару* – сугышчы,

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

юлаучы өчен гадәти хәл булган. Аннан соң, кубызның эшләнелеше дә дагага охшаган лабаса! Ә дага ул – юл уңуга ышаныч та.

Кубызга охшаган уен коралларының дөньяда меңгә якын исеме бар. Һәр халык аны үзенчә атый. Азиядә яшәүче төрки халыкларда бу уен коралы үзара охшаш исемнәрдә йөри: *кубыз, хомус, кумыз, къобуз, купас, комус, кобыз* һ.б.

Кубыз – сихри көчкә ия уен коралы. Аның килеп чыгышы да турыдан-туры дини тәгълиматка бәйле. *Камнар* (шаманнар-имчеләр) камлаган вакытта ярдәмгә төрле уен коралын алганнар. *Комус* (камус) төшенчәсе дә *камлау* сүзеннән барлыкка килгән булырга мөмкин. Алтай белгечләре сөйләгәнчә, яхшы имче кубыз белән камлау вакытында өченче кат күккә кадәр күтәрелә ала икән. Бу сүзләрдә, ихтимал, хаклык бардыр да. Әйтик, бүген дә Европаның зур шәһәрләрендә кубыз ярдәмендә музыкатерапия сеанслары үткәрелә. Бу эшне, имчеләрдән гайре, үз эшләрен яхшы белгән профессиональ табиблар да башкара.

Һәр халык әлеге уен коралын үзенеке дип саный һәм ничек тә аны үзенә якынайтырга тырыша. Мәсәлән, Вена шәһәрендә (Австрия) кубызчыларның Халыкара конгрессы урнашкан. Һәр ике ел саен дөньяның зур-зур калаларында кубызга багышланган Халыкара симпозиум-конкурслар үткәрелә. Олан-Батыр (Улан-Батор) шәһәрендә (Монголия) үткән шундый Халыкара конкурсның берсендә катнашып, виртуоз кубызчы Роберт Заһретдинов (Уфа) Гран-при иясе булган иде. 2012 елда Мәскәүдә үткән шундый ук бәйгедә Татарстаннан «Сорнай» фольклор ансамбле дә катнашты.

АГАЧ КУБЫЗ

Казан татарларында агач кубыз турында истәлекләр бик аз сакланган. Булганнары да борынгырак чорларга карый. Ә инде соңгы елларда агач кубыз кулланудан бөтенләй диярлек төшеп калды. Шулай да, татар халык авыз иҗатында аның турында истәлекләр бар:

Дыр-дыр-дыр икән,
Ник дырылдый бу имән?
Әллә бизгәк тотканмы,
Әллә давыл купканмы?
Оста кулында имән
Бөгелә дә сыгыла.

Күңел биреп тотынсаң,
Имәннән дә моң чыга.
Дыр-дыр-дыр имән,
Дырылдамый бу имән.
Бу имән шулай җырлый,
Хатирәләрне сырлый.

Шушы табышмак-шигырьдән генә дә агач кубызның казан татарларына билгеле булуы, уйнаганда *дыр-дыр-дыр* дигән тавыш чыгаруы һәм имән агачыннан ясалуы турында белергә мөмкин.

1984 елны мин Азнакай районында агач кубыз тавышына охшатып такмак әйтеп биегән апаларның тавышын яздырып алган идем. Алар *бези-бези-безибәт,* дип, бию көйләренә импровизация ясап биеде. Кечерәк итеп эшләнгән агач кубыз, дөрестән дә, шундый аваз чыгара.

Дунай буенда яшәүче украин, мажар (венгр), гуцул, гагауз халыклары аны *дрымба, доромба, друмла* диләр. Бу исемнәр дә агач кубыздан калган булса кирәк.

Агач кубызның төзелеше бик гади. Аны безнең якларда кипкән имән, өрәңге, чыршы кебек каты агачлардан ясаганнар.

Ясау өчен иң элек калынлыгы – 2-4 мм, озынлыгы – 200-250 мм, киңлеге 15-16 мм булган һәм юкартып эшкәртелгән агач пластинка алабыз. Аның өске ягына кубызның сызымын сызабыз һәм шул сызым буенча лобзик яисә үткен пычак белән кисеп, кәүсәсен ясыйбыз (кәүсә-форманы һәр оста үзе теләгәнчә бизәкләп ясый ала). Аннан



Агач кубыз

соң бик юка пәке белән тавыш чыгару өчен *тел* ясала. Музыкаль тавыш югарылыгы шушы телнең озынлыгына һәм калынлыгына бәйле. Тел озынрак һәм юкарак булган саен, тавыш – түбәнрәк, тел кыскарак һәм калынрак булган саен – югарырак яңгырый.

Уйнаганда кубызның бер башыннан сул кул белән учлап тотабыз һәм кубызның тел турысын авызга якын китерәбез. Кубызның өске читен – өске тешләргә, ә аскы читен – аскы тешләргә терибез. Кубызның икенче башына акрын гына уң кулның имән бармагы белән сугып, тавыш чыгарабыз. Авыз куышлыгы акустика ролен үти һәм музыкаль авазның тембрын билгели. Шулай ук аның сугып уйный торган башына җеп бәйләп, шул җепне кисәк кенә тартып-җибәреп уйнарга да мөмкин. Авыз аша эчкә-тышка тын өргәч, аның тавышы тагын да көчәя, матурая.

ТИМЕР КУБЫЗ

Кубыз – татар милләте өчен бик кадерле уен коралы. Халык аны иң авыр елларда да кулдан төшермәгән, качып булса да уйнаган. Буыннар арасында өзелмичә сакланып килгән ике уен коралының берсе ул – кубыз!

Гадәттә, аны көмешчеләр, җизчеләр, тимерчеләр ясаган. Бүгенгәчә сакланып калган кубызларның кәүсәсе күп очракта 2-5 мм калынлыктагы тимер яисә җиз чыбыклардан дага формасында бөгелеп ясалган. Тел өлешен җиз чыбыкны төеп, юкартып ясаганнар. (Төйгән саен, металл катылана, чыныга, сыгылмалыга әйләнә һәм аның тавышы да көчлерәк яңгырый.) Ул кәүсәгә кургаш кисәген эретеп яисә чүкеч белән чүкеп беркетелгән. Телнең бармак белән чиертеп уйный торган башы 20-22 мм озынлыкта бөгелгән.

1970-2000 елларда аерым башкаручылар да, төрле ансамбльләр дә уен кораллары остасы Ифрат ага Хисамов ясаган кубызларда уйнады. Шулай ук, Ифрат ага, авылларга, районнарга йөреп, меңләгән үзешчән артистларны, бигрәк тә балаларны кубызда уйнау серләренә өйрәтте. Өйрәнергә җиңел булсын өчен, ул кубызны һаман камилләштереп ясарга тырышты, һәрдаим эзләнде. Мәсәлән, кубызның чиртеп уйный торган башына зур булмаган металл кисәге беркетте. Бу ни өчен кирәк? Уйнаганда без кубызны тешләргә терибез. Озак репетиция ясаганда балаларның башы авыртырга мөмкин. Ифрат ага керткән үзгәреш кубызны тешкә терәргә мәҗбүр итми. *Масса* ролен шушы металл кисәге үти.

Гомумән, соңгы елларда төрки дөньяда уен коралларын ясау технологиясе шактый алга китте. Бик яхшы материаллар, махсус җайланмалар, станоклар сатып алырга була. Һәр уңышың белән уртаклашырга да бөтен мөмкинлекләр бар.

Бүгенге көндә Казанда татар кубызларын Таһир Вәлиуллин ясый.

Хәзер *ре* тавышына көйләнгән кубызның үлчәмнәрен биреп китик.

Ул 3-4 мм калынлыктагы металл пластинкадан ясала. Озынлыгы – 110 мм. Авызга кабып, тешләргә тери торган 50 мм озынлыктагы араны (анда металл тел йөри), эчке ягыннан (астан да, өстән дә) почмак ясап, тигез итеп игәүлибез. Телнең бөгелгән урынга кадәрге өлеше – 70 мм. Беркетелгән телне кирәкле тавыш югарылыгына көйләү өчен, телнең очын йә кыскартырга, йә түгәрәкләп бөгәргә, йә игәүләп юкартырга була. Шуңа күрә алдан ук телнең бөгелгәннән соңгы өлешен озынрак итеп калдырырга кирәк.

Җәя кубыз

Кубызда уйнауның берничә алымын тәкъдим итәм:

1) кубызның түгәрәкләнеп килгән башыннан сул кул белән нык итеп тотабыз һәм авызга якын китерәбез. Бармаклар телгә тимәскә тиеш. Кубыз теле йөрерлек ара калдырып, өске тешләрне кубызның өске читенә, аскы тешләрне аскы читенә терибез. Музыкаль авазның сыйфаты шуларны ничек терәүдән тора, ә баш сөяге масса ролен үти. Уң кулның терсәге – иңбашы биеклегендә. Имән бармакның очы белән акрын гына кубыз теленә чиртәбез. Авыз эчен зурайтып-кечерәйтеп, тавышның югарылыгын, тембрын көйлибез. Ул резонатор булып тора. Тынны төрле көчәнештә эчкә-тышка өреп, тавышның көчен көйлибез;

2) имән бармакның очы белән үзеңә таба сугып, кубыз телен тибрәндерәбез. Башка бармаклар, аз гына аерылып, туры торалар;

3) кулларның торышы икенче алымдагы кебек. Имән бармакның очы белән телне ике якка да сугып тибрәндерәбез. Кул чугы беләзектән генә хәрәкәтләнә;

4) уң кулның терсәген иңбашы биеклегенә күтәрәбез һәм, кул чугын беләзектән бөгеп, имән бармак белән үзеңә таба сугып уйныйбыз;

5) шул ук тәртиптә кул чугын беләзектән бөгеп, имән бармак белән ике якка сугып уйныйбыз;

6) сул кулның баш бармагы белән телнең эчке ягыннан каты басмыйча гына тотабыз (томалыйбыз, тавышны бераз «сүндерәбез») һәм уң кулның өч бармагы белән бер-бер артлы чиртеп уйныйбыз. Уйнаганда кубызны тешләргә терәп тә, тешләрдән аерып, бары тик иреннәр белән генә каплап та уйнарга була. Бу алым ярдәмендә ат тоягы, тамчы таму кебек тавышлар матур яңгырый.

Әлеге күрсәтелгән уен алымнары төрле музыкаль авазлар, ритмнар, табигать тавышларын чыгару өчен уңайлы. Көй чыгару өчен авыз куышлыгы ярдәмендә үзең сайлаган көйне күңелдән башкарырга кирәк. ■

ӘДИП-ГАЛИМ-АРТИСТ ГАБДУЛЛА АБЫЙГА МӘДХИЯ

Әхтәм Зарипов

Габдулла абый Шамуковның яңа чыккан китабы («Мәсәлләр җыентыгы») буенча телевизион тапшыру өчен автордан интервью алырга баргач, иң башлап ул үзе сорау биреп, безне телсез калдырды: «Нәрсә, әйттеләрмени? «Теге чир», – диделәрме?»

– Без – яңа җыентык буенча, – дидем мин.

Ә Габдулла абый һаман үзенекен итә:

– Җыентык яңа булса да, «җыентык» инде ул. Гомер буе җыелганнар шунда чагыла.

...Холкының мондый «шырпылы» түгеллеген белгәнлектән, әзерләп килгән сорауларыма җавап алгач, баш режиссер Марсель Сәлимҗановка мөрәҗәгать итеп, Габдулла абыйның үз-үзен тотышындагы сәерлегенең сәбәбен сорадым. Ә Марсель, гадәтенчә, боргаланып-сыргаланып тормыйча: «Анда рак чире тапканнар», – диде. Мин – юләр, бу хәбәргә ышанмыйча:

– Гомер буе аракы эчмәгән, тәмәке тартмаган кешедә рак буламыни? – дидем.

– Була икән шул. Бу интервью алган тасмаларыңның тарихи булуы ихтимал, сакла, – диде Марсель Хәкимович.

Дөресен әйтергә ашыгам: саклый алмадым мин ул тасмаларны. Ә театр, медицина Габдулла абыйны саклый алмады. Китте талантлы мәсәлчебез, мәшһүр тәрҗемәчебез, күпкырлы галимебез, талантлы артистыбыз – әйтәсе сүзләрен әйтеп бетерә алмый – телдән калып, ике милләтне ятим итте. Тууына 110 ел тулу уңае белән мәкалә язарга алынгач, Габдулла абыйның кеше буларак төп сыйфатларын билгеләргә утырдым һәм шунда ук үземдә гаеп таптым: «Кеше буларак төп сыйфатлар кәлимәсе» – үзе үк җавап түгелмени? Кеше булу һәр сорауга җавап була ич! Ул кеше иде!

Әйе, Габдулла абый тормыш ваклыкларыннан азат, нәфесенә хуҗа, дуслыкта талымлы, мәхәббәтендә хыянәтсез, иҗатында даими, кешеләр белән аралашуында ихлас, үз бәхетен тапкан булса да, аны һаман эзләүче шәхес – чын кеше буларак хәтерләрдә яши, яшәр.

...Сусаганда су эчәбез. Габдулла абыйны су белән чагыштырганда, ул дистиляцияләнгән су да, яңгырдан соң чокырга җыелган су да түгел. Билгеле булуынча, дистиляцияләнгән су да, яңгыр суы да эчәргә яраксыз. Габдулла абыйны мин гади авыл чишмә суы белән чагыштырыр идем: сусаганны да баса, сагышны да, шифалы да.

Замандашлары белән бер үк җәмгыятьтә яшәгәч, ул җәмгыять кануннарын күрмәс, ишетмәс (сукыр-чукрак) – гамьсез кеше түгел, ә үзе яшәгән, үзе тудырган шул җәмгыятьнең бер вәкиле иде.

СССРның халык артистлары Ш.Биктимиров, Ф.Халитов, Г.Шамуков. 1980 ел

Театрда эшләгән чагымда миңа Габдулла абый белән артист Вәкил Закировның бәхәсләшүенә шаһит булырга туры килде. Михайлов дигән килмешәкнең, баш режиссер булырга тырышып, татар артистларын газаплаган чоры иде. «Театрны бу хәленнән ничек чыгарырга?» – дигән мәсьәлә буенча әңгәмә корып утырганда, Вәкил Закиров, Габдулла абыйны гаепләп:

– Ширъяздан Сарымсаковны баш режиссерлыктан алу турындагы карарны бертавыштан кабул иткәндә, худсоветта син дә булгансың ич, ник каршы, дип кул күтәрмәдең? Бу сезнең групповщина интересларын яклау булган, – диде.

– Ялгышасың, Вәкил, – диде Габдулла абый моңа җавап итеп. – Групповщина – бер, группа икенче төшенчә ул. Әгәр мин группа интересларын яклаганмын икән – бу начарлыкка түгел. Урысча әйткәндә, мин труппада рухи чисталык хакимлеге өчен кул күтәрдем, ә стерильность өчен түгел. Дистиляцияләнгән су да, елга суы да эчәргә яраксыз.

– Бездә бер төркемнең килешеп карар кабул итүе коллектив фикере, дип сатыла. Групповщина бу!

– Тавышны санарга гына түгел, кем тавышы булуына да карарга кирәк шул. Санау – бер, сынау – икенче.

«Бертавыштан карар кабул ителде», – диләр. Югыйсә, бертавыштан карар кабул иткәнче, мәсьәләне хәл итү генә кирәк ич! Бездә карарлар кабул итү эшләнәсе эшне алыштыра. Габдулла абый, кайсы өлкәдә эшләсә дә, «эшкә барам», дип эшне имитация белән алыштыручы түгел, ә эшләргә баручы чын эш кешесе иде. Язса – үзенекен яза, тәрҗемә итсә – тәрҗемәсе оригиналга тиң, тикшерсә – тикшергәне чын галимнәрчә.

1968 елда «Казан утлары» журналында Габдулла абыйның Сөембикә манарасының төзүчеләре турындагы күләмле мәкаләсе басылып чыкты. Ышандырырлык, махсус белгечләрне дә йокыдан уятырлык гыйльми хезмәт иде ул. Тоталитар идеологиянең ко-

тырган чорында милли истәлекләребезнең аянычлы хәлдә булуы турында тел яшерми язуы аны тиешле органнарга чакырып тикшерүләр белән генә калмады, нәтиҗәләрен дә бирде. Габдулла Шамуков – татар артистларыннан иң соңгы СССРның халык артисты. (Гәрчә бу мактаулы исемгә ул 30 ел элек лаек булса да.) Исән чагында бездә кешене зурлап, тиешенчә кадерләп хөрмәт итү традициясе аның асылына карап түгел, ә хакимиятнең аңа карашыннан чыгып гамәлгә ашырыла иде.

Габдулла абый, чын иҗатчы, мавыгучан холыклы шәхес буларак, тышкы регалияләргә әһәмият бирүдән ерак – ул һәркайда да һәм һәрчак иҗат утында янып яшәде, башкалар да шулай яши, дип ышана иде. Ул гайбәтнең ни икәнен белмәс саф күңелле кеше иде. Гайбәтне ишетмәс чукрак түгел – ишетә, әмма аны үзенчә кабул итә.

Яңгыр астында калса, тавык күшегә, ә каз исә рәхәтләнеп «юына». Габдулла абыйга театр дөньясында була торган төрле гайбәтләр яңгырның казга тәэсире кебек кенә иде. Артист буларак аның сәхнәдә тудырган образлары турында язудан тыелам. Беренчедән, бу өлкәдә эшләүче махсус белгечләр белән бәхәскә керәсем килми. Икенчедән, Габдулла абый, артист буларак, импровизация остасы иде. Бүген болай уйнаса, иртәгә тегеләй уйнаудан да качмый, курыкмый иде ул. Гомумән алганда, Габдулла абыйның «харап иткән», «бозган» рольләре юк. Барысы да образ буларак табылган, реаль кеше образлары иде. Сүземне аның кызыклы, оригиналь шәхес буларак онытылмас якларын хәтерләү белән дәвам итәм. Әгәр язмамда кабатланучы фикерләр очраса, Габдулла абый сүзе белән әйткәндә, инверсия буларак кабул ителсә иде.

Үз фикерләренә кемнедер ышандыру бик мөһим булганда, әдип Габдулла Шамуков бер үк фикерне кабатлаудан беркайчан да курыкмый иде. Әмма ул фикерләр төрле әйтелештә төрлечә яңгыраса да, бер үк максатка юнәлгән булырлар иде.

Яшең 80не узып 90га якынлашканда, юксыну тойгысы кешенең аерылмас озатучысына әверелә икән. Бакыйлыкка күчкән хезмәттәшләр генә түгел, аларның кайбер холык-гадәтләре, эшләгән эшләре, әйткән сүзләре искә төшеп, торган саен ныграк юксындыра. Бигрәк тә бергә эшләгән өлкән артистларның кабатланмас шәхесләр булганлыгын хәтерләгәндә, юксыну сагышка әверелә. Мәсәлән, Шәүкәт абый Биктимировның, җыелышларда бик актив чыгышлар ясаган, әмма иҗатта әллә ни эш кырмаган аумакай холыклы, күп сүзле бер артистка карата: «Коры җирнең каек-кимәсе булды инде бу абзый», – дигәнен хәтерләп, Шәүкәт абыйның сүз снайперы булганлыгын да, теге абзыйны да күз алдына китерәсең. Габдулла абый Шамуковның, ниндидер бер бәхәс вакытында баш бухгалтер ханымның артистларны кимсеткән сүзләрен ишеткәч: «Сезнең сүзгә каршы мин: йөз бухгалтердан театр оешмый, ә менә бер артистлы театрлар бар һәм яшиләр», – дигәне, канатлы фикер буларак, театрда һаман телләрдә яңгырый, Габдулла аганы хәтерләтеп юксындыра.

Бер сүз белән әйткәндә, Габдулла Шамуков шәп артист иде. Ә кеше буларак ихлас күңелле, ялган-риясыз, ышанучан һәм үзенә тиз ышандыручы, мавыгучан кеше иде. Мавыгучанлыгы турында театр эчендә төрле мәзәкләр тууын әйтеп узу да гайбәт дип кабул ителмәстер, шәт. Репетицияләрдән буш вакытларда тәнәфесләрдә Габдулла абый, дөньяларын онытып, шахмат уйнарга ярата иде. Шулай бер уен вакытында ул, рольдәге киемен алыштырырга өлгермичә, азарт белән уйнап утырганда, кинәт радиодан режиссер ярдәмчесенең, Габдулла абый, дип чакырган тавышы яңгырый. Кулына ат фигурасын тоткан, бер аягына туфлиен дә кимәгән килеш, артист сәхнәгә атылып чыккан, имеш. Бу хәлнең дөрес булуына Габдулла абыйның башка чакларда мавыгулары да дәлил.

1963 елда театр, Уфага гастрольгә барырга, дип, зур пароходны тулысынча яллады. Мондый юмартлыкны күрмәгән артистлар, юл ризыкларын мул әзерләп, каюталарга

«Әни килде» (Ш.Хөсәенов) спектакленнән бер күренеш. Г.Ибраһимова, Ә.Зарипов, Г.Шамуков. 1970 ел

урнашты, тәмам «бәйдән ычкынып», иң юмарт һәм кунакчыл хуҗаларча бер-берсен кунак итешүгә күчте. Моңа пароход йөртүчеләр дә җәлеп ителеп, күпмедер вакыт узуга, төнлә пароходыбызның сайга утырганлыгы мәгълүм була. Театр җитәкчеләренең ничек кайгырганын күзаллау кирәкмидер, әмма Габдулла абыйдагы шатлануның чиге юк иде. Аңа кызык һәм күңелле. Махсус аның өчен оештырылган бер чара кебек иде бу хәл. Ул, һәр очраган кешене туктатып, кызарып чыккан кояшка сокланырга куша, һаман бер үк сүзне кабатлый: «Романтика бит бу!» – ди, шигырь сөйли, директорга рәхмәт укый. Ә директор, икенче пароход чакыртып, коллективны Уфага соңлатмау мәшәкатьләрендә кайный. Әйе, икенче пароходка күчерделәр. Кузгалып киттек. Барысы да шат һәм аек. Тик Габдулла абый гына пошаманда, чөнки аны романтикадан мәхрүм иттеләр...

Ниһаять, пароходыбыз Алабуга шәһәре пристанена җитеп туктый. Кемнәрдер шәраб киоскысы эзләп чыкса, Габдулла абыйга газета кирәк. Анысы өстәрәк икән – шәһәр эчендәрәк. Пижама һәм юка башмак кына кигән халык артисты, аны-моны уйлап тормый, газета эзләп йөгерә. Тапса, пижамасында акчасы юк икән, каютада калган. Газета ала алмый. Ә каютасына, дип борылып чапса, пристаньда пароход юк! Көтмәгән – киткән! Нишләсен, Габдулла абзабыз турыдан-туры райком секретарена бара, хәлне сөйли. Пароходны гаепли. Башкортстанның атказанган артисты дәрәҗәсенә 1943 нче елда ук лаек Габдулла абыйның даны райкомнарга үтеп кергән чак була, күрәсең. Аны, яхшы костюмнарга киендереп, «Волга» машинасына утыртып, Уфага озаталар. «Свердлов» пароходын Габдулла абыйның ничек каршылаганын чамалыйсыздыр... Шулай, Габдулла абый һәрнәрсәдән кызык таба, матурлык эзли һәм соклана белә, башкаларны да сокландырырга тырыша иде.

Ул борынгы кием-салымнарга, йолаларга, гадәтләргә үтә игътибарлы булды. Бу аның узганнарга гашыйк булып яшәвеннән түгел. Ул күп нәрсә белән тиз мавыга иде.

Узганнар белән генә яшәгәнне – бәхетсез, киләчәк белән генә яшәгән кешене – хыялый, бүгенге белән яшәгән кешене мәнсез, диләр. Өч заманны да күңеленә сыйдыра алганны гына иҗади кеше, камил зат, диләр. Габдулла абый шундый иде.

Кешене күтәрү өчен кайчак аның бик күп әйбәт сыйфатлары да аз тоела. Ә төшерер өчен бер йомшаклыгын атау да җитә. Габдулла аганың йомшак якларын мин белмим. Кемнәрдер белгән һәм тиешле урынына җиткергән, күрәсең. (Аңа СССРның халык артисты исеме иң соңыннан гына бирелде. Хәер, бирелмәгән булса да, Габдулла Шамуков исеме дәрәҗәләрдән дә данлы иде.)

Ул милләтебезнең мәдәният тарихында үз киштәсенә урнашып, шул биеклектән безне күзәтәдер кебек. Без исә – аның варислары, останың тарихтагы урыны дөресмеюкмы – шуны ачыкларга тиешбез. Күңелдә аның бер сүзе һаман яңгырый кебек: «Аңламадылар».

Бүген режиссер Марсель Сәлимҗанов исемендәге премия булган кебек, аның остазы Габдулла Шамуков исемендәге премия булдырылса, бу чара артистның 110 еллыгына бүләк, татар театрының дөньякүләм данын үстерүдә нәтиҗәле рухландыручы нәрсәгә әверелер. Әлеге премия, кәсепчеләрдән чын иҗатчыларны аера белүгә юнәлтелгән гадел һәм тәвәккәл чараларның берсе буларак, җәмәгатьчелек тарафыннан хупланып кабул ителер иде. **Күпкырлы иҗатчы Габдулла Шамуковның исеме әлегә кадәр Казаныбыз урамнарының берсенә кушылмавы да бик аяныч!**

Бу хәлләрне күрмәмешкә салышуларның сәбәбен сер итеп сакламыйча, данлы шәхесләребезнең исемен мәңгеләштерүдә тәвәккәл бер адым ясалса, останы юксынып сагышланучы варислары гына түгел, гомумән, милли тамашачыларыбыз да рәхмәтле булыр иде.

Әйе, Габдулла абыйны үз вакытында аңламадылар, дөресрәге, без – замандашларың сине аңламаганбыз. Аңлаган булсак, син эшләгәннәреңнән күбрәк эшләгән, уйнаган рольләреңнән күбрәк уйнаган, язганнарыңнан күбрәк язган булыр идең.

Әмма синең кылган хезмәтләрең ике артист, бер әдип шәхесенә җитәрлек. Шулар өстенә син эстрада остасы, галим-педагог та идең! Кызганыч, без бу хезмәтләреңне соңарып кына күрдек. Хәзер инде сиңа боларның әһәмияте юк. Әмма варисларың өчен кирәк! Дөнья классигы Шекспирның ун әсәрен, Лопе де Вега, Мольер, Шиллер, Бомарше, Золя комедияләрен, Пушкин, Грибоедов, Островский әсәрләрен татарча укыткан, сәхнәдән татарча яңгыраткан тәрҗемә остасы Габдулла Шамуков әле бүген дә тиңсез. Син тәрҗемә иткән әсәрләрдә автор стиле, шигъри сөйләм, тел үзенчәлекләренә хилафлык килми генә түгел, син хәтта үзең тәрҗемә итәргә алынган авторның шәхси үзенчәлекләрен дә татар укучысына, татар тамашачысына җиткерүгә ирешә идең.

Антик дөнья сәнгатенең атаклы әсәре – Эсхилның «Прометей»е белән дә татар укучылары синең тәрҗемәң аша танышты. Шигырь белән язылган бу катлаулы әсәрне татарча уңышлы яңгыратуга, бер яктан, синең үзеңнең шигырь төзелеше мәсьәләләре белән якыннан кызыксынуың, шигырь язу теориясен яхшы белүең, икенче яктан, поэзияне тәрҗемә итүдә туплаган бай тәҗрибәң һәм төрек, гарәп, фарсы телендә язылган шигырьләрне шул телләрдә укый алуың ныклы нигез булгандыр.

Мәсәлче буларак та әле милли әдәбиятыбызда син ирешкән биеклекләргә күтәрелгән шәхес бармы икән?! Шәхсән үзем белмим. Мәсәлнең кинаягә нигезләнгән традицион алымнары сиңа шактый гыйбрәтле сюжет-вакыйгалар корырга, образлар тудырырга мөмкинлек биргәндер кебек. Мәсәлән, креслода утырган Мияугалиең мал врачы Ябалакка шылтырата:

– Тыңласана, зинһар,
Сезгә бик зур йомышым бар,
Маэмайның хәле бик начар.
Нур калмады күзләрендә,
Сагыш, хәсрәт йөзләрендә;
Шундый сизгер, уяу сакчы,
Хәзер бакчы,
Йоклап китә постта торган җирләрендә,
Ял кирәк, ял! Юкса аның эше харап...
Төпле киңәш бирегезче,үзен карап...

Мондый сөйләшүне ишеткәч, тавыклар аптырап кала:
– Мияугали дошманы өчен ник шулкадәр өзгәләнә?
– диләр.

Мәсәлнең асылын Әтәч аңлатып бирә:

– Мияукайга һич ошамый мондый сакчы,
Шунда ул бар дип күрсәтеп илдә юкны,
Сау-сәламәт Маэмай дусын
Авырый, дип, пенсиягә озатмакчы...

Кыскасы, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр турында сөйләүче шундый аллегорик образлардан һәм шартлы вакыйгалардан тыш, мәсәл язуда шигъри фикерне төрле әйбер-предметлар яки турыдан-туры кешеләрнең үз образлары аша ачу алымын да кулланып, Габдулла ага Шамуков өч дистәгә якын оригиналь мәсәл иҗат итте. Ул мәсәлләр әле бүген дә актуальлеген югалтмады бит. Бүген бармы аңа алмаш?! Юк!

Әмма Габдулла Шамуков барыннан да бигрәк артист, сәхнә остасы иде. Аның иҗат юлы 1930 елда Уфада Башкорт академия театрында башлана. 1946 елда аны Г.Камал исемендәге театрга махсус чакырып алалар. Шуннан алып гомеренең ахырына кадәр ул Казанда, татар халкының баш театрында хезмәт итте.

Кайбер артист гомер буе бер характердагы образлар иҗат итә. Габдулла Шамуков – холык-фигыльләре, табигатьләре белән бер-берсеннән бик нык аерылып торган, капма-каршы образларны да бердәй осталык белән башкара алган киң диапазонлы артист-виртуоз иде. Моңа дәлил итеп, Ленин, Тукай, Хуҗа Насретдин, Балтаев образларын искә төшерү дә җитәдер.

Шунысы хак һәм куанычлы: татар сәхнәсендә Габдулла Шамуковның гаять самими, үзенчәлекле, күпкырлы таланты, шәкертләрендә уңдырышлы туфрак табып, тамыр җибәрде, чәчәк атты, җимешләрен бирде. Бигрәк тә Г.Камал исемендәге театрда.

Габдулла Шамуков – сәхнә остасы – артист кына түгел, җәмәгать эшлеклесе дә, милләтпәрвәр гыйлем иясе, тикшеренүче-тарихчы да иде. Аны кайда да үз итеп, белгеч буларак, киңәшче-табышчы итеп кабул иттеләр. Ул үз тиңнәре – иҗатчылар белән тиз танышып, дуслашып китә, бәхәс-манзаралар ярата торган, яңалык һәм ачышларны күрә белгән зирәк һәм тапкыр кеше иде. Кызганыч, бик теләсәк тә, без бүген Габдулла ага Шамуковка тиңләрлек, аның диапазоны белән чагыштырырлык артист – шәхес табып: «Менә ул шундый иде!» – дип күрсәтә алмыйбыз.

Габдулла абый бар иде, бер иде һәм шулай булып кала да. Бәлки, иҗат кешесенең кыйммәте нәкъ менә шундадыр – бар, бер, кабатланмас булуда! ■

Безнең мирас №12 декабрь 2019

ГАСЫРЛАР-ЧОРЛАР АША – ЯҢА ҮРЛӘРГӘ!

Розалина Шаһиева

«Зур бәхет инсанга – һәр көн, һәр сәгатьтә яхшыру;
Яхшыру юк булса анда: «Яхшы мин! – дип лаф ору!»

Г.Тукай. «Толстой галиҗәнапларына»

...Әйләнә-тирә табигать тылсымын, гүзәл стихияләр, әкәм-төкәмнәр, бөҗәк-мәхлуклар һәм башка шундый күзгә күренмәгән газиз тамашаларның биоэнергетикасын, диңгез гөрелтеләрен, йолдыз-планеталарның галәм киңлекләрендә йөзү авазын, карурманнар мәңгелеген, тарихи алышларның бөек кодрәтен һәм Аллаһы Тәгалә вә галәм-табигатьнең иҗат җимеше – кеше – адәм галәмәтенең гүзәллеген тәкрарлаган, җәмгыятьнең «таркалган зиһен күзәнәкләрен» төрле могҗизалар аша кайтаручы илаһи көч – мәдәният-сәнгать, музыка, әдәбият, шигърият гаҗәеп тәэсир көченә ия. «Измеряй все доступное измерению», – дигән Галилей... Ләкин сәнгатьнең тәэсир итү көчен үлчәү җиңел эш түгел!.. Безнең чор галимнәре уйлап тапкан сизгер приборлар ярдәмендә сәнгать әсәрләренең йөрәк һәм кан тамырларының камил эшләүләре процессына тәэсирен, кешенең сәнгать аша алган эмоциональ дулкынлануының самими рәсемен һәм башка төрле шундый уңай физиологик процессларны фәнни дәлилләргә була. Бу тәэсир нәкъ менә Каюм Насыйриның «Шифалы үләннәр» исемле китабындагы кешене уятучы, «тирләтүче», тынычландыручы һәм илһамландыручы – холкын

йомшартучы, акылын камилләштерүче үләннәрнең шифалы тәэсире белән бермә-бер... Сәнгатьнең рухи тәрбия өлкәсенә караган чагыштыргысыз көч-куәте булу – һәммәбез өчен дә һич шөбһәсездер... Бу сәнгать трансляциясен тапшыручы, гүзәллек һәм акыл бөркеп, йөрәкләрне җилкендереп, ераклардан чакырып торучы «учак-әхрамнар» бик күптөрле: алар тарих тәрәккыятендә төрле шәкелләр алып, күз алдына йә гигант Колизей, яисә юнан халыклары төзегән мәһабәт Акрополь, мисырлыларның серле пирамидалары, Гыйрак, Иран, Урта Азия һәм Һиндстан җирлегендә төзелгән Тадж-Мәхәлләр, Идел Болгарстаны төрбә һәм мәчетләре булып килеп басалар. Гасырларны тоташтырып, безгә узган цивилизацияләрдән хәбәр тапшыралар... Вакыт уза, заман үзгәреп тора, һәр чор үзенең сәнгати михраб-галәмәтләрен тудыра!

90 нчы елларда, ниһаять, күз алдыбызда – милли идеяләр белән азыкланган, мәйданы, географиясе Балтыйк буеннан алып Казакъстанга кадәр җәелгән, тарихчанлык, дәүләтчелек, милли горурлык идеяләре белән сугарылган яңа мәдәни мохит, милли сәнгать туды.

Татар тарихын һәм мәдәниятен без, тоташ бер цивилизация итеп, бөтен дөньяга таныттык: Венгрия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Төркия, Италия, Париж, Мәскәү һәм Петербурглардагы сәнгать мәйданнарына татар халкының милли җәүһәрләре, көчле ташкын яки вулкан кебек, сискәндереп килеп керде, зур абруй яулады. Ул гына да түгел... Күмерле көл арасыннан Казаныбызның меңьеллык образын торгыздык. Тарихта беренче мәртәбә, гасырлар буе хыялланган милли мәдәният әхрамын кабыздык... Башкалабызда бер-бер артлы, безнең тәэсиребез нәтиҗәсендә, Татарстанның туган як музее (Краеведческий музей) үзен Татарстан Республикасының Милли музее дип игълан итте, нәфис сынлы сәнгать әсәрләре җыелмасыннан гыйбарәт, аның үсешен тарихи эзлеклелек белән күрсәтүче музей – «Хәзинә» комплексына әверелде, күптөрле борынгы вә бүгенге сәнгать манзараларын тарихи дәүләтчелегебез идеясе белән берләштергән яңа «сәнгать территориясе» – Кремль тыюлыгы барлыкка килде. Бер-бер артлы халык хәтеренең «алтын баганалары» – Болгар, Биләр, Зөя тарихи-мәдәни тыюлыклары күтәрелеп чыкты. Шулай итеп, тарих белән бүгенгене тоташтырган, киләчәккә омтылган «милли үзаң челтәре» пәйда булды... Мәдәни мәркәзләр, яңа музейлар белән беррәттән, күләмле сәнгать әсәрләре, әдәби басмалар, гимн-поэмалар, әдәби әсәрләр иҗат ителде. Ниһаять, нәкъ менә шәһәребез һәм милләтебезнең халыкара данын күтәргән, дөнья һәм Россия киңлекләрен биләп алган «Татар дөньясы» гыйбарәсе туды. Милли сәнгать стихиясе, ниндидер микъдарда – һәр кешегә, һәр гаиләгә, даирәгә үтеп керде...

Ләкин тоташ бер фикер, концепция нәтиҗәсендә туган, борынгыдан бүгенгегә килеп тоташкан эзлексез милли аң феномены, аның могтәбәр зыялы иҗаткярләре, фән һәм мәдәниятне тоташ интеллектуаль пантеонга әверелдергән, Франциянең мәшһүр сынчысы Роденның барыбызга да мәгълүм «Кале шәһәре гражданнары» композициясендәгечә бердәм рух һәм ирек бердәмлелеге идеясе булып килеп баскан, ниндидер микъдарда «Ватан» төшенчәсен гәүдәләндергән әсәрләр тезмәсе тумады әле.

Әйе, сәнгатьнең, бигрәк тә иң беренчел сенсор гамәл – «күз күреме» сәнгате – рәсем, сурәт өлкәсенә караган нәфис сәнгатьнең – тирән, зур мәгълүмати эчтәлекле, күләмле гыйбарәләр тудыру осталыгы дөнья күләмендә күптән акланган. Бу фактор безнең проблемага килгәндә дә зур өмет тудыра, канатландыра, яңа мөмкинлекләргә ишарәли. Хыялларда күптән хөкем сөргән «Ватан» образы, «Казан һәм казанлылар», «Татар дөньясы», «Без тарихта эзлебез» дигән темалар, ниндидер зур монументаль панно, фреска сыман зур формалар аша, күптән үзләренең чишелешен көтәләр...



VIII гасырга караган шигъри-фәлсәфи текстлы мәшһүр Күлтәгин ташы

...Тикмәгә генә нәкъ менә Казан шәһәрендә Европа белән Азия дөньясының бербөтенлеген тойган, интуитив рәвештә шәрык фәлсәфәсендә үзенә соңгы таяныч тапкан, Казан университетының шәрык телләре факультетында укыган **Лев Толстой** Ватан турында мондый хикмәтле сүзләр язып калдырмаган: *«Ватан ул – борынгыдан, тарих төпкелләреннән килгән, үзенең телен, мәдәниятен киләчәккә җиткерергә омтылган, бу җирлектә яшәүгә катгый хокукын тойган, төрле шәхесләрне, умарта кәрәзе кебек, бер вакыт дисбесенә кертеп берләштергән бербөтен, мәңгелек төркем...»*

Татарлар – менә шундый бер мохиттә, тузынган ана корт аерган умарта өере кебек, зур популяция, бөек төркем. Максатыбыз – гел яхшыру, камиллеккә омтылу, тәрәккыят итү, мәңгелеккә ашу...

Ватаныбыз бертуктаусыз хәрәкәттә. Ул киңәя, тетрәнүләр кичерә, кайвакыт хәрабәләр эчендә дә кала, көч җыя, җәрәхәтләрен төзәтә, үзен төзекләндерә, яңа сәнгати-рухи мохит тудыра... «Җир-нигез» дигән әйбер бездә гел алмашуда, төрле амплитудаларда тирбәлүдә, һәрвакыт үзгәрештә... Ләкин без аның тәэсирен, йөрәк тибешен, хикмәтен гел тоябыз, аның белән гел бергә тибрәләбез, үләбез – юкка чыгабыз, ләкин, берара вакыт узгач, үлемсез әкияти коштай, яңадан туабыз, төзибез, ашлыйбыз, эшкәртәбез, төзекләндерәбез – максатыбызга табан тагын бер адым атлыйбыз. «Яшәү орлыгын» үзебезнең буыннарга тапшырабыз.. Аның тылсымы, магниты зур. Ул – үзе бер олы кояш һәм без аның җылы нурларында коена торган, тернәкләнеп киткән мохит – бөек газиз төрки– татар – Болгар, Урда, Казан иле! Әлбәттә, халкыбызның күмәк образын, аның тышкы портретыннан бигрәк, «күңел сурәтен тудыру», узганын – тарихын, ул иҗат иткән, тудырган күңел ядкярләрен барлау, борынгы белән киләчәкне тоташтыру, берләштерү һәм, ниһаять, аның «рухи сакчыларын» – әдипләрен, фәйләсүфшагыйрьләрен бер мәрҗәнгә тезү яисә аның бербөтен портрет галерeясын тудыру җиңел эш түгел. Бу, әгәр без тарихсыз, телсез, мәдәниятсез халык булсак, химерик ният, утопия булыр иде. Ләкин безнең зур, тотрыклы мәдәни тарихыбызда сәнгатнең төрле өлкәләренә караган гаҗәп шедеврларыбыз, аларны иҗат иткән фидакарь шәхесләребез, бөтен дөньяга яңгырап дан алган эпос-поэмаларыбыз бар!

Шул уңайдан әйтеп китик. Бөек немец әдибе Генрих Гейне италиялеләр турында: «аларның милләте – музыка», – дип билгеләсә (өстәп әйтик, рәссамчылык та!), татар халкының милли рухи билгесе, коды, образы ул – әдәбият, беренче чиратта, шигърият. Меңьеллык татар тудырган хикмәтле мираста, ул – һичшиксез, беренчел катлам, бәһассез байлык! «Мирас күзәнәге!»

VIII гасырга караган шигъри-фәлсәфи текстлы мәшһүр Күлтәгин ташларыннан алып, Йосыф Баласагуни, Мәхмүт Кашгари, Мөхәммәдьяр иҗатлары, бөтендөнья күләмендә яңгыраш тапкан Г.Тукай, М.Җәлил шигъриятенә килеп тоташкан бу «көмеш чылбыр» – милләтнең «умыртка баганасы», дөньяны танып белүнең төп ысулы һәм тәрбия чарасы. Дөньяга Кол Галинең «Кыйссаи-Йосыф»ын, Тукаебызның «Шүрәле» һәм ...«Кисекбаш»ларын, Муса Җәлилнең мәңге үлмәс «Моабит дәфтәрләре»н биргән әдәбият – татар халкының мәңге тутыкмас күңел көзгесе, җан-рух – йөрәк тамгасы, акыл-фикер бөеклеге дәрәҗәсе. Шунлыктан, үзебезнең милләтебез хакында зурдан кубып сүз алып барганда, беренче чиратта әдәбиятыбызны күз алдына китерәбез.

Бүгенге Казанның мәдәни картасы-панорамасына күз салыйк!

Әле бүгенге көндә безнең дөньякүләм бәһагә лаек булган, шәрык мохитендә иң яхшы музейларның берсе дип саналган милли әхрамыбыз бар. Анда үзебез иҗат иткән технологияләрне сеңдергән, татар тарихынербөтен итеп күрсәткән шаһәсәрләр: алтын «Казан тажы» һәм «Казан тәхете», әкияти тәэсирле могҗиза – «Казан капкасы» һәм, гомумән, борынгыдан бүгенгә кадәр тәрәккыят иткән мәдәни мирасыбыз саклана... Казан кирмәнендәге «Хәзинә» галереясында «Россия татарлары» дигән фотокүргәзмә, Кирмән мәйданчыгында «Татар династияләре» дигән ачык һавадагы панорама – тарихи монументаль тезмә, милли саклагычларда борынгы кулъязмалар, язма мирас үрнәкләре урнаштырылган. Бүгенге татар «китап фабрикасы»нда (Татарстан китап нәшриятында) китаплар нәшер ителә. Һәм, гомумән алганда, бүгенге көн татар мәдәнияте учакларында җанлы иҗади, игелекле тормыш гөрли, яңа идеяләр туып тора, шәхесләр – шәхесләр белән, чорлар чорлар белән очраша. Бу тынгысыз кайнау галәмәте безгә борынгыдан ук «кан әйләнеше» – генетик код шәкелендә бирелгән һәм хәзер дә үз эшен дәвам итә. Әлеге халәтне бүгенге фәйләсүфләр «динамизм» дигән төшенчә аша аңлаталар. Һәм бу кайнарлык, әверелешләр, мистификация – мифологик уйдырмалар, тормышны хыялда булса да яхшыга үзгәртергә омтылу заманында бездән бөтен дөньяга ургылып кергән һәм андагы торгынлыкны какшаткан.

Иң борынгы мирасларыбызның берсе – әдәби җәүһәрләребезгә баксак, бу фактның тулаем рәвештә гәүдәләнүен күрәбез.

Җәнүб Кырымда, Тын (Дон), Дунай елгалары буенда эллиннар тәэсирен татыган, (дөрес, биредә тәэсир ике яклап барган), эпик грек авторы саналган бөек әдип Гомерның (Гомәрнең) әсәрләрендә үк инде Ватан, ил турында сөйләм-уйланулар, хәтерләү стихиясе хөкем сөрә: әдипнең исеме дә төрки-шәрыкчә яңгырый; әсәрләре исемендә дә безнең назым – шигъри аһәң, «көйләп уку» традициясе гәүдәләнә. Бүгенге галимнәребезнең гипотезалары буенча, бөек илаһи поэмаларның исемендә үк «Ил хәтере» – «ил яды», «Илиада» – «илне яд итү» дигән төшенчә, ә «Одиссея»дә исә («әтисе») – ыруг башы, ил агасының каһарманлыклары, аның гакыл тирәнлеге һәм бу этноска хас һәрчак дөньяны күреп белүгә омтылу – сәяхәт, «кәчәбәлек» инстинкты сурәтләнгән. Ул – тарихи пассионарийларның беренчесе, вакыйгалар да төрки җирлектә бара (Троя – Тура» шәһәре бүген Төркиягә карый).

Кол Галинең ЮНЕСКО исемлегенә кергән, Болгар чорына караган «Йосыф вә Зөләйха» поэмасы (XIII гасыр) дөньякүләм шедеврлар тезмәсендә шөһрәтле урын алып тора. Шагыйрь әсәрендәге Йосыф образында, борынгы традицияләргә тоташып,

бөтен иҗади хирыслыгы белән халык авыз иҗатына хас тирән, саф, хәвефле мәхәббәт, акыл вә хис, эчке вә тышкы гармония мәсьәләләрен күтәрә. Тәңречелек ырымнарын да үзенә туплаган, гасырлар буена җырланып килгән, аруз ритмында көйләп укылган поэмада әле мәҗүсилек инануыннан килгән фантазия – «гүзәл ырым» – алымнар яшәп килә: «ай белән кояш та Йосыфка баш ияләр», «нур» идеалына табыну, архаик, ислам диненә кадәрге нәкыш, яшәү чалымнары (Зөләйха сараендагы алтын-көмеш сыннар һ.б) – барысы да гадел, иман кушканча гамәл кыла торган, акыллы һәм камил кеше образы тирәсендә туплана.

Идел Болгарстаны чорыннан җирне сөю, Ватан төшенчәсе, үзеңне галәм киңлегендә тою, фән һәм табигать күренешләрен аңларга омтылу татарда этник беренчел үзаң, фәлсәфә яралгыларын формалаштыра. Бу процесс, эзләнүләр Европа илләренә Шәрыктән килеп җиткән Яңарыш чорына килеп тоташа.

Болгар цивилизациясе һәм, Алтын Урда дәүләтенең дәвамчысы буларак, бүгенге Татарстан территориясендә мөстәкыйль мөселман дәүләте – Казан ханлыгы формалаша. Яшәеше гел үзгәреп торган, бөтендөнья сәясәтенә тоташкан, Европа һәм Урта Азия, Шәрык дөньясы белән тыгыз элемтәдә торган Казан ханлыгы XV-XVI гасырларда чын мәгънәсендә «чәчәк ата», үзенең дәүләтчелеген, мәдәниятен, сәясәтен тудыра. Моңа мәмләкәтнең географик урыны һәм күпчелек халыкларның уртак дине булган ислам дине, сәяси, икътисади, сәүдә багланышлары этәргеч бирә.

Бу чорда Казанда югары дин башлыгы – Казан ханлыгы чорының шөһрәтле затларының берсе – сәет Кол Шариф тә иҗат итә. Дипломат, мөгаллим, моңлы философ, патриот шагыйрь, Казанны Явыз Иван явыннан саклаган чакта үз мәчете капкасы янында батырларча һәлак булган Кол Шәрифнең фаҗигале язмышы турында хәбәр-риваять, аның берничә шигъри тәлгәше безнең көннәргә кадәр килеп җиткән («Гыйкаб», «Зөфәрнамә-и вилайет-е Казан» һ.б.).

Ир-ат шагыйрьләр арасында лирик, мәхәббәт шигъриятенең ватанпәрвәрлек идеяләре белән кушылуын гәүдәләндергән Сөембикә ханбикә иҗаты да алтын фольклор утравы булып кала. Ул – шулай ук шагыйрь, бәет, келәүләр, моңлы мөнәҗәтләр авторы. Аның XVI гасырга караган, Кабан күлендә табылган латун-бакыр кувшинына язылган шигъри юллары, халык телендә сакланып килгән бәетләре нәкъ шул хакта сөйли. Күз алдына «Әрхәрәй» дачасына урнашкан Сөембикә бакчасы – «Бустан», андагы китапханәсе, яшәеше килеп баса, шигырьләрендә чагылган күрәзәлек галәмәте, шәхси фаҗигасе тирән уйга сала.

XVI гасыр Казан ханлыгы чорының иң күренекле шагыйре, әлбәттә, Мөхәммәдьяр:

«Тарихның тукыз йөз кырык сәкесендә
Мөбарәк мөхәррәмнең уникесендә,
Болгар шәһре Казан дәрвазасында –
Мөхәммәт Әмин хан каберендә, и шәһрияр,
Моҗавир иремен бәси булып зар...»

Үзенең милләтенә ул XIX гасырның беренче яртысында «Азиатский музей»ның кулъязмалары арасында кайтып керә. «Төхфәи мәрдән» һәм «Нуры содур» поэмалары (1539-1542 еллар) авторы, Сафагәрәй хан идарә иткән чорда яшәгән шагыйрьнең язмышы фаҗигале... «Ваш поэт Могаммедьяр убит нашими при Муроме», – дип яза Явыз Иван Сөембикәгә... Шагыйрь, халык, дигән төшенчәне йөрәгендә саклап, әдәбиятта беренчеләрдән буларак, сыйнфый тигезсезлекне күрә һәм моның сәбәпчеләренә каршы ук ата:

«Мән ирермен бу шәһәрдә бер фәкыйрь,
Ил күзендә гаҗиз, вә хур, вә хәкыйрь» .

Шәрык телләрен, шигъриятен, фәлсәфәсен тирәнтен белгән шагыйрь, бөек татлы «аруз» ритмыннан гайре, игътибарын үз халкының сәясәтенә, социаль хәленә юнәлтә; «гөл», «мәхәббәт» темалары урынына халык идеалларын, мәнфәгатен алга сөрә. Аның шигъри юлларын татар әдәбиятының киләчәк шагыйрьләренә хас булачак уйланулар, кайгы-хәсрәт вәземнәре баса, ул, «сарай», «хан йорты» шагыйре генә булып калмыйча, ирекле, үзсүзле, хакимияткә буйсынмый торган, киләчәктәге гарасатны тоеп еглаган халык җырчысына әверелә:

«Кыйнадың җанымны, белмәк йазыкым,
Кайгы-хәсрәт булды сәндин азыкым...»
«Искә алырлар бу сөекле гидайны,
Дога белән сөендерерләр аны».

Ул шигърият стихиясенең мәңгелеген – андагы мәгълүматның, хисләрнең мәңгелеген, аларның киләчәк буыннарга килеп җитәчәген исбатлый.

«Камил шәхес», ватанпәрвәрлек идеясе бүген дә дөньякүләм әһәмияткә ия. Иран шагыйрьләренең 2008 нче елгы симпозиумында бу идея тагын бер кат зур трибуналардан тәкрарланды; Коръән битләреннән, Нәваи, Дәһләви шигъриятеннән килгән кешенең «бәхетле ил, җир» биләмәсен эзләве, үзен һәм үзе яшәгән мохитне камилләштерүгә омтылу тенденциясе бүген дә бөтендөнья шигърияте, шул исәптән татар шигъриятенең дә чыгыры булып кала бирә.

Борын-борын заманнардан килгән шигъри шаукым татар халкының рухында мәңге яшәп килә... XX гасыр башында мәдәният күгендә яңа сәнгать төрләре борнап чыга: сынлы сәнгать, татар театры, профессиональ музыка һ.б. Әдәбият һәм сәнгать мәйданына Г.Камал, Г.Тукай, Һ.Такташ, Б.Урманче, Х.Туфан, С.Хәким, Муса Җәлил, Заһид Хәбибуллин, С.Сәйдәшев, Һади Такташ, К.Тинчурин һ.б. килә... Һәм алар арасында даһие – гаҗәеп, могҗизаи Тукай!..

Безнең чор – мәдәни тарихыбызга яңа «йолдызларын» өсти.

Алдарак әйтелгәннәрдән чыгып, сәнгатьнең төрле ысуллары – җанлы тарихи мәгълүмат, образлар – узган чор һәм аның даһилары белән беррәттән, бүгенге татар сәнгать осталарының идеалларын ачучы, аларның тарих агышы дәвамында барган Казанга тартылу көчен сурәтләүче, үз милләтенең узганына баш июче, киләчәген күрәзәләүче, мәдәниятнең «алтын җебе» белән бер-беренә тоташучы әсәрләрнең нәфис тезмәсе иҗат ителергә һәм үзенең лаеклы урынын шәһәребезнең берәр олуг мәйданында, музей-пантеонында табарга тиеш. Аның миссиясе – «тарих тузанына күмелгән елларга әйләнеп кайту», даһилар калдырган мирасны барлау һәм бүгенге интеллектуаль байлыкка әйләндерү, аңсыз манкорт-монстрлардан аермалы буларак, техноген белем һәм кабатланмас мирасны бергә туплаган киләчәкле һәм сәләтле – нәкъ менә «Толстой галиҗәнаплары өндәгән, бертуктамый «яхшыруга» омтылган «алгарыш» («динамизм») чоры шәхесләрен тәрбияләү. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2019

НОЯБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 30 октябрьдә Чаллының М.Җәлил исемендәге үзәк китапханәсендә шагыйрь Нияз Акмалны (1954-2007) искә алу кичәсе булып үтте. Кичәдә шагыйрьнең туганнары, каләмдәшләре, дуслары катнашты һәм чыгыш ясады.

● Ноябрь башында Кукмара районының Өркеш авылында яу кырында башларын салган каһарманнар истәлегенә обелиск ачылды. Анда Өркеш, Октябрино һәм Хасановка авылларыннан сугышка китеп, мәңгелеккә чит җирләрдә ятып калган 97 ир-егетнең исемнәре уеп язылган.

● 5 ноябрьдә Екатеринбургта «Щелкунчик» балет театры сәхнәсендә, XIII Халыкара «Коляда-Plays» театр фестивале кысаларында, Әтнә татар дәүләт драма театры драматург А.Батуринаның «Фронтовичка» спектаклен (режиссеры – И.Казакбаев, рәссамы – А.Нестеров, композиторы – М.Мезинова, хореографы – О.Даукаева) тәкъдим итте. Нәтиҗәдә, әлеге спектакль Николай Коляда бүләгенә лаек булды. Котлыйбыз!

● 7 ноябрьдә Камал театры артистлары Яңа бистәдәге татар зиратында мәшһүр режиссер Марсель Сәлимҗанов каберен зиярәт кылды.

● 8 ноябрьдә Татарстан Язучылар берлегенең Киңәшмәләр залында «Чыңгыз Айтматов безнең күңелләрдә» дип аталган түгәрәк өстәл булып узды. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Д.Салихов алып барган әлеге чарада язучылар Ф.Бәйрәмова, Х.Миңнегулов, Х.Бәдигый, А.Юнысова, Н.Сафина, Л.Лерон, сәнгать әһеле В.Гәрәева катнашты һәм чыгыш ясады. Чара вакытында язучылар Ч.Айтматовның әнисенә багышланган «Ана» романы (Ф.Бәйрәмова әсәре) турында фикер алышты, истәлекләр белән уртаклашты.

● 14 ноябрьдә Татар әдәбияты тарихы музеенда һәм Шәриф Камал мемориаль фатирында (Татар китабы йортында) Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының шәһәр семинары узды. Музей

директоры Луиза Янсуар Татар китабы йортының «һәр татар баласы укырга тиеш 100 китап» проекты белән таныштырды.

● 14 ноябрьдә Казандагы «Ногай» кунакханәсенең Тукай клубында Татарстан китап нәшриятының 100 еллыгы уңаеннан конференция һәм К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында әдәби-музыкаль кичә булып үтте.

● 15 ноябрьдә Тукай районында күренекле шагыйрь Фәннур Сафинга нисбәтле чаралар узды. Татар язучылары Р.Батулла, Ф.Садриев, Х.Миңнегулов, Ф.Галимуллин, Э.Шәрифуллина, Д.Салихов, Р.Фәйзуллин, Р.Зәйдулла, В.Имамов, Р.Галиуллин, Л.Лерон, Р.Сәгъди, Г.Бәйрәмова, Ф.Солтан, Факил Сафин, А.Хәлим, Ш.Җиһангирова, Р.Сәлимҗанов, С.Якупова, А.Әхмәтгалиева, А.Хәмзин, М.Разов, Л.Садриева, Л.Фәттәхова, Г.Шаһи, А.Суфиянов, районның бик күп авылларында булып, укытучылар һәм мәктәп укучылары белән очрашты. Шул көнне кич Яңа Троицк авылы мәдәнияттәт йортында «Җырымда юатырмын» дигән әдәби-музыкаль кичә булды. Кичәдә Фәннур Сафин сүзләренә язылган җырлар яңгырады, Тукай муниципаль район хакимияте башлыгы Фаил Камаев һәм Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов язучы-сатирик, җырчы-композитор Алмаз Хәмзин белән ветеран-язучы, шулай ук бик күп көйләр авторы Рубис Зариповка Фәннур Сафин исемендәге премия тапшырды.

● 16 февральдә Казандагы Г.Тукай әдәби музеенда «Кулыма китап алам» дип исемләнгән күргәзмә ачылды. Ул «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре» китабы басылуга 105 ел тулуга багышланган.

● 18 ноябрьдә Татарстан Язучылар берлегенең Тукай клубында ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, күренекле шагыйрь Газинур Моратовка 60 яшь тулу уңаеннан иҗат кичәсе үтте. Анда юбилярның каләмдәш дуслары Р.Батулла, Д.Салихов, Р.Зәйдулла, Р.Гаташ, К.Кәримов, Ш.Җиһангирова, Х.Җәләй, Р.Рахман, Ф.Галимуллин, Р.Мөхәммәтшин, И.Иксанова, Г.Рәхим, М.Закир, Г.Гыйльманов, А.Хәмзин, Л.Лерон, М.Гафурова, Ф.Кутлу, Казандагы Ш.Мәрҗани исемендәге 2 нче гимназиянең икенче сыйныф укучысы Ф.Гатина катнашты һәм чыгыш ясады. Кичәне шагыйрь һәм прозаик Марат Кәбиров алып барды.

● 27 ноябрьдә Уфаның «Ихлас» мәчетендә танылган журналист Фәнис Фәтхине (1961-2018) искә алу чарасы булып узды. Чарада мәрхүмнең хатыны Зөһрә Фәткуллина, кызлары Алия һәм Җәмилә, якын туганнары, каләмдәш дуслары, дин әһелләре һәм Казаннан килгән кунаклар – Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон һәм башкалар катнашты. ■

Мирасворд

Язучы, «Күрше малае», «Сусыз дәрья» повестьлары авторы

Бик нык тузган, ертылып-тишелеп беткән

Тәүфикъ Әйди повесте

Язучы ... Тәрҗеманов

Гомергә, мәңгелеккә (иск.)

Үзеңне тота белү кагыйдәләре

Борынгы француз биюе

Шагыйрь Әхмәт ...

Күрәзәлек итү

Мордваларның милли уен коралы

Ку-клукс-...

Христианнарда табыну сурәте

Татар халык дастаны

Брюс, Вивьен

Мишәр абзые

Кәрим Тинчурин драмасы

Әсәрнең композицион өзеге, бүлеге

Иркен (иск.)

Мәҗүсиләр табына торган сын, балбал, пот

«Бөтен союз старостасы»

Кереш сүз

Ашальчи ... (удмурт шагыйрәсе)

Казах кабиләсе

Сугарга дигән көлтәләрне киптерү урыны

... Кинҗәбулатов (башкорт шагыйре)

Африкадагы ил

Ясир ...

Драматург Гамир ...

Төс, кыяфәт (диал.)

Ызгыш, талаш, гауга

Жанна д' ...

Тур Хейердал көймәсе

Ерак Көнчыгышта яшәүче аз санлы халык

Таҗи Гыйзәтнең «Ташкыннар» трилогиясендәге персонаж

Шагыйрь ... Гамбәр

«... кыры» повесте (Чыңгыз Айтматов)

Коләхмәтов, Каюмов

Һәрвакыт

Пәйгамбәр

... Арагон

Ерак җир, урын (диал.)

Рәис Габдулла төзеде.

11 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: камыт, кару, «Картуф», ага, Тумашев, Бола, ымлык, пыр, ошак, Рашат, Аван, пута, «Иоланта», мум, Купер, учар, Икар, Рамо, орчык, Алов, би, Әбрар, илот, үч.
Өстән аска: Кәрами, «Убырут», ал, Морат, кимоно, Акмал, Шамуков, шава, Упа, акр, Тимер, матавык, ыруг, алу, Гобәй, Туфайлова, «Ышаныч», чирү, акант, чабы, Абрек.

«Безнең мирас» елъязмасы /декабрь

Низами Ганҗәвигә куелган һәйкәл.
Баку шәһәре,1949 ел. Авторы Фуад Габдрахманов

810 ел элек (1209)

Низами Ганҗәви (1141-1209) – «Ләйлә вә Мәҗнүн» поэмасын иҗат иткән бөек шагыйрь – вафат була.

790 ел элек (1229)

Каракорымда (Җучи Олысының башкаласы) корылтай җыела. Олысның бөек ханы итеп Чыңгыз ханның өченче углы Үгәдәй (1186-1241) сайлана.

540 ел элек (1479)

Казан ханлыгының күренекле шагыйре Өмми Камал (чын исеме – Исмәгыйль) дөньядан кичә.

440 ел элек (1579)

Ливония сугышында җиңелә башлагач, Явыз Иван, инде яуланган Казан һәм Әстерхан төбәкләреннән, Нугай Урдасыннан, Касыйм ханлыгыннан татарларны җыеп, аларны яубашы Касыйм ханы Мостафагалигә буйсындырып, Курляндиягә яуга җибәрә.

155 ел элек (1864)

3 декабрьдә язучы вә галим Муса Акъегет (1864-1923) дөньяга килә.

100 ел элек (1919)

23 декабрьдә Россия Коммунистлар партиясенең Омск вилаять комитеты каршындагы мөселман оешмасы әдәби һәм сәяси «Азат Себер» исемле татар телендәге газетаның 1 нче санын чыгара. Ошбу басма 1935 нче елга кадәр яшәп килә.

60 ел элек (1959)

«Совет әдәбияты» журналында Һади Такташның яңа табылган хатлары дөнья күрә.

50 ел элек (1969)

ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты каршында «Иҗади яшьләр оешмасы» төзелә. Оешманың җитәкчесе итеп Роберт Батуллин билгеләнә.

Журналга ***Марат Закир*** *әзерләде.* ■

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЖУРНАЛЫНЫҢ 2019 ЕЛГА БИБЛИОГРАФИЯСЕ

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

Әнвәр Давыдов. – №3. – Б.3.
Әхмәт Саттар. – №10. – Б.3.
Габдулла Тукай. – №4. – Б.3.
Газинур Морат. – №8. – Б.3.
Дәрдемәнд. – №11. – Б.3.
Зиннур Мансуров. – №7. – Б.3.
Зыя Ярмәки. – №6. – Б.3.
Мөхәммәдьяр. – №2. – Б.3.
Мөхәммәт Мәһдиев. – №12. – Б.3.
Сәгыйть Сүнчәләй. – №5. – Б.3.
Фатих Кәрим. – №1. – Б.3.
Шәүкәт Гаделша. – №9. – Б.3.

ТАРИХИ МИРАС

А.Галимҗанов. Татарлар Грузияне дә коткарганнар. – №4. – Б.50-51.

А.Галимҗанов. Чыңгыз хан – кара татарлар нәселеннән. – №7. – Б.10-11.

А.Зиннәтуллина. «Мәктәп тотып үскән баллы Багъбостан ханым...» – №5. – Б.16-22.

А.Минһаҗ. Әтрәк әл-Каткан кыйссасы. – №5. – Б.23.

А.Нәҗми. Тәрҗеман-әл-Әнҗерәи нәселе. – №3. – Б.14-17; №4. – Б.18-21.

Ә.Аширов. Томск йомышлы татарлары Кузнецк крепосте төзелешендә. – №11. – Б.21-25.

Ә.Әкъсәнов. Казан ханлыгында ислам дине. – №6. – Б.17-19.

Г.Баембәтов. Бер ай частьта. – №2. – Б.16-21.

Г.Гали. Париж выставкасында. – №5. – Б.16-22.

Г.Гобәйдуллин. Татар телендәме, рус телендәме? – №9. – Б.36-39.

Г.Төхфәтова. «Милләтне без тергезик!» – №2. – Б.36-41.

Г.Хаҗиева. Хозыр Ильяс булсын юлдашың! – №7. – Б.28-30.

З.Әхмәд. Яңа Болгар пүчинкәсе. – №4. – Б.22-24.

И.Биккинин. «Алты авыл» татарлары һәм бертуган Хәмитовлар. – №11. – Б.16-20.

И.Габдрахманов. Белем алу тарихыбыздан... – №7. – Б.31-33.

И.Газизуллин. Дон казаклары һәм татарлар. – №3. – Б.34-39.

И.Салихҗан. Такталачык: ятимнәр сыенган җылы йорт. – №5. – Б.13-15.

И.Таһиров. 1920 нче еллардагы татар рухи тормышы. – №10. – Б.26-31.

Илдус Әмирханов: «Дәүләт милләтне тудырмый, милләт дәүләтне тудыра!» – №1. – Б.44-46.

Йорт-Орыдагы чат татарлары музее. – №11. – Б.13-15.

К.Нәҗми. Большевизм уты астына. – №8. – Б.21-27; №9. – Б.24-29.

К.Нәҗми. Я.Мамкиев, И.Хәмзин. Бер мәктәпнең кыскача тарихы. – №6. – Б.10-12.

К.Локман. Садри Максуди Арсалның Сорбонна университетындагы соңгы дәресе. – №1. – Б.32-35.

«Корылтай» газетасы. – №12. – Б.26-30.

Л.Гайнанова. Тукай жандармерия документларында. – №4. – Б.40-49.

Л.Галиева. Гаяз Исхакый – татар Прометее. – №12. – Б.22-25.

Л.Галиева. Гаяз Исхакый – француз журналында. – №9. – Б.40-41.

Л.Гобәйдуллин. «Тамашачы» журналы. – №1. – Б.26-31.

Л.Гобәйдуллин. Екатеринбургтагы борынгы татар зираты. – №11. – Б.53-55.

Л.Коновалова. Екатеринбургтагы «татар кварталы» һәм сәүдәгәр Агафуровлар. – №11. – Б.46-52.

Л.Мортазина. Габдулла Тукай турында бер истәлек. – №4. – Б.34-35.

Л.Мортазина. Татар шырпы заводлары. – №9. – Б.20-23.

Л.Мортазина. Тукаев кәнфитләре. – №4. – Б.25.

Л.Мөхәммәтҗанова. Икмәкле дә, хикмәтле дә Мамадыш. – №7. – Б.24-27.

М.Госманов. Археографик көндәлек. – №9. – Б.30-35; №10. – Б.32-38.

М.Зәйнетдинов. Камышлы хатирәләре. – №6. – Б.34-37.

М.Фәйзи. «Күпме яшь күкрәкне изге дип издермәдем». – №9. – Б.42-47.

М.Фәйзи. «Курчак уйнар идем менә». – №10. – Б.42-47.

Мәрҗани ул – Тимерказык! – №2. – Б.32-35.

Н.Каштанов. Төрк тарихына бер караш. – №10. – Б.39-41.

Н.Савельева. Томскида татар театры тарихы. – №11. – Б.39-41.

Новосибирск шәһәренең мәдәни тормышыннан кайбер сәхифәләр. – №6. – Б.28-33.

О.Иванова. Гәүһәршад. – №1. – Б.4-10.

О.Иванова. Сөембикә. – №4-10.

Р.Ахунҗанова. Таҗетдин чишмәсе. – №6. – Б.13-16.

Р.Вилданова. Семберләге татар бистәсе. – №11. – Б.26-31.

Р.Мәрданов, И.Һадиев. Тау иленең ташъязма истәлекләре. – №4. – Б.36-33.

Р.Мәрданов. Саралы мең ыруы татарлары. – №1. – Б.36-43; №2. – Б.26-31; №3. – Б.22-29.

Р.Мөхәммәтшин. Егерменче еллар сәламе... – №8. – Б.34-35.
Р.Шәйдуллин. Мәрҗаниләр эшен дәвам итеп... – №12. – Б.17-21.
Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин. «Сибирия» газетасында Томск шәһәре татарлары тормышы. – №11. – Б.32-38.
Рафаэль Баһаветдинов: «Без рухи-әхлакый хәзинәләрне сакларга тиеш!» – №6. – Б.45-51.
Ризаэддин казый сабакташы Хөснулла ахун. – №6. – Б.38-44.
Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре. – №1. – Б.47; №2. – Б.25; №3. – Б.21.
Ризаэддин Фәхреддин. Сәгыйдь. – №1. – Б.11-16; №2. – Б.9-15.
С.Шәмси. Этрусклар – Рим остазлары. – №7-12.
Т.Галиуллин. Милли күтәрелеш җимеше иде... – №3. – Б.30-33.
Татар бистәләренең шанлы тарихы. – №11. – Б.12.
Татарстан җөмһүрияте авылларындагы җәйге эш күренешләре. – №7. – Б.34-35.
Татарстанның бишьеллык бәйрәме көнендә. – №2. – Б.22-24.
Татарча язу машиналары. – №3. – Б.18-20.
У.Сүләҗи. Читада Яңа ел каршы алу. – №1. – Б.17-25.
Ф.Бәйрәмова. Чат татарлары. – №6. – Б.20-27.
Ф.Мусин. Куян авылы тарихы. – №3. – Б.9-13.
Ф.Мусин. Тарихи карталарда – Бәрәңге җирләре. – №12. – Б.12-16.
Ф.Уразаев. Кайту. – №7. – Б.36-43.
Ф.Хатипов. Агымсуларны эшкә җигәсе бар. – №8. – Б.28-33.
Х.Бәдигый. Хәтер көне. – №10. – Б.21.
Х.Габәши. «Төрки халыкларның гомуми тарихы». – №2-4, 8.
Ч.Сафиулла. Кем ул Лотфи Исхакый? – №10. – Б.22-25.
Челтәрле дә бизәкле. – №11. – Б.42-45.
Чишмә авылы тарихы. – №5. – Б.27-31.
Шәрип Шәймиевнең музей-йорты. – №5. – Б.24-26.
Э.Сабирова. «Кулында форсат вакытта укып кал». – №4. – Б.36-39.
Э.Сәлахова. Затлы гаилә язмышы. – №12. – Б.31-37.
Э.Шәвәлиева. Әйт, авылым, кайда соң моң? – №6. – Б.52-55.
Ю.Карпов. Әҗмәк һәм Васильево авыллары тарихы. – №7. – Б.18-23.

ТАТАР ГАМЕ

А.Закир. Яшел камин яктысы. – №5. – Б.72-74.
Ә.Фәйзрахманов. Ихлас күңелле спикер. – №5. – Б.32-33.
Ә.Шәрипов. Сәнгатьчә дә, тарихи да... – №10. – Б.59-63.
Әмир Гәрәев: «Татар мәдәниятенең байлыгы – безнең горурлыгыбыз!» – №6. – Б.56-61.
Без – мираслы халык! – №2. – Б.42-45.
Буа театры артисты Ильфир Солтанов: «Безнең эш урыны – дөнья». – №3. – Б.44-47.
Г.Морат. Сусау ләззәте. – №6. – Б.70-73.
Г.Рәхим. Елый-елый укыган китап. – №7. – Б.49-50.
Г.Хаҗиева. Татар галимнәрен таныткан хезмәт. – №12. – Б.49-50.
З.Мансуров. Пушкин белән шигырь алмашу. – №9. – Б.58-63.
И.Сафин. Кулаткы укулары тарихы. – №5. – Б.52-55.
И.Хәлимов. Кем ул Эдуард хаҗи Ганиев? – №5. – Б.42-43.
Казанда беренче матбугат ифтары. – №7. – Б.56-57.
Казанны данлаучы шәхес. – №3. – Б.40-43.
Минтимер Шәймиев: «Туган тел проблемаларына күз йома алмыйбыз». – №7. – Б.44-48.
Н.Гыйләҗева. И, бөек китап... – №10. – Б.64-65.
Н.Сабиров. Апанай мәчете: тарихы һәм хәзерге заман. – №5. – Б.55-58.
Нәкыйп Каштанов: «Без – серле халык». – №4. – Б.55-57.
Р.Закиров. Дөнья бәһасе торырлык инсан. – №5. – Б.40-41.
Р.Зәйдулла. Игелекле ханым. – №2. – Б.50-55.
Р.Сәгъди. Әлмәт театрының асылташы. – №1. – Б.48-56.
Р.Сәгъди. Керәшеннәр башкаласы. – №7. – Б.51-55.
Р.Сәгъди. Көрәшчеләр. – №11. – Б.56-63.
Р.Хәбибуллина. Безнең заман һәм замандашлар. – №8. – Б.42-49; №9. – Б.50-57.
Т.Галиуллин. Гыйлем үзәге... бар иде. – №12. – Б.44-48.
Т.Галиуллин. Күңеле пакьнең эше дә ак. – №6. – Б.62-69.
Т.Гыйләҗев. Хатыйп Миңнегулов: галим һәм остаз. – №5. – Б.64-71.
Ф.Бәйрәмова. Шәҗәрә капкасын ачучы... – №10. – Б.48-53.
Ф.Җәүһәрова. Халкыбызның асыл заты. – №1. – Б.57.
Ф.Җәүһәрова. Бөркет биектән курыкмас. – №5. – Б.59-63.
Ф.Җәүһәрова. Чын галимнең сүзе калыр, җуелмас эзе калыр. – №2. – Б.46-49.
Ф.Леронова. «Бәйгеләрдә бәйге тоткан кавем...» – №8. – Б.36-41.
Ф.Садриев. Галимнең ике җиңүе. – №4. – Б.52-54.
Фәрит Мадьяров шигырьләре. – №11. – Б.64.
Х.Габидуллина. Өстәлемдәге китап – тарих ядкаре. – №11. – Б.65-66.

Х.Ибраһим. Яшел тышлы китап. – №9. – Б.48-49.
Х.Миңнегулов. Рухи хәзинәбезне барлаганда. – №12. – Б.38-43.
Х.Хәлилов. Аның рухы, фәһеме бар... – №12. – Б.51-52.
Э.Шәрифуллина. Туган ил каян башлана? – №10. – Б.54-58.
Эдуард хаҗи Ганиев ядкяре. – №5. – Б.44-51.
Энгель Фәттахов: «Сабан туе милли горурлыкны арттырырга тиеш!» – №5. – Б.34-40.

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

А.Сарманбәтов. Җәнҗал агачы. – №1. – Б.58-65.
Абай. Хикмәтле сүз. – №10. – Б.66-67.

ДИНИ МИРАС

А.Гайнетдинов. Габдулла Буби һәм аның «Иҗтиһад заманы үттеме, юкмы?» китабы. – №7. – Б.78-79.
Г.Буби. Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме? – №7. – Б.80-83; №8. – Б.56-61; №12. – Б.58-61.
Г.Ибраһимов. Ислам дөньясы. – №1-12.

ӘДӘБИ МИРАС

А.Әхмәдуллин. «Хөсәен мирза» трагедиясе турында. – №8. – Б.68.
А.Имамиева. Ярмәк әдибе – Г.-Халикъ Садри. – №6. – Б.80-81.
А.Хәлим. Исемле кошлар хуҗасы. – №2. – Б.74-77.
Абакамның көтепханәсе. – №11. – Б.81-82.
Ә.Гаффар. Гаффаризмнар. – №4. – Б.73.
Ә.Шәрипов. Сириннең публицистик поэмасы. – №11. – Б.88-89.
Бикә Рәхимова шигырьләре. – №4. – Б.67-69.
Г.-Халикъ Садри. Безнең таң. – №6. – Б.82-88.
Госман Садә шигырьләре. – №3. – Б.68-69.
Дәрдемәнд. Вак хикәяләр. – №3. – Б.54-55.
«Җиңел адымнардан соң». – №4. – Б.70-72.
З.Мансуров. «Туган тел»гә һәйкәл кирәк. – №7. – Б.84-91.
Л.Мортазина. Көнең өчен яшәмә. – №1. – Б.72-77.
Л.Хәмидуллин. Безнең тарих белән кызыксыну арта. – №2. – Б.72-73.
Л.Хәмидуллин. Дәрдемәнднең барланмаган иҗат үрнәкләре. – №11. – Б.77-80.
М.Закир. Киләчәккә йөз тоткан берлек. – №1. – Б.78-79.
М.Өзтүрк. «Күңелем һәрчак сине эзли, кайларда син?!» – №4. – Б.64-66.
О.Иванова. Сөембикә. – №3. – Б.70-73.
Р.Батулла. Йолдызның нурлы улы. – №6. – Б.89-92.
Р.Мингалим. Үпкәләрмен кебек. – №6. – Б.93.
Р.Фәттәхова. Мәшһүр иремнең беренче хатыны. – №3. – Б.56-59.
С.Сүнчәләй. Күл – күз яше. – №11. – Б.72-76.
С.Сүнчәләй. Хатирәт. – №8. – Б.62-67.
Сирин. Халыкара сугышка каршы Конгресста Сириннең сөйләгән беренче рече. – №11. – Б.90-93.
Ф.Бурнаш. Хөсәен Мирза. – №8-12.
Ф.Кутлу. Кем ул – Карәхмәт? – №10. – Б.82-90.
«Хәтергә уелган китап» конкурсының нигезләмәсе. – №4. – Б.79.
Х.Сарьян. Башкорт кызы. – №2. – Б.62-71.
Х.Ширмән. «Әллүки»ле еллар. – №4. – Б.74-78.
Э.Закирова. Җылынды синең учакта, җылынды ничә буын!.. – №3. – Б.60-67.
Э.Шәрифуллина. Әгәр Фаил исән булса... – №5. – Б.80-87.

ХӘТЕР САНДЫГЫ

«Зур эшләргә көч, кабилият, мәхәббәт сизелә үзегездә». – №3. – Б.78-81.
А.Дубин. Тарих шаһитлары. – №9. – Б.83.
Ә.Зарипов. «Исемең матур, кемнәр куйган...» – №7. – Б.100-105.
Ә.Зарипов. Бер рәсем тарихы. – №10. – Б.94-95.
Ә.Зарипов. Фәтхуллиннар эзе. – №6. – Б.94-103.
Ә.Фәйзрахманов. «Тылсымлы тартма»ның... беренче адымнары. – №12. – Б.70-75.
Ә.Фәйзрахманов. Әмирхан ага һаман да сагындыра. – №3. – Б.74-77.
Ә.Фәйзрахманов. Сөер дустыбыз Шамил. – №9. – Б.80-82.
Ә.Фәйзрахманов. Сурәтле хатирә. – №11. – Б.100-101.
Ә.Фәйзрахманов. Татарстан сандугачы. – №4. – Б.80-84.
Г.Гомәр. Җырлап китте мәңгелеккә. – №3. – Б.87-89.
Г.Дәүләтшина. Төшләремә кергән Алмания... – №4. – Б.98-99.
З.Хәйруллин. Милләтебезнең горурлыгы. – №3. – Б.90-93.
И.Сәлахов. Татарның гаярь ирләре. – №12. – Б.80-81.
И.Һадиев, Р.Мәрданов. Иске Мәңгәрнең борынгы зиратындагы ташъязма истәлекләр. – №12. – Б.76-79.
Истә, һаман да истә! – №1-12.
Л.Лерон. Мәктәпләр һәм сабакташлар. – №8-12.
М.Закир. Әфган дастаны (бәяннан өзек). – №2. – Б.84-91; №3. – Б.82-86.

Н.Гыйләҗева. Дин кушканча яшәде. – №11. – Б.96-99.
Н.Мәхмүтов. Багдадтан хатлар. – №4. – Б.93-97.
Нәбиулла солдат кыйссасы. – №2. – Б.92-95.
Р.Зарипов. Мөхтәрәм Мөдәмил ядкяре. – №8. – Б.83-94.
Р.Мәһдиев. Уттан сау чыккан хәтер-хатирә (Фронтовик этием язмалары). – №1. – Б.80-85; №2. – Б.78-83.
Р.Сәгъди. Моңлы ядкарь. – №12. – Б.84-88.
Р.Хуҗахмәтова. Сугышта җиңеп кайткан этием. – №5. – Б.88-90.
Р.Хуҗәхмәтова. Иске альбом хатирәсе. – №4. – Б.91-92.
С.Ибраһимова. Сергей Михалков белән очрашу. – №5. – Б.95-97.
Сурәтле хатирә. – №9. – Б.83; №10. – Б.96-97.
Ф.Кутлу. Кайсысы дөрес: «Фатих»мы, әллә «Фатиһ»мы? – №8. – Б.98-99.
Ф.Хәсәнов. Иске Мостяк хатирәләре. – №5. – Б.91-94.
Ф.Якупов. Күршем Хәсән Сарьян. – №4. – Б.85-90.

СӘНГАТИ МИРАС

А.Хәкимова. Иңнәргә канат куйган еллар... – №3. – Б.100-107.
А.Хәкимова. Якты күңелле җырчы. – №9. – Б.106-110.
Ә.Зарипов. Тукайга якынаю юлында. – №11. – Б.112-115.
Ә.Зарипов. «Әнвәр». – №9. – Б.96-101.
Ә.Зарипов. Әдип-галим-артист Габдулла абыйга мәдхия. – №12. – Б.100-105.
Ә.Зарипов. Нәдер, Гали абый, Мингали Исламович... – №10. – Б.104-106.
Р.Гыйләҗев. Борынгы татар милли музыка уен кораллары. – №1-12.
Р.Сәгъди. Зур иҗатка бер караш. – №5. – Б.104-111.
Р.Шаһиева. Гасырлар-чорлар аша – яңа үрләргә! – №12. – Б.106-115.
С.Сүнчәләй. Музыкабыз. – №5. – Б.100-103.
Хикмәтле хатлар. – №1. – Б.94-99.

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

Ә.Гадел. Телнең киләчәге – безнең киләчәк! – №1. – Б.100-103.
Б.Рәхимова. Ил тотмыйча, тел тотып кара... – №8. – Б.106-109.
Г.Мөхәммәдкәрим. «Сүзләр тавыш биреп атлыйлар...» – №6. – Б.111.
Г.Рәхим. Сүзләр иленә сәяхәт (Лингвистик хикәятләр). – №2. – Б.104-107; №3. – Б.108-110.
М.Әгъләм. Ә маймылы кайда? – №6. – Б.110.
Р.Сәфәров. «Татарстан». – №6. – Б.108-109.
Р.Сәфәров. Челлә, чиләк һәм челтәр. – №2. – Б.108-109.
Тукай шигърияте безгә ник якын һәм кадерле? – №4. – Б.105-107.
Ф.Кутлу. Яхшы хатын – ир күрке. – №3. – Б.111.

ХӘТЕР САГЫНДА

«Иске Казан» дәүләт музей-тыюлыгы. – №4. – Б.114-115.
Иске Казанда – саклану һәм һөҗүм итү кораллары. – №3. – Б.114-115.
Киез итекләр иле. – №1. – Б.112-115.
Н.Фәттахова, Л.Харасова. Ядкәрләр табыла. – №4. – Б.3.110-113
Симетбаш һәйкәлләре. – №5. – Б.114.
ТАССР тарихы – фотоларда. – №9. – Б.119.
Татарстан Республикасының Милли китапханәсе. – №1-9.
Хотня авылындагы намаз йорты һәм кәшәнә. – №2. – Б.114-115.
Ябынчыда – «Муллалар коесы». – №1. – Б.110-111.

ПЕДАГОГИК МИРАС

Л.Мортазина. Керәшен татарлары математигы Игнатий Алексеев. – №7. – Б.58-63.
Р.Исхаков. Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе. – №7. – Б.64-71.

СУГЫШ КАЙТАВАЗЫ

Р.Низами. Өчәү (хикәя). – №7. – Б.96-99.
Р.Шәйдуллин. Сихерче карт. – №7. – Б.92-95.
Ш.Мостафин. Изге антка тугрылык. – №8. – Б.77-82.

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН

Гомәр Бәширов көндәлегеннән. – №8-11.

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ХӘБӘРЛӘРЕ. – №1-12.

МИРАСВОРД. – №1-12.

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЕЛЪЯЗМАСЫ. – №1-12.

*Басмага **Ләйсән Данилова** әзерләде.* ■



СОДЕРЖАНИЕ. ДЕКАБРЬ 2019

И останется в мире слово моё…: Мухаммад Магдиев.

Историческое наследие: «Этруски – римские умельцы». С.Шамси; «Продолжая работу поколения Марджани...» Р.Шайдуллин; «Гаяз Исхаки – татарский Прометей». Л.Галиева; «Газета «Курултай». Р.Шарафеева, Л.Губайдуллин; «Судьба знатной семьи». Э.Саляхова.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Хусаин Мирза». Ф.Бурнаш.

В глубинах памяти: «Надгробные надписи в древнем кладбище деревни Старый Менгер». И.Хадиев, Р.Марданов; «Смелые мужчины татарского народа». И.Саляхов; «В памяти, до сих пор в памяти!»; «Школы и одноклассники». Л.Лерон.

Художественное наследие: «Древние национальные музыкальные инструменты». Р.Гилязов; «Минуя веки и эпохи к новым вершинам!» Р.Шагиева.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. DEZEMBER 2019

There will be left my word in the world…: Mukhamad Magdiev.

Historic heritage: «The Etruscans are the Roman craftsmen» by S.Shamsi; «Keep doing the works of Mardjani's generations» by R.Shaydullin; «Gayaz Iskhaki is the Tatar Prometheus» by L.Galieva; «Kurultay» newspaper»; «The destiny of the Tatar notable family» by E.Salyakhova.

Religious heritage: «Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov.

Literary heritage: «Khusain Mirza» by F.Burnash.

From the deepest store of memory: «The stone inscriptions are in the ancient graveyard of Stariy Menger village» by I.Khadiev, R.Mardanov; «The courageous men of the Tatar people» by I. Salyakhov; «Still keeping in the memory, still keeping!»; «Schools and classmates» by L.Leron.

Creative heritage: «The ancient Tatar national musical instruments» by R.Gilyazov; «Passing through the centuries, epochs to the new high points» by R.Shagieva.

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation's life.

Сергей Неустроев

Сергей Васильевич Неустроев 1927 елның 25 июнендә Киров өлкәсенең Подгорное авылында туа. Казан сынлы сәнгать училищесын (1958) тәмамлый. 1980 елдан СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы. ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1981).

Казан шәһәрендә иҗат итте һәм 2010 елда вафат булды.

«Машинист Клюев». 1959. Киндер, майлы буяу

«Борынгы әйберләр». 1970. Киндер, майлы буяу

«Көнбагыш белән натюрморт». 1968. Киндер, майлы буяу

Язып һәм 5 смартфонның берсен от!

Бүләкләр 2020 елның 19 февралендә уйнатылачак

2019 елның 30 декабренә кадәр «ТАТМЕДИА» АҖнең кимендә өч басмасына

1 ЯЗЫЛ

Язылу квитанцияләренә «Акция» билгесен куеп, копияләрен (телефон номерын язарга онытмагыз!) 420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур. 2 нче йорт, яисә podpiska@tatmedia.ru адресына

2 ҖИБӘР

Биш смартфонның берсен, юрган һәм башка бүләкләр

3 ОТ

татмедиа

Акциянең үткәрелү вакыты, бүләкләр һәм аларны алу тәртибе турында тулырак tatmedia.ru сайтында. Акциянең үткәрелү вакыты 1.11.2019-30.03.2020. Гаризалар 2020 елның 20 гыйнварына кадәр кабул ителә. Оештыручы - «ТАТМЕДИА» АҖ. Реклама 16+